КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ

ИНСТИТУТ ПЕДАГОГИКИ И ПСИХОЛОГИИ

А.Н. ХУЗИАХМЕТОВ

Р.Р. НАСИБУЛЛОВ

# Педагогика: История образования и педагогической мысли (Мәгариф тарихы һәм педагогик фикерләү)



**Краткий конспект лекций**

Казань-2013

*Принято на заседании кафедры педагогики*

*Протокол № 7 от 29.01.2013*

**Хузиахметов А.Н., Насибуллов Р.Р.**

**Педагогика: История образования и педагогической мысли: Краткий конспект лекций (в билигвальной тат.-рус. среде)** / А.Н. Хузиахметов, Р.Р. Насибуллов; Каз.федер.ун-т. – Казань, 2013. – 109 с.

Педагогик эшчәнлекне һөнәр итеп сайлаган кешегә педагогиканы белү бигрәк тә кирәк. Педагогик белемнәре булмаган кеше мәктәпкә килсә, эшкә ничек керешеп китәргә дә белмәячәк. Эше нәтиҗәле булсын өчен, аңа тәрбиянең максатын һәм бурычларын ачык белү зарур. Бары шунда гына аның эшендә тиешле дәрәҗәдә максатка омтылучанлык туачак. Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган лекцияләр курсы да нәкъ менә шуңа хезмәт итәр дип уйлыйбыз.

**© Казанский федеральный университет**
**© Хузиахметов А.Н., Насибуллов Р.Р.**

## Содержание

**1. Тема 1.** ***ПЕДАГОГИКАНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ……* 5**
1.1. Вопросы для самоконтроля ........................................................... 18
1.2. Задания для практики ..................................................................... 19
1.3. Глоссарий по теме 1 ....................................................................... 25
1.4. Использованные информационные ресурсы ................................. 27
**2. Тема 2.** ***БОРЫНГЫ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ*.......................28**
2.1. Вопросы для самоконтроля ........................................................... 32
2.2. Задания для практики ..................................................................... 32
2.3. Глоссарий по теме 2 ....................................................................... 33
2.4. Использованные информационные ресурсы ................................. 33
**3. Тема 3.** ***КОЛБИЛӘҮЧЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ТӘРБИЯ*........ 34**
3.1. Вопросы для самоконтроля ........................................................... 45
3.2. Задания для практики ..................................................................... 46
3.3. Глоссарий по теме 3 ....................................................................... 46
3.4. Использованные информационные ресурсы ................................. 47
**4. Тема 4.** ***ФЕОДАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР*…………………………………...……………………….…. 47**
4.1. Вопросы для самоконтроля ........................................................... 57
4.2. Задания для практики ..................................................................... 57
4.3. Глоссарий по теме 4 .......................................................................57
4.4. Использованные информационные ресурсы ................................. 58
**5. Тема 5.** ***МОНОПОЛИСТИК КАПИТАЛИЗМГА КАДӘРГЕ ЧОРДА МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИКА. ЯН АМОС КОМЕНСКИЙНЫҢ ПЕДАГОГИК ТЕОРИЯСЕ*.................................................................... 59**
5.1. Вопросы для самоконтроля............................................................ 73
5.2. Задания для практики...................................................................... 73
5.3. Глоссарий по теме 5........................................................................ 73
5.4. Использованные информационные ресурсы.................................. 76
**6. Тема 6.** ***ДЖОН ЛОККНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ*….......76**
6.1. Вопросы для самоконтроля………………………..………………… 81
6.2. Задания для практики…………………..……………………………. 82
6.3. Глоссарий по теме 6........................................................................ 82
6.4. Использованные информационные ресурсы.................................. 83
**7. Тема 7.** ***ЖАН-ЖАК РУССОНЫҢ ПЕДАГОГИК ТӘГЪЛИМАТЫ* …… 83**
7.1. Вопросы для самоконтроля…………………………………………. 92

7.2. Задания для практики…………………..………………………..… 92
7.3. Глоссарий по теме 7...................................................................... 93
7.4. Использованные информационные ресурсы……………………..94
**8. Тема 8.** ***XVIII ГАСЫР ФРАНЦУЗ МАТЕРИАЛИСТЛАРЫНЫҢ (ГЕЛЬВЕЦИЙ, ДИДРО) ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ*** **……….…. 94**
8.1. Вопросы для самоконтроля……………………………………...... 99
8.2. Задания для практики……………………………………….…… 100
8.3. Глоссарий по теме 8......................................................................100
8.4. Использованные информационные ресурсы……………………101
**9. Тема 9.** ***ФРАНЦУЗ БУРЖУАЗ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЧОРЫНДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР ҺӘМ МӘКТӘП*** **………………...…………101**
9.1. Вопросы для самоконтроля……………………………………..... 108
9.2. Задания для практики…………………………………….…..…. 108
9.3. Глоссарий по теме 9...................................................................... 108
9.4. Использованные информационные ресурсы…………………… 109

**Тема 1.** ***ПЕДАГОГИКАНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ***

**Аннотация.** Данная тема раскрывает общую характеристику и возникновение педагогики как науки.

**Ключевые слова.** Образование, воспитание, обучение.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание «Эссе» и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

## *ПЕДАГОГИКАНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ*

Тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Тәрбия балаларның бер-берсенә һәм олыларга мөнәсәбәтләренә, аларның уен-хәрәкәтләренә, хезмәткә, тулаем бөтен җәмгыятькә карашларына юнәлеш биреп килгән. Тәрбия — иҗтимагый күренеш. Ләкин гомуми җәмгыять юк, ягъни борынгы җәмгыять, колбиләүчелек җәмгыяте, феодаль җәмгыять булган, шунлыктан гомуми тәрбия дә юк. Хаким сыйныфлар тәрбия аша үз сәясәтләрен, үсеп килә торган яшь буынга үз йогынтыларын үткәрәләр.

Бер иҗтимагый стройны икенчесе белән алыштыру революцион юл белән эшләнә һәм, строй үзгәрү белән бергә, тәрбия бирүнең эчтәлеге, аны оештыру формалары һәм методлары да үзгәрә. Тәрбия бирүнең практикасы да, теориясе дә тигез һәм эзлекле үзгәрми, бәлки иҗтимагый, сыйнфый көрәштә үзгәрә. Димәк, педагогика — тарихи фән ул.

Борынгы җәмгыятьтә сыйныфлар булмаган. Балалар бертөрле тәрбия алганнар, һәм бу тәрбия турыдан-туры хезмәт процессында, шулай ук балаларның уеннарында тормышка ашырыла торган булган. Ләкин, хезмәтнең җенескә карап бүленүе сәбәпле, ир һәм кыз балаларны тәрбияләүдә берникадәр аерма булган. Мәсәлән, ир балалар — аучылыкка, кызлар торак тирәсендәге эш төрләренә өйрәтелгәннәр. Ләкин борынгы җәмгыятьтә үк инде, гәрчә махсус тәрбия бирү йортлары булмаса да, өлкәннәрнең тәҗрибәсен махсус рәвештә яшь буынга тапшыру белән шөгыльләнүче кешеләр килеп чыккан. Җәмгыять тәрбия эшен контрольдә тоткан, аны оештырган һәм аңа

тиешле юнәлеш биргән. Димәк, ул чорда ук инде тәрбия эше саф стихияле процесс кына булмаган.

Җәмгыятьне сыйныфларга бүлү килеп чыккач, бай балаларын тәрбияләү ярлы балаларын тәрбияләүдән кискен аерыла. Мәсәлән, борынгы колбиләүчелек дәүләте Спартада бары тик хаким сыйныф балалары гына дәүләт исәбенә тәрбияләнгәннәр. Спарталылар хакимлек иткәннәр, җир хуҗалары һәм колбиләүчеләр булганнар. 9000 спарталы гаиләсе коллыкка төшерелгән 250000 илот һәм периэк гаиләсен изгән. Мондый хәл бары тик хәрби көч куллану аркасында гына була алган.

Спарталылар үз балаларын хәрби хакимлеккә әзерләгәннәр. Шуңа күрә аларда төп укыту предметы гимнастика һәм хәрби эш булган. Балаларда үз дәүләтенә ихлас бирелгәнлек, сугышчанлык, батырлык, тәртип, көч, җитезлек, чыдамлык, тыйнаклык, колларга җирәнеп карау һ. б. ш. сыйфатлар үстерергә омтылганнар.

Егетләрне хәрби лагерьга җибәргәннәр, алар анда чыныгу алганнар. Физик тәрбиягә зур игътибар биргәннәр. Шулай ук музыкага, җыр һәм биюгә өйрәнгәннәр. Бу дәресләр, һәм гомумән тәрбия, хәрби рухта булган.

Олы кешеләргә һәм идарәчеләргә һичсүзсез буйсыну, колларга, физик хезмәткә җирәнеп карау — Спартада хакимлек иткән изүче сыйныфларның балалары әнә шул рухта тәрбияләнгәннәр. Колларның һәм "иректә" дип йөртелгән гади халыкның балалары мәктәпләрдә яки башка төрле уку йортларында бернинди дә тәрбия һәм белем алмаганнар. Алар, һөнәрчеләр гаиләләрендә һәм турыдан-туры җир хуҗаларында эшләп, физик хезмәткә өйрәнгәннәр, хуҗаларына буйсынучанлык рухында тәрбияләнгәннәр.

Безнең эрага кадәр VII – V гасырларда Афинада Спартага караганда башкачарак икътисади шартлар булган. Бирегә сәүдә шактый үскән. Идарәчеләр белән халык арасында власть өчен көрәш барган. Гәрчә бирегә дә хуҗалык колбиләүчелек хуҗалыгы булып, аз санлы "гражданнар" йөз меңнәрчә коллар өстеннән хакимлек итсәләр дә, шулай да Афинада балаларга тәрбия бирү инде гимнастика, хәрби эш һәм хәрби музыка белән генә чикләнә алмаган. Афинадагы колбиләүчеләр үз балаларының белем алулары киң күләмдә сәүдә итү һәм сәяси тормышта актив катнашу өчен кирәкле сыйфатларга ия булулары белән кызыксынганнар.

Ул заманда Афина халкының шактый зур катлаулары сәяси көрәшкә тартылган. Афина урамнарына һәм мәйданнарына җыелган халыкка хәрби көч белән генә түгел, бәлки оратор сүзе белән дә йогынты ясау кирәк булган. Шунлыктан Афинада хәрби сәнгать белән беррәттән ораторлык сәнгатенә дә бик югары бәя бирелгән. Бай ата-аналарның уллары 7 яшьтән 17 яшькә кадәр түләүле хосусый мәктәпләргә йөргәннәр. Анда алар үзләрен яхшы тоту кагыйдәләренә, дөрес язарга, санарга, әдәби сүз сөйләргә, шулай ук җыр, поэзия һәм гимнастикага өйрәнгәннәр. Афинаның җир һәм сәүдә эшлеклеләре улларына физик һәм хәрби тәрбия биргәннәр, яшьләр сәяси һәм фәлсәфи әңгәмәләр алып барганнар, сөйләм осталыгына ия булганнар. Аеруча бай балалары бу сәнгатькә аерым "софист" укытучылардан бик күп акча түләп өйрәнгәннәр. Грек философы Платон әйтүенчә, Афина яшьләре шулардан белем алганнар, игенчеләр һәм һөнәрчеләр белән идарә итәргә өйрәнгәннәр.

Хезмәт ияләренең балаларына килгәндә исә, алар мәктәптә укымаганнар. Көндәлек эш тәҗрибәсе аша һөнәрчелеккә өйрәнгәннәр, хезмәт тәрбиясе алганнар. Кол балаларын мәктәпкә алмаганнар.

Шулай итеп, антик колбиләүчелек җәмгыятендә колбиләүчеләр сыйныфы тарафыннан юнәлеш бирелә торган тәрбия бу сыйныфның хакимлеген ныгытуга һәм изелүчеләр сыйныфын буйсындыруга юнәлдерелгән булган.

Хаким сыйныф балалары заманына күрә киң белем алганнар. Ә кол балалары фәннәрдән һәм сәнгатьтән бөтенләй читтә кала килгәннәр.

Коллар революциясе колбиләүчелек җәмгыятен җимерде, аңа алмашка феодаль җәмгыять килде.

Төрле иҗтимагый төркемнәрнең таркаулыгы һәм үз эченә бикләнгәнлеге, чиркәү йогынтысының гаять дәрәҗәдә үсүе, аерым феодалларның үзара өзлексез көрәш алып барулары сәбәпле, тәрбия бирүнең максатлары антик җәмгыятьтәгегә караганда башкачарак куела. Башка феодалларга һәм крестьяннарга каршы көрәшү өчен рыцарьга сөнге, кылыч белән эш итәргә, атта йөрергә һ. б. ш. өйрәнергә кирәк була, һәм аңарда шул сыйфатларны тәрбиялиләр дә. Рыцарьга бернинди дә диярлек фәнни белем кирәк булмаган. Шуңа күрә, кагыйдә буларак, дөньяви феодалларның бөтенесе дә диярлек укый-яза белмәгәннәр, фән яки физик хезмәт белән шөгыльләнүчеләргә җирәнеп караганнар.

Урта гасыр җәмгыяте тормышында бик зур роль уйнаган чиркәү һәм руханилар, хакимлекләрен һәм йогынтыларын ныгыту өчен, халыкка: "теге дөньядагы" тормыш хакына түзәргә кирәк, бары "теге дөнья" гына чын дөнья, дип аңлатырга тырышканнар. Чиркәүгә, феодалга буйсыну, хис-теләкләрен тыю, үз фикере булмау, сыкранмыйча авырлыкларга түзү – тәрбияләнүче алдына куела торган таләпләр әнә шулар булган. Дин бердәнбер хакыйкать чыганагы булып саналган. Ләкин дини хакыйкатьләр чынбарлыкны белүгә түгел, ә гайре табигый көчләргә, "алланың җир йөзен-дәге вәкиленең" абруена нигезләнгәннәр. Чиркәү алдында тулысынча, сукырларча баш ию һәм һичсүзсез буйсыну, дөнья фәнен дошман күрү әнә шуннан килә. Фән дингә хезмәт иткән. Нинди генә булмасын, чын фәнни фикер каты җәзага дучар ителгән, күп кенә галимнәрнең башлары чиркәү җәлладлары тарафыннан киселгән.

Урта гасырларда крестьяннар үзләрен коллыкка төшергән дөньяви һәм рухани феодаллар тарафыннан бик каты изелгәннәр. Белем алу ягыннан бөтенләй караңгылыкта кала килгәннәр.

Феодаль җәмгыятьтә тәрбия эше катлаулана дияргә була. Дворяннарның үз эченә бикләнгән катлавын тәшкил итүче (анда дворянлык мирас буенча тапшырыла) дөньяви феодаллар чиркәү һәм монастырь мәктәпләрендә фән белән шөгыльләнүне түбән эш итеп санаганнар. Кайбер эре феодалларның сарайларында югары катлау балалары өчен үз мәктәпләре булгалаган. Соңыннан дворян балалары өчен өстенлекле мәктәпләр — ир балалар өчен хәрби һәм дөньяви уку йортлары, кызлар өчен махсус институтлар төзелгән. Бу уку йортларына бүтән катлау балалары алынмаган.

Руханилар аерым катлау тәшкил иткәннәр. Крестьяннар, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр дә шулай ук үз эченә бикләнгән катлау группаларын тәшкил иткәннәр, бу группалардан чыгу аерата нык чикләнгән булган.

Урта гасырларда феодаль җәмгыятьтә чиркәү һәм монастырь мәктәпләре күп булган. Бу мәктәпләрдә бирелә торган белемнәр тормыш белән бәйләнмәгән, аларда әйберләрнең үзләрен өйрәнү белән түгел, бәлки һәртөрле ясалма билгеләмәләр, төшенчәләрне телдән өйрәнү белән генә шөгыльләнгәннәр. Шуның белән бергә аларда бөтен нәрсә тамгалар белән, дини мәгънәдә аңлатыла торган булган.

Яңа педагогикага нигез салучы, "Бөек дидактика"ның авторы Ян Амос Коменскийның бу "схоластик сафсата"га карашы менә нинди

булган: "Бер елда төшенә алырдай нәрсәләр белән укучы-ларны биш, ун һәм аннан да күбрәк ел тоткарлаганнар. Аңга акрынлап кертә барырга мөмкин нәрсәләрне көчләп такканнар, укучыларның башына тукып, тыңгычлап керткәннәр. Үзең күреп һәм аермачык күз алдына китереп була торган нәрсәне, караңгы, буталчык итеп, нәкъ табышмаклар төсле чуалтып аңлатканнар... Укучыларның башларын күбесенчә чүп-чар сүзләр, мәгънәсез лыгырдаулар, фикер калдыклары, сөрем белән тутырганнар".

Шулай итеп, феодаль җәмгыятьтә дә тәрбия эше сыйнфый характерда булган. Биредә белем бирү, нигездә чиркәү һәм руханилар кулында булганга күрә, дини рухта, тормыштан аерылган, күп сүзле, үтә схоластик булган.

Буржуазия иске, феодаль җәмгыятькә каршы аяусыз көрәш алып бара, атап әйткәндә, феодаль җәмгыятьтәге тәрбиянең катлаулылыгына кискен каршы чыга, белем бирү өлкәсендә тигез хокуклылыкны таләп итә иде. Бу таләп ул вакытта, һичшиксез, алдынгы таләп иде.

Буржуаз педагогика феодализмга каршы көрәш чорында күп кенә прогрессив таләпләрне алга сөрде. Балаларга схоластик, тормыштан аерылган белем бирү урынына, мәктәпнең тормыш белән бәйләнгән булуы, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, белем бирүдә күрсәтмәлелекне куллану һәм укучыларга гуманлы мөнәсәбәт таләп ителде. Ир һәм кыз балалар өчен гомуми укыту программасы кертү турындагы мәсьәлә куелды. Белем бирүне элеккегә караганда шактый тизләтергә, өстәвенә күбрәк балаларны укытырга мөмкинлек бирә торган яңа форма һәм методлар эшләнде.

XVIII гасыр уртасында ул чорның иң зур педагогик фикер ияләреннән берсе Жан Жак Руссо кеше хокукларын һәм шәхеснең ирекле үсешен бик нык яклап чыкты. "Табигый тәрбия бирү" идеясен алга сөреп, ул: кешеләр ирекле, сәләтле булып туалар, ә җәмгыять аларны боза, чөнки барлык тәрбия учреждениеләре социаль тигезсезлек һәм изү рухы белән сугарылган. Табигый хәлдә генә кешеләр арасында фактик тигезлек яши һәм кешене кеше коллыкка төшерү булмый, дигән караштан чыгып эш итте. Шуңа күрә Руссо, тәрбия эшен бозык җәмгыятьтән читтә алып барырга, аны җәмгыятькә бәйсез (ирекле) итәргә кирәк, дип саный иде.

Руссоның карашы үз вакыты өчен алдынгы булса да, аның төп идеясе тормышта була алмый иде.

Һәр фәннең үз тарихы була. Аның теоретик нигезләренә төшенү һәм аларны үзләштерү өчен әлеге тарихны белүнең әһәмияте зур. Шуның өчен педагогика курсын өйрәтүне аның үсеше турында кыскача гына тарихи күзәтүдән башлап китәргә кирәк.

Педагогика — борынгы белем тармакларының берсе һәм ул асылда җәмгыять үсеше белән аерылгысыз. Бу фикер аңлашыла төшсен өчен, бер җитди нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Педагогик белемнәр кеше эшчән-легенең тәрбиягә бәйле үзенчәлекле даирәсенә карый. Чынлап та, педагогика турында сөйләгәндә, гадәттә, бу сүз тәрбия төшенчәсе белән тәңгәлләшә. Ә тәрбия эше кешелек җәмгыяте барлыкка килгәннән бирле яши. Хезмәт коралларын ясауга һәм табигать хәзинәсен үзләштерүгә бәйле җитештерү тәҗрибәсен, шулай ук хезмәттәшлек һәм күмәк эшчәнлек тәҗрибәсен туплап, кешеләр бу тәҗрибәне яшь буынга биреп калдырырга тырышканнар. Иҗтимагый үсеш кешеләрнең һәр буыны ата-бабалар тәҗрибәсен баетып һәм тагын дә камил-ләштереп үзеннән соң килгән буыннарга тапшыруы нәтиҗәсендә мөмкин була. Шулай итеп, туплана килгән җитештерү, әхлакый һәм социаль тәҗрибәне яшь буынга тапшыру — кешелек җәмгыятенең яшәеше һәм үсеше өчен мөһим алшарт һәм аның төп вазифаларыннан берсе. Менә шуңа күрә тәрбия эше кешелек җәмгыятенең барлыкка килүе һәм үсеше белән аерылгысыз.

Башка иҗтимагый күренешләр кебек үк, тәрбия бирү эшчән-леге һәм аның характеры бер урында тормый, җәмгыятьтәге шартлар йогынтысында даими камилләшә һәм үсә. Озак вакытлар дәвамында, мәсәлән, өлкәннәр белән күмәк хезмәт эшчәнлегендә һәм көндәлек аралашу нәтиҗәсендә, балалар җитештерү һәм әхлак тәҗрибәсе туплаганнар. Ыруглык җәмгыяте урнашканга кадәр һәм ыруглар яшәгән чорда, әле тәҗрибә үзе дә чагыштырмача гади булган заманнарда да бу шулай була. Менә шуңа күрә бу чорда тәрбия эше аерым бер иҗтимагый бурыч буларак аерылып тормый һәм кешеләрнең профессиональ эшчәнлегенең махсус өлкәсен тәшкил итми, ягъни балалар өчен махсус тәрбия учреждениеләре дә, педагогик эшчәнлек белән махсус шөгыльләнүче һәм бала тәрбияләүне профессияләре иткән кешеләр дә булмый. Бу хәл колбиләүчелек чорында да озак вакытлар саклана.

Аннары кешелек җәмгыяте үсешенең билгеле бер баскычында, аерым алганда колбиләүчелек строеның соңгырак чорында, җитештерү һәм фән шактый үсеш алгач, тәрбия эше иҗтимагый вазифа буларак

аерылып чыга, ягъни махсус тәрбия бирү учрежде-ниеләре, балаларны өйрәтүче һәм аларга тәрбия бирүче профессия кешеләре барлыкка килә. Бу күп кенә борынгы илләрдә шулай була, әмма малайлар өчен ачылган мәктәпләр турындагы азмы-күпме мәгълүматлар безгә Якын Көнчыгыш илләреннән һәм борынгы Грециядән килеп җиткән.

Педагогик фикерләү теориясе башлангычларын философия нигезләрен-нән эзләргә кирәк, чөнки ул борынгы заманнардан ук тормышның мәгънәсе, кеше яшәешенең максатлары, җәмгыятьтә аның роле һәм урыны, кешене тормышта үз урынын табарга әзерләү турындагы сорауларга җавап эзләүче фән буларак билгеле.

Фәлсәфи фикерләү колбиләүчелек җәмгыятендә үк шактый үсеш ала. Төзек фәлсәфи система Сократ (безнең эрага кадәр 469-399 еллар). Платон (б. э. га кадәр 427-347 еллар), Аристотель (б. э. га кадәр 384-322 еллар), Демокрит (б. э. га. кадәр 460-370 еллар) кебек борынгы фикер ияләре тарафыннан тудырыла. Аларның фәлсәфи тәгълиматында кешене тәрбияләү, шәхес формалаштыру, аның тормыштагы урынын билгеләү мәсьәләләре белән бәйле идеяләр һәм принципларны табарга була.

Борынгы заман педагогикасы дин белән бәйле була: яхшы белән яман турындагы дини күзаллаулар бәян ителгән һәм дингә ышанучыларга гаилә һәм җәмгыять әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең аерым нормалары билгеләнгән изге китаплардан үзен-чәлекле педагогик васыятьләр, тәртип кагыйдәләре турында — кешеләр, балалар һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләр турында күрсәтмәләр табарга була.

Тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләре соңгырак гасырларда да күп кенә фикер ияләре, язучылар, галимнәрнең игътибарын – гәрчә аларның кайберләре тәрбия эшчәнлеге белән турыдан-туры шөгыльләнмәсәләр дә — үзенә даими җәлеп итеп килгән. Яңарыш чоры язучылары һәм фикер ияләре Витторино да-Фельтре (1378-1446) һәм Ф.Рабле (1494-1553), инглиз философы Дж. Локк (1632-1704), XVIII гасыр француз мәгърифәтчесе Ж. Ж. Руссо (1712-1778), К.А. Гельвеций (1715-1771), Д. Дидро (1713-1784) һәм башкалар бала табигате, аны тәрбияләүнең максаты, юллары һәм чаралары турындагы үзләренең якты уй-фикерләре белән педагогик фикерләү үсешенә йогынты ясадылар.

Педагогиканы фәннең бер тармагы буларак рәсмиләштерү иң элек бөек чех педагогы Ян Амос Коменский (1592-1670) исеме белән

бәйле. Аның "Олуг дидактика" исемле зур хезмәте хаклы рәвештә беренче фәнни педагогика китабы дип исәпләнә.

Педагогик фикерләү үсешендә һәм педагогиканың фән буларак форма-лашуында күренекле Швейцария педагогы И. Г. Песталоцци (1746-1827) һәм немец педагогы А. Дистервегның (1790-1866) хезмәтләре һәм педагогик эшчәнлек тәҗрибәсе зур әһәмияткә ия.

Педагогика теориясе үсешенә революциягә кадәрге Россиянең прогрессив педагог һәм мәгърифәтчеләре керткән казанышлар да зур. Л. Н. Толстой (1828-1910) крестьян балалары өчен мәктәп ача, күп кенә дәреслекләрне, шул исәптән мәшһүр "Әлифба" һәм арифметика дәреслеген үзе яза, патша мәктәпләрендә хөкем сөргән хәрефкә ябышып ятуга һәм коры формализмга каршы чыга. Балаларның иҗади сәләтен үстерергә чакыра, һәр баланың шәхесен ихтирам итәргә өйрәтә. Танылган рус хирургы һәм либераль җәмәгать эшлеклесе Н. И. Пирогов (1810-1881) төрле катлау балалар өчен билгеләнгән мәктәпләрне кискен тәнкыйтьләп чыкты, баланы "кеше итеп үстерергә" тиешле тәрбия эшенә гомуми карашларны тамырдан үзгәртү кирәклеген яклады.

Педагогика фәне үсешенә К. Д. Ушинский (1824-1870) керткән өлеш аеруча зур. Аның педагогик карашлары "Тәрбия җимеше буларак – кеше" исемле хезмәтендә бәян ителгән. Алар аның берничә буын балалар укып үскән, үзе төзегән уку китапларында, шулар исәбендә "Туган тел" һәм "Балалар дөньясы" дигән мәгълүм китапларында методик гәүдәләнеш таба.

К. Д. Ушинскийдан соң ук танылган татар галиме һәм мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров) (1825-1902) халыкчан тәрбия идеясен алга сөрә. Аның "Тәрбия китабы", "Әхлак рисаләсе", "Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре" дигән хезмәт-ләрендә татар халкының гуманистик педагогикасы турында гаять бай материал тупланган. Рус җәмәгатьчелеген татар халкының рухи мәдәнияте белән таныштыру максатыннан К. Насыйри күп кенә зирәк һәм хикмәтле сүзләрне русчага тәрҗемә итеп бирә.

Демократик педагогиканың формалашуына күренекле татар мәгърифәтчесе һәм язучысы Галимҗан Ибраһимовның (1887-1938) эшчәнлеге шактый йогынты ясады. Ул гуманлы тәрбиянең күп кенә юнәлешләрен җентекләп эшләде. Бу мәсьәләдә аның "Тәрбия эшендә иреклелек һәм гуманлылык нигезләре" дигән хезмәте игътибарга лаек.

Оешкан төстә алып барылган тәрбиягә озак еллар дәвамында балалар гына тартылып килде һәм шуңа күрә педагогиканы балаларга тәрбия бирү турындагы фән дип атыйлар иде. Ә хәзер исә, белем бирү һәм тәрбия балаларга гына түгел, асылда бөтен кешегә дә кагылганлыктан, педагогиканы кешене барлык үсеш баскычларында тәрбияләү турындагы фән дип әйтәләр. Педагогиканы болай аңлату бик актуаль, чөнки хәзерге чорда белем бирүнең мәктәпкәчә учреждениеләрдән башлап гомуми белем бирү, профессиональ белем бирү, хезмәт ияләренең квалификациясен күтәрүнең күптөрле формаларына кадәр барлык буыннарын эченә алган тулы бер системасы булдырыла.

Хәзерге заманда кешеләр тормышында бик җитди кыенлык килеп туа: фән һәм техниканың төрле тармакларында белемнәр күләме гадәттән тыш тиз үсә, шуңа күрә кешегә белем бирүдә, тәрбия, укыту эшендә элеккеге эчтәлек нигезендә, элекке алымнарны кулланып кына чордан калышмыйча алга бару кыенлана.

Педагогикада үсешләренең төрле баскычында балалар һәм яшьләрнең кешелек дөньясы туплаган рухи байлыктан нәрсәне үзләштерергә тиешлеген билгеләүдә яңа критерийлар булдыру зарури. Яшь буынны үзлегеннән белем алу һәм үз-үзен тәрбияләү ысуллары һәм алымнары, мөстәкыйль рәвештә фәнни эзләнүләргә, фәнни тикшеренүләргә тизрәк кереп китәргә булышырдай алымнар белән коралландыру мәсьәләсе аеруча кискен тора.

Хәзерге катлаулы шартларда педагогларның осталыгына таләп арта бара. Бүген педагоглар тәрбиясендәге балалар элеккеге чор балаларыннан аерылып тора, тормышның төрле өлкәләрендәге күренешләр һәм вакыйгалар турында, техник һәм фәнни казанышлар, әдәбият һәм сәнгать әсәрләре һ. б. турында мәгълүмат бирүче каналлар күп булу сәбәпле, хәзерге балалар иртә өлгерәләр, таләп һәм омтылышлары да җитдирәк була бара. Педагоглардан укучыларның танып-белү, интеллектуаль һәм гамәли эшчәнлек активлыгын үстерүгә исәпләнгән метод һәм алымнар куллану таләп ителә. Педагогика укытучыларны үз эшенең остасы итәргә тиеш тә. Ул теоретик фән генә түгел, ә гамәли фән дә (мәсәлән, медицина кебек).

Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнеп һәм гомумиләштереп, фәнни күзәтү һәм тәҗрибәләрдән файдаланып, педагогика белем, осталык һәм күнекмәләрне, үз-үзеңне тоту гадәтләрен үзләштерүдә, танып-белү сәләтен һәм дөньяга карашларны үстерүдә ныклы

нәтиҗәләр бирергә, белем һәм тәрбия ысулларын, аларны куллану шартларын табу һәм нигезләү мәсьәләсен хәл итәргә тиеш.

Хәзерге чорда яшь буынны тәрбияләүнең үзенчәлеге шул, бу эштә күп кенә көчләр: гаилә, иҗтимагый оешмалар һәм учреждениеләр катнаша. Педагоглар алар белән хезмәттәшлек итә. Педагогиканың бурычы — бергәләп эшләү дәверендә төп җаваплылык педагог-белгечләр өстенә төшүен истә тотып, әлеге хезмәттәшлекнең эчтәлеге һәм алымнары, вазифаларны бүлешү һәм көчләрне берләштерү мәсьәләләрен хәл итү.

Барлык өлкәләрдә белемнәрнең күпләп туплануына һәм фәнни-тикшеренүләр күләменең бик тиз үсүенә бәйле рәвештә фәннәрнең дифференциацияләнүе һәм специальләшүе, ягъни кайчандыр бердәм исәпләнгән төп фәннең күп кенә аерым тармакларга бүленүе һәм аларның мөстәкыйль фән буларак үсә башлавы торган саен ныграк сизелә.

Соңгы елларда педагогика фәнендә да специальләшү һәм дифференциацияләнү сизелерлек үсә. Әле чагыштырмача күптән түгел генә философиянең бер өлешен тәшкил иткән педагогиканың хәзерге вакытта аерым бер юнәлештә үсә башлаган күпсанлы тармаклары барлыкка килде. Аларның инде кайберләре, мәсәлән, мәктәп педагогикасы, мәктәпкәчә яшьтәге балалар педагогикасы кебекләре мөстәкыйль педагогик фән булып танылдылар. Башкалары исә, төрле категориядәге укучыларны тәрбияләү үзенчәлекләрен чагылдыру зарурлыгыннан килеп чыгып, әлегә формалашу һәм фәнни тармакның предметын ачыклау баскычында гына торалар. Мәсәлән, өлкәннәр педагогикасы һәм аңарда мөстәкыйль тармак буларак тиз үсә баручы югары мәктәпләр педагогикасы шундыйлардан санала.

Педагогиканы, тәрбияләнүчеләрнең яшенә карап, мәктәпкәчә яшьтәгеләр педагогикасы, мәктәп яшендәгеләр педагогикасы (яисә мәктәп педагогикасы) һәм өлкәннәр педагогикасына бүлеп йөртәләр.

Яшьләрне төрле уку йортларында укыту һәм тәрбияләүнең билгеле бер үзенчәлекләренә бәйле рәвештә билгеле бер яшьтәгеләр группаларын тәрбияләүдәге аерымлыкларны өйрәнүче педагогикадан шушы үзенчәлекне чагылдырган тармаклар бүленеп чыга. Мәсәлән, мәктәп педагогикасыннан профессиональ-техник училище шартларында укыту-тәрбия эше барышының үзенчәлекләрен чагылдырган профтехбелем педагогикасы бүленеп чыга.

Халык хуҗалыгы һәм мәдәниятнең барлык өлкәләрендә кадрларның белемен күтәрү системасы барлыкка килде, шуңа бәйле әлеге системада эшләүче белгечләрне өйрәтүне оештыру һәм аның методикасының үзенчәлекләре игътибарны җәлеп итә. Бу исә өлкәннәр педагогикасының, ягъни өзлексез белем күтәрү педаго-гигасының аерым тармагын өйрәнү предметы булырга тиеш. Ул формалаша башлады гына әле.

Аерым предмет методикалары — конкрет фәннәрне укыту һәм өйрәтү закончалыклары турындагы фәннәр дә педагогика тармакларына керә.

Хәзерге вакытта мәктәптә өйрәнелә торган төп уку предметлары методикасы (физика, химия, география, тарих һ. б. укыту методикасы) аеруча анык формалашкан.

Аерым курслар (мәсәлән, югары уку йортларында философия, педагогика, психология һәм күп кенә башка фәннәр буенча) укыту методикалары да барлыкка килә башлады. Гомуми мәктәпләрдә укырга комачауларлык дәрәҗәдә күрү, ишетү, сөйләм сәләте бозылган, шулай ук психикасы какшаган балаларны укыту, тәрбияләү һәм аларны хезмәткә әзерләү үзенчәлекләрен тикшерүче фән педагогик фәннәрнең махсус группасына карый. Педагогиканың тармаклары махсус педагогика яисә дефектология дигән гомуми исем астында йөртелә.

Дефектология үз чиратында аерым мөстәкыйль тармакларга бүленә: чукрак-телсез һәм чукрак балаларны укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләре белән — сурдопедагогика, сукырлар белән — тифлопедагогика, акылы зәгыйфьләр белән — олигофренопедагогика, тотлыгучы һәм сакау балалар белән — логопедия шөгыльләнә.

Үзенең тикшерү өлкәсе булган, мөстәкыйль һәм инде шактый үсеш алган фән булуына карамастан, педагогика башка фәннәрдән аерым үсә алмый. Педагогларның эшчәнлек объекты булып физик һәм акыл ягыннан үсеп килүче шәхес тора, шуңа күрә педагогика барыннан да элек кешене өйрәнүче фәннәр белән тыгыз бәйләнгән.

Җәмгыять әгъзасы буларак кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны турын-дагы мәсьәлә белән иҗтимагый фәннәр шөгыльләнә; биологик үсешнең бер продукты буларак, кеше биология фәненең, нигезендә физиологиянең өйрәнү объекты булса, үзенең эчке дөньясы белән һәм фикер йөртү сәләтенә ия буларак ул психологиянең өйрәнү объекты булып тора.

Нәкъ менә шуңа күрә дә әлеге фәннәр булачак педагоглар өчен уку предметы булып торалар, гомуми һәм профессиональ әзерлек буенча аларның уку планына кертелгәннәр.

Бу багланышлар нәрсәдә чагыла соң? Философия, барыннан да элек, башка фәннәр кебек үк, педагогиканың да методологик нигезе. Философия һәм педагогиканың кешене тәрбияләү максатлары проблемасы, фәнни караш формалаштыру проблемасы, коллектив һәм шәхеснең үзара элемтәсе, кешенең әйләнә-тирә чынбарлыкны танып-белү формаларының берсе буларак, укучыларның танып-белү теориясен эшләү белән бәйләнгән гносеологик проблемалар кебек күп кенә уртак проблемалары бар.

Педагогика шулай ук яшьләргә әхлакый, эстетик тәрбия бирү бурычларын хәл итүдә булыша торган этика, эстетика кебек философиянең чагыштырмача мөстәкыйль тармаклары белән дә тыгыз бәйләнгән.

Социаль тирәлекнең кешегә йогынтысын, кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын өйрәнүче социология белән дә педагогиканың багланышлары ныгый.

Педагогик социология, педагогика һәм социология чигендә барлыкка килгән яңа фән буларак, җәмгыятьнең социаль үзгәрешләр процессы барышы, кешеләрнең профессиональ мәшгульлеге турындагы социологик тикшеренү мәгълүматларын һәм нәтиҗәләрен мәктәп, гаилә һәм җәмәгатьчелек хәл итәргә тиешле тәрбия мәсьәләләренә күчерә.

Педагогика шулай ук экономика белән дә, атап әйткәндә, аның халык мәгарифе экономикасы дип йөртелгән тармагы белән дә тыгыз бәйләнгән. Халык мәгарифе экономикасы мәгълүматлары балаларны алты яшьтән укыта башлауга бәйле рәвештә чыгымнар үсешен, мәктәпләрнең структурасын һәм классларда укучылар, укытучылар санын билгеләү, мәктәп биналарын төзү һәм башка чыгымнарны билгеләү өчен кирәк.

Бу мәсьәләләрне хәл иткәндә педагогика да, экономика да туу, үлем-җитем, күченүләр кебек халык саны проблемаларын өйрәнә торган демография мәгълүматларына таяна. Туучылар санын, халыкның яшь үзенчәлекләрен, күченүләрне исәпкә алмыйча һәм фараз итмичә генә мәктәпләр төзү, тиешле санда укытучылар әзерләү мәсьәләләрен хәл итү мөмкин түгел.

Биология фәннәре, аерып әйткәндә физиология, педагогика һәм психология өчен табигый-фәнни база итеп карала.

Укыту һәм тәрбия эшенең конкрет мәсьәләләрен хәл итү, ял режимы төзү өчен яшь чорлары физиологиясе (ул балалар, яшүсмерләр, егетләр һәм кызлар организмының төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнә) һәм мәктәп гигиенасы (мәктәптә барлык төр дәресләрдә гигиена мәсьәләләрен — укыту-тәрбия режимына һәм шартларына бәйле рәвештә укучыларның сәламәтлеген, физик үсешен һәм эшкә сәләтен өйрәнә) аеруча зур әһәмияткә ия.

Педагогиканың психология белән бәйланышлары күптәннән килә. Педагогика өчен яшь чорлары психологиясе һәм педагогик психология бик әһәмиятле. Яшьләренә карап максатка юнәлдерелгән укыту һәм тәрбия шартларында балаларның психик үсеш закончалыкларын педагогик психология өйрәнә.

Соңгы елларда кеше һәм техниканың үзара мөнәсәбәтләрен тикшерүче инженерлык психологиясе белән педагогика арасында элемтәләр ныгый бара. Психологиянең бу тармагы биргән мәгълүматлар педагогикага хәзерге мәктәпләрдә техник чаралар кертүнең фәнни методикасын эшләргә ярдәм итә.

Кешенең шәхси үзенчәлекләрен өйрәнүче дифференциалъ психология педагогиканы һәр укучыга индивидуаль якын килү алымнарын тормышка ашыруда зарури мәгълүматлар белән коралландыра.

Төрле группалардагы балаларның шәхес булып өлгерү үзенчәлекләрен өйрәнеп, социаль психология укучыларны коллективта тәрбияләү проблемаларын тикшерү һәм аларны коллектив аша тәрбияләү методикасын эшләү өчен күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар һәм фактлар белән педагогиканы баета.

Катлаулы динамик системаларны идарә итү турындагы фән — кибернетика белән дә соңгы елларда педагогиканың элемтәләре урнашты. Кибернетиканың гомуми идеяләрен педагогикада куллануның гамәли нәтиҗәләреннән берсе — программалы укыту булды.

Педагогиканың башка фәннәр белән бәйланышларында этнография һәм фольклористика фәннәре аерым урын алып тора. Халык традицияләрен, төрле халыкларның йолаларын һәм гореф-гадәтләрен, халык иҗаты ядкәрләрен өйрәнү педагогиканың аерым бер тармагы — халык мәдәнияте ядкәрләренең педагогик асылын өйрәнә

торган халык педагогикасы дигән тармагы өчен чыганак һәм нигез булып тора.

Болар барысы да үз предметы һәй тикшеренү өлкәсе булган педагогиканың чиктәш фәннәр белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә. Төрле факторлар йогынтысында бара торган кеше үсешенең аерым якларын өйрәнүче башка фәннәрдән аермалы буларак, педагогика гомумән кеше белән эш итә һәм кешенең тулы канлы шәхес булып формалашуының иң нәтиҗәле юлларын эзли.

Педагогиканың башка фәннәр белән багланыш формалары төрле-төрле һәм түбәндәгеләрне эченә ала:

- фәнни идеяне алу һәм аны педагогикада иҗади файдалану (мәсәлән, кибернетик идарә идеясе);
- башка фәннәр туплаган мәгълүматлардан файдалану (мәсәлән, төрле яшьтәге укучыларның эшкә сәләте турында физиология мәгълүматлары);
- башка фәннәрнең методикасыннан файдалану (мәсәлән, математик ысуллардан);
- уртак проблемаларны педагогика белән бергәләп хәл итү өчен ике яисә берничә фәннең көчләрен берләштерү (мәсәлән, мәктәп балаларын системалы укытуны тагын да иртәрәк башлау мөмкинлекләрен өйрәнү өчен психология, физиология һәм педагогиканың бергә эшләве);
- педагогик күренешләрнең асылы турындагы күзаллауларны баету һәм тирәнәйтү өчен яисә яңаларын билгеләү өчен башка фәннәрнең терминнарын һәм төшенчәләрен файдалану (мәсәлән, кибернетикадан алынган кайтма бәйләнеш турында төшенчә).

Педагогика чиктәш фәннәрнең материалларын һәм мәгълүматларын әзер хәлендә түгел, ә аларны җентекләп сайлап алу, махсус педагогика күзлегеннән чыгып эшкәртү нигезендә, аларны педагогикада куллану шартларын һәм чикләрен ачыклагач кына файдалана.

**1.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. Что представляет собой педагогический процесс с точки зрения К.Д. Ушинского, В.П. Вахтерова, П.Ф. Лесгафта, К.Н. Вентцеля?
2. В 20-е годы советская школа получила название Единая трудовая школа. Объясните, в чем суть этого названия?
3. Почему педагогику С.Т. Шацкого называют социальной педагогикой?

**1.2. Задания для практики.**

Охарактеризуйте школьную систему в России на рубеже XIX – XXI вв.

**Методические рекомендации по написанию эссе**

**Введение**

Эссе от французского "essai", англ. "essay", "assay" - попытка, проба, очерк; от латинского "exagium" - взвешивание. Создателем жанра эссе считается М.Монтень ("Опыты", 1580 г.). Это прозаическое сочинение - рассуждение небольшого объема со свободной композицией. Жанр критики и публицистики, свободная трактовка какой-либо проблемы. Эссе выражает индивидуальные впечатления и соображения по конкретному поводу или вопросу и заведомо не претендует на определяющую или исчерпывающую трактовку предмета. Как правило, эссе предполагает новое, субъективно окрашенное слово о чем-либо и может иметь философский, историко-биографический, публицистический, литературно-критический, научно-популярный, беллетристический характер. Эссе студента - это самостоятельная письменная работа **на тему, предложенную преподавателем (тема может быть предложена и студентом, но обязательно должна быть согласована с преподавателем). Цель эссе состоит в развитии навыков самостоятельного творческого мышления и письменного изложения собственных мыслей.** Писать эссе чрезвычайно полезно, поскольку это позволяет автору научиться четко и грамотно формулировать мысли, структурировать информацию, использовать основные категории анализа, выделять причинно-следственные связи, иллюстрировать понятия соответствующими примерами, аргументировать свои выводы; овладеть научным стилем речи. Эссе должно содержать: четкое изложение сути поставленной проблемы, включать самостоятельно проведенный анализ этой проблемы с использованием концепций и аналитического инструментария, рассматриваемого в рамках дисциплины, выводы, обобщающие авторскую позицию по поставленной проблеме. В зависимости от специфики дисциплины формы эссе могут значительно дифференцироваться. В некоторых случаях это может быть анализ имеющихся статистических данных по изучаемой проблеме, анализ материалов из средств массовой информации и использованием изучаемых моделей, подробный разбор предложенной задачи с развернутыми мнениями, подбор и детальный анализ примеров, иллюстрирующих проблему и т.д.

**Тема эссе**

Тема не должна инициировать изложение лишь определений понятий, ее цель — побуждать к размышлению. Тема эссе должна содержать в себе вопрос, проблему, мотивировать на размышление.

**Построение эссе**

Построение эссе - это ответ на вопрос или раскрытие темы, которое основано на классической системе доказательств.

**Структура эссе:**

**Титульный лист**

**Введение** - суть и обоснование выбора данной темы, состоит из ряда компонентов, связанных логически и стилистически; На этом этапе очень важно правильно **сформулировать вопрос, на который вы собираетесь найти ответ в ходе своего исследования.** При работе над введением могут помочь ответы на следующие вопросы: «Надо ли давать определения терминам, прозвучавшим в теме эссе?»,«Почему тема, которую я раскрываю, является важной в настоящий момент?», «Какие понятия будут вовлечены в мои рассуждения по теме?»,« Могу ли я разделить тему на несколько более мелких подтем?».

**Основная часть** - теоретические основы выбранной проблемы и изложение основного вопроса. Данная часть предполагает развитие аргументации и анализа, а также обоснование их, исходя из имеющихся данных, других аргументов и позиций по этому вопросу. В этом заключается основное содержание эссе и это представляет собой главную трудность. Поэтому важное значение имеют подзаголовки, на основе которых осуществляется структурирование аргументации; именно здесь необходимо обосновать (логически, используя данные или строгие рассуждения) предлагаемую аргументацию/анализ. Там, где это необходимо, в качестве аналитического инструмента можно использовать графики, диаграммы и таблицы. В зависимости от поставленного вопроса анализ проводится на основе следующих категорий: Причина — следствие, общее — особенное, форма — содержание, часть — целое, Постоянство — изменчивость. В процессе построения эссе необходимо помнить, что один параграф должен содержать только одно утверждение и соответствующее доказательство, подкрепленное графическим и иллюстративным материалом. Следовательно, наполняя содержанием разделы аргументацией (соответствующей подзаголовкам), необходимо в пределах параграфа ограничить себя рассмотрением одной главной

мысли. Хорошо проверенный (и для большинства — совершено необходимый) способ построения любого эссе — использование подзаголовков для обозначения ключевых моментов аргументированного изложения: это помогает посмотреть на то, что предполагается сделать (и ответить на вопрос, хорош ли замысел). Такой подход поможет следовать точно определенной цели в данном исследовании. Эффективное использование подзаголовков - не только обозначение основных пунктов, которые необходимо осветить. Их последовательность может также свидетельствовать о наличии или отсутствии логичности в освещении темы. **Заключение** - обобщения и аргументированные выводы по теме с указанием области ее применения и т.д. Подытоживает эссе или еще раз вносит пояснения, подкрепляет смысл и значение изложенного в основной части. Методы, рекомендуемые для составления заключения: повторение, иллюстрация, цитата, впечатляющее утверждение. Заключение может содержать такой очень важный, дополняющий эссе элемент, как указание на применение (импликацию) исследования, не исключая взаимосвязи с другими проблемами.

**Структура аппарата доказательств, необходимых для написания эссе**

Доказательство - это совокупность логических приемов обоснования истинности какого-либо суждения с помощью других истинных и связанных с ним суждений. Оно связано с убеждением, но не тождественно ему: аргументация или доказательство должны основываться на данных науки и общественно-исторической практики, убеждения же могут быть основаны на предрассудках, неосведомленности людей в вопросах экономики и политики, видимости доказательности. Другими словами, доказательство или аргументация - это рассуждение, использующее факты, истинные суждения, научные данные и убеждающее нас в истинности того, о чем идет речь. Структура любого доказательства включает в себя три составляющие: тезис, аргументы и выводы или оценочные суждения. **Тезис**— это положение (суждение), которое требуется доказать. **Аргументы** — это категории, которыми пользуются при доказательстве истинности тезиса. **Вывод** — это мнение, основанное на анализе фактов. **Оценочные суждения** — это мнения, основанные на наших убеждениях, верованиях или взглядах. **Аргументы** обычно делятся на следующие группы:

1. **Удостоверенные факты** — фактический материал (или статистические данные). Факты — это питательная среда для выяснения тенденций, а на их основании - законов в различных областях знаний, поэтому мы часто иллюстрируем действие законов на основе фактических данных.
2. **Определения** в процессе аргументации используются как описание понятий, связанных с тезисом.
3. **Законы** науки и ранее доказанные теоремы тоже могут использоваться как аргументы доказательства.

**Виды связей в доказательстве**

Для того чтобы расположить тезисы и аргументы в логической последовательности, необходимо знать способы их взаимосвязи. Связь предполагает взаимодействие тезиса и аргумента и может быть прямой, косвенной и разделительной. Прямое доказательство — доказательство, при котором истинность тезиса непосредственно обосновывается аргументом. Например: мы не должны идти на занятия, так как сегодня воскресенье. Метод прямого доказательства можно применять, используя технику индукции, дедукции, аналогии и

причинно-следственных связей. Индукция — процесс, в результате которого мы приходим к выводам, базирующимся на фактах. Мы движемся в своих рассуждениях от частного к общему, от предположения к утверждению. Общее правило индукции гласит: чем больше фактов, тем убедительнее аргументация.

Дедукция — процесс рассуждения от общего к частному, в котором вывод обычно строится с опорой на две предпосылки, одна из которых носит более общий характер. Например, *все люди, ставящие перед собой ясные цели и сохраняющие присутствие духа во время критических ситуаций, являются великими лидерами. По свидетельству многочисленных современников, такими качествами обладал А. Линкольн - один из самых ярких лидеров в истории Америки.* Аналогия - способ рассуждений, построенный на сравнении. Аналогия предполагает, что если объекты Л и Б схожи по нескольким направлениям, то они должны иметь одинаковые свойства. Необходимо помнить о некоторых особенностях данного вида аргументации: направления сравнения должны касаться наиболее значительных черт двух сравниваемых объектов, иначе можно прийти к совершенно абсурдному выводу. Причинно-следственная аргументация - аргументация с помощью объяснения причин того или иного явления (очень часто явлений, находящихся во взаимозависимости).

**Требования к фактическим данным и другим источникам**

При написании эссе чрезвычайно важно то, как используются эмпирические данные и другие источники (особенно качество чтения). Все (фактические) данные соотносятся с конкретным временем и местом, поэтому прежде, чем их использовать, необходимо убедится в том, что они соответствуют необходимому для исследований времени и месту. Соответствующая спецификация данных по времени и месту — один из способов, который может предотвратить чрезмерное обобщение, результатом которого может, например, стать предположение о том, что все страны по некоторым важным аспектам одинаковы (если вы так полагаете, тогда это должно быть доказано, а не быть голословным утверждением). Всегда можно избежать чрезмерного обобщения, если помнить, что в рамках эссе используемые данные являются иллюстративным материалом, а не заключительным актом, т.е. они подтверждают аргументы и рассуждения и свидетельствуют о том, что автор умеет использовать

данные должным образом. Нельзя забывать также, что данные, касающиеся спорных вопросов, всегда подвергаются сомнению. От автора не ждут определенного или окончательного ответа. Необходимо понять сущность фактического материала, связанного с этим вопросом (соответствующие индикаторы? насколько надежны данные для построения таких индикаторов? к какому заключению можно прийти на основании имеющихся данных и индикаторов относительно причин и следствий? и т.д.), и продемонстрировать это в эссе. Нельзя ссылаться на работы, которые автор эссе не читал сам.

**Как подготовить и написать эссе?**

Качество любого эссе зависит от трех взаимосвязанных составляющих, таких как:

- исходный материал, который будет использован (конспекты прочитанной литературы, лекций, записи результатов дискуссий, собственные соображения и накопленный опыт по данной проблеме);
- качество обработки имеющегося исходного материала (его организация, аргументация и доводы);
- аргументация (насколько точно она соотносится с поднятыми в эссе проблемами).

Процесс написания эссе можно разбить на несколько стадий: обдумывание — планирование — написание — проверка — правка. **Планирование** — определение цели, основных идей, источников информации, сроков окончания и представления работы. **Цель** должна определять действия. **Идеи**, как и цели, могут быть конкретными и общими, более абстрактными. Мысли, чувства, взгляды и представления могут быть выражены в форме аналогий, ассоциации, предположений, рассуждений, суждений, аргументов, доводов и т.д. Аналогии — выявление идеи и создание представлений, связь элементов значений. Ассоциации — отражение взаимосвязей предметов и явлений действительности в форме закономерной связи между нервно — психическими явлениями (в ответ на тот или иной словесный стимул выдать« первую пришедшую в голову» реакцию). Предположения — утверждение, не подтвержденное никакими доказательствами. Рассуждения — формулировка и доказательство мнений. Аргументация - ряд связанных между собой суждений, которые высказываются для того, чтобы убедить читателя (слушателя) в верности (истинности) тезиса, точки зрения, позиции. Суждение — фраза или предложение, для которого имеет смысл вопрос: истинно

или ложно? Доводы — обоснование того, что заключение верно абсолютно или с какой-либо долей вероятности. В качестве доводов используются факты, ссылки на авторитеты, заведомо истинные суждения (законы, аксиомы и т.п.), доказательства (прямые, косвенные,«от противного»,«методом исключения») и т.д. Перечень, который получится в результате перечисления идей, поможет определить, какие из них нуждаются в особенной аргументации. Источники. Тема эссе подскажет, где искать нужный материал. Обычно пользуются библиотекой, Интернет-ресурсами, словарями, справочниками. Пересмотр означает редактирование текста с ориентацией на качество и эффективность. Качество текста складывается из четырех основных компонентов: ясности мысли, внятности, грамотности и корректности. Мысль - это содержание написанного. Необходимо четко и ясно формулировать идеи, которые хотите выразить, в противном случае вам не удастся донести эти идеи и сведения до окружающих. Внятность — это доступность текста для понимания. Легче всего ее можно достичь, пользуясь логично и последовательно тщательно выбранными словами, фразами и взаимосвязанными абзацами, раскрывающими тему. Грамотность отражает соблюдение норм грамматики и правописания. Если в чем-то сомневаетесь, загляните в учебник, справьтесь в словаре или руководстве по стилистике или дайте прочитать написанное человеку, чья манера писать вам нравится. Корректность — это стиль написанного. Стиль определятся жанром, структурой работы, целями, которые ставит перед собой пишущий, читателями, к которым он обращается.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 1» , добавить вопросы для самоконтроля.

**1.3. Глоссарий по теме 1.**

**История педагогики** — отрасль педагогической науки, изучающая состояние и развитие теории и практики воспитания и обучения подрастающего поколения на разных ступенях развития человеческого общества. Источниками исследования являются: официальные материалы и нормативные документы, относящиеся к сфере образования; учебники, учебные пособия, программы; труды педагогов, педагогическая пресса; архивные материалы, мемуарная и критическая литература.

**История развития** — наука о развитии жизни в ходе истории развития Земли и о развитии отдельных существ, индивидов.

**Образование** — 1) процесс и результат усвоения определенной системы знаний в интересах человека, общества и государства, сопровождающиеся констатацией достижения гражданином (обучающимся) установленных государством образовательных уровней (цензов). О. получают в основном в процессе обучения и воспитания в учебных заведениях под руководством педагогов. Однако все возрастающую роль играет и самообразование, т. е. приобретение системы знаний самостоятельно; 2) специально организованная в обществе система условий и учебно-образовательных, методических и научных органов и учреждений, необходимых для развития человека; 3) процесс изменения, развития, совершенствования сложившейся системы знаний и отношений в течение всей жизни, абсолютная форма бесконечного, непрерывного овладения новыми знаниями, умениями и навыками в связи с изменяющимися условиями жизни, ускоряющимся научно-техническим прогрессом; 4) многообразная личностно ориентированная деятельность, обеспечивающая самоопределение, саморазвитие и самореализацию человека в динамичной социокультурной среде; становление, развитие, рост самой личности как таковой; 5) формирование образа мыслей, действий человека в обществе; создание человека в соответствии с его качеством, мерой, сущностью, раскрываемой в каждый конкретный исторический отрезок до определенного уровня (Н.П. Пищулин). **Образование глобальное** — формирование у учащихся понимания мира на основе *холистических* (восприятие мира как единого целого) и *гуманистических* взглядов. Концепция О. г. ориентирована на выработку у учащихся осознания, что Земля является общим домом для всех жителей планеты, все люди — одна семья и каждый человек способен активно участвовать в мироустройстве. *Коммуникация, контакт, понимание, эмпатия, симпатия, солидарность, сотрудничество* являются основными понятиями О. г. **Образование дополнительное** — образовательные программы и услуги, реализуемые в целях всестороннего удовлетворения образовательных потребностей граждан, общества и государства в общеобразовательных учреждениях профессионального образования за пределами определяющих их статус основных образовательных

программ, в образовательных учреждениях О. д.: учреждения повышения квалификации, курсы, центры профессиональной ориентации, музыкальные и художественные школы, школы искусств, дома детского творчества, станции юных техников, станции юных натуралистов и т. п. (Закон РФ «Об образовании»). **Образование классическое** — тип общего среднего образования, предусматривающий систематическое изучение древних языков и математики в качестве главных предметов. **Образование непрерывное** — целенаправленное получение человеком знаний, умений и навыков в течение всей жизни в учебных заведениях и путем организованного самообразования. Цель О. н. — поддержание общественно и индивидуально необходимого уровня культуры, общеобразовательной и профессиональной подготовки. Организуется на принципах всеобщности, демократизма, доступности, непрерывности, интегративности, преемственности, принципа самообразования, гибкости и оперативности. **Образование политехническое** — образование, ориентированное на знакомство учащихся с основными принципами организации современного производства, безотходных и экологически чистых технологий, обучение навыкам обращения с компьютерной техникой и простейшими современными орудиями механизированного и автоматизированного труда.

### 1.4. Использованные информационные ресурсы.


1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования / Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.
8. Хузиахметов А.Н. Мәгариф тарихы һәм фәлсәфәсе. – Казань, 1998

**Тема 2.** ***БОРЫНГЫ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ***

**Аннотация.** В данной теме рассматривается воспитание в Древнем обществе.

**Ключевые слова.** Концепции воспитания, обычаи, старшее поколение, опыт.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

## *БОРЫНГЫ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ*

Кайбер галимнәрнең тәрбиянең барлыкка килүе хакындагы күп кенә концепцияләре кеше үсеше турында вульгар-эволюцион күзаллаулар йогынтысында туган. Бу исә тәрбиянең социаль асылына әһәмият бирмәүгә, тәрбия процессын биологияләштерүгә китерә.

Хайваннар дөньясында өлкән буыннарның яшь буынга әйләнә-тирә мохиткә җайлашу күнекмәләрен бирүне "кайгыртуы" турындагы җентекләп җыелган фактик материалларга таянып, андый концепция тарафдарлары (мәсәлән, Ш. Летурно, А. Эспинас) хайваннарның инстинкта буйсынып кылган эш-гамәлләрен борынгы кешеләрнең тәрбия практикасы белән тиңләштерәләр, шулай итеп тәрбиянең бердәнбер нигезе — кешеләрнең нәсел дәвам итүгә омтылышы һәм табигый сайланыш законы дигән ялгыш нәтиҗәгә киләләр.

Кайбер галимнәр арасында, шулай ук балаларның актив рәвештә өлкәннәргә охшарга омтылышы тәрбия нигезе булып тора, дигән фикер киң таралган. Шул рәвешле, тәрбия барлыкка килү сәбәпләрен биологиягә бәйләп аңлатуга психологиягә бәйләп аңла-ту каршы куела. Бу теориягә, социаль күренешнең барлыкка килүен фәкать психологик факторлар белән генә аңлатырга тырышуның теләсә нинди омтылышлары кебек үк, ачыктан-ачык идеализм хас. Гәрчә, әлбәттә, тәрбия процессында, балаларның яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу процессында охшарга тырышу, охшату элементларының барлыгын да инкарь итеп булмый.

Борынгы кешеләрнең хезмәт эшчәнлеге һәм шул процесста формалашкан иҗтимагый мөнәсәбәтләр тәрбия барлыкка килүнең төп

шарты булып тора. "Маймылның кешегә әверелү процессында хезмәтнең роле" дигән классик хезмәтендә Ф. Энгельс "хезмәт кешене тудырган" дип яза. Кеше формалашуның биологик алшартлары хезмәт аркасында хайвани халәттән кеше халәтенә күчүнең нигезе булып хезмәт итә алган. Кеше хезмәт кораллары ясый башлаган чордан кешелек җәмгыяте барлыкка килгән.

Борынгы кешеләрнең яшәүгә һәм үрчүгә булган табигый ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлгән хезмәт эшчәнлеге кешелек җәмгыятен тудырган, анда кешенең формалашуы социаль закончалыклар белән билгеләнә башлаган. Иң гади хезмәт кораларын куллану һәм аларны аңлы рәвештә күбрәк, катлаулырак итеп ясау хезмәт күнекмәләрен һәм тәҗрибәне үсеп килүче буыннарга тапшыру зарурлыгын тудырган.

Башта бу хезмәт эшчәнлеге, көнкүреш һәм иҗтимагый тормыш процессында барган. Тора-бара тәрбия кеше эшчәнлегенең һәм кеше аңының аерым өлкәсенә әверелә.

Борынгы җәмгыять үсешенең беренче баскычында — ыруглык җәмгыятенә кадәр — кешеләр табигатьнең әзер продуктларын үзләштергәннәр, ауга йөргәннәр. Яшәү чыганаклары табу процессы үзенчә гади дә, шул ук вакытта катлаулы да булган. Эре ерткычларны аулау, табигать көчләре белән көрәшү күмәкләп тормыш итү, эшләү һәм куллану шартларында гына тормышка ашырыла алган. Бөтен нәрсә уртак булган, коллектив әгъзалары арасында социаль аерымлыклар булмаган.

Борынгы җәмгыятьтә иҗтимагый мөнәсәбәтләр кан кардәшлеге белән тәңгәл килә. Анда хезмәт һәм социаль функцияләр бүленеше табигый биологик нигезләрдә корыла, шуның нәтиҗәсендә ирләр һәм хатын-кызлар арасында хезмәт бүленеше, шул рәвешле иҗтимагый коллективның яшь буенча бүленеше яши.

Ыруглык строена кадәр җәмгыять яшь буенча өч төркемгә бүленгән: балалар һәм яшүсмерләр; тормышта, хезмәттә тулы кыйммәтле һәм тулы хокуклы катнашучылар; уртак тормышта тулы кыйммәтле катнашырга җитәрлек физик көчләре булмаган өлкән-нәр һәм картлар (борынгы җәмгыять строе үсешенең алдагы баскычларында яшь буенча төркемнәр саны арта).

Кеше, тугач, иң элек үсеп килүчеләр һәм картаючыларның уртак төркеменә эләгә, ул шунда яшьтәшләре һәм тәҗрибәле картлар белән аралашып үсә.

Тиешле биологик яшькә җитеп, беркадәр аралашу тәҗрибәсе, хезмәт күнекмәләре алгач һәм тормыш кагыйдәләре, гореф-гадәтләр белән танышкач, кеше икенче яшь төркеменә күчкән. Күпмедер вакытлардан соң бу күчеш чорында инициацияләр, "багышлаулар" булган, ягъни яшьләрнең тормышка әзерлекләре: мохтаҗлыклар, авыртуларын кичерә белүләре, батырлык, чыдам-лык күрсәтә белүләре саналган.

Бер яшь төркеме әгъзалары белән икенче яшь төркеме әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр язылмаган, әмма катгый үтәлә торган гореф-гадәтләр һәм традицияләр белән көйләнгән, ул гореф-гадәтләрне туып килүче социаль нормалар ныгыткан.

Ыруглык строена кадәрге җәмгыятьтә әле табигый сайланыш һәм мохиткә җайлашуның биологик механизмнары да кеше үсешенең хәрәкәтләндерүче көчләреннән берсе булып кала. Ләкин җәмгыять үсә барган саен, анда формалашучы социаль закон-чалыклар һаман зуррак роль уйный башлый, әкренләп беренче урынга ук чыгалар.

Борынгы җәмгыятьтә бала үзенең тереклек эшчәнлеге, өлкәннәр эшенә катнашу, алар белән көндәлек аралашу процессында тәрбия һәм белем алган. Ул, соңрак кабул ителгәнчә, тормышка әзерләнеп кенә калмаган, ә үзе булдыра алган эшчәнлеккә турыдан-туры катнашып киткән, өлкәннәр белән, алар җитәкчелегендә күмәк хезмәткә, күмәк көнкүрешкә өйрәнгән. Бу җәмгыятьтә һәммә нәрсә күмәк булган. Балалар да бөтен ыругныкы исәпләнгән: алар башта — ана ыругыныкы, аннары ата ыругыныкы булганнар. Хезмәттә һәм өлкәннәр белән көндәлек аралашуда балалар һәм яшүсмерләр үзләренә кирәкле тормыш һәм хезмәт күнекмәләрен үзләштергәннәр, гореф-гадәтләр белән танышканнар, борынгы кешеләр тормышындагы йолаларны һәм үзләренең барлык вазифаларын башкарырга, үзләрен тулысынча ыруг мәнфәгатьләренә, өлкәннәр таләбенә буйсындырырга өйрәнгәннәр.

Малайлар өлкән ирләр белән беррәттән ауга, балыкка йөргәннәр, корал ясаганнар, кызлар исә өлкән хатын-кызлар җитәкчелегендә азык җыйганнар, уңыш үстергәннәр, ризык әзерләгәннәр, савыт-саба ясаганнар, кием теккәннәр.

Матриархат үсешенең соңгы этапларында яшь буын яши һәм укый торган беренче оешмалар — яшьләр йортлары барлыкка килгән. Малайлар өчен аерым, кызлар өчен аерым ул йортларда балалар

ыругның иң өлкән кешеләре җитәкчелегендә тормышка, хезмәткә, "багышлауларга" әзерләнгәннәр.

Патриархаль ыруглык җәмгыяте стадиясендә терлекчелек, җир эшкәртү, һөнәрчелек барлыкка килә. Җитештерүче көчләрнең үсеше һәм кешеләрнең хезмәт тәҗрибәләре киңәюгә бәйле рәвештә тәрбия дә катлаулана, ул инде күпьяклырак һәм планлы төс ала. Балалар терлек карарга, җир эшкәртергә, һөнәргә өйрәнәләр. Яхшырак оешкан тәрбиягә ихтыяҗ тугач, ыруглык общинасы үсеп килүче буынны тәрбияләү эшен тәҗрибәлерәк кешеләргә тапшырган. Алары, хезмәт күнекмәләре бирү белән бергә, балаларны туып килүче дини культ кагыйдәләре, риваятьләр белән таныштырганнар, язарга өйрәткәннәр. Риваятьләр, уен һәм биюләр, музыка һәм җыр, бөтен халык авыз иҗаты әхлак, үз-үзләрен тоту, билгеле бер характер тәрбияләүдә бик зур роль уйнаган.

Үсеш нәтиҗәсендә ыруглык общинасы "үзидарәле, коралллы оешмага" әверелә. Хәрби тәрбия ялгылары барлыкка килә: малайлар җәядән атарга, сөңге кулланырга, атта йөрергә һ. б. өйрәнәләр. Яшь төркемнәрендә анык эчке оешма барлыкка килә, башлыклар аерылып чыга, "багышлауларның" программасы катлаулана, хәзер инде яшьләрне моңа ыругның махсус билгеләнгән өлкәннәре әзерли. Белем башлангычларын үзләштерүгә, ә язу барлыкка килгәч — язуга зур игътибар бирелә башлый.

Тәрбия эшен ыруглык общинасы билгеләгән аерым кешеләр тормышка ашыру, аның эчтәлеген һәм ахырдан сынаулар программасын киңәйтү, катлауландыру — болар һәммәсе шуны раслый: ыруглык строе шартларында тәрбия җәмгыять эшчән-легенең аерым формасы буларак аерылып чыга башлый.

Шәхси милек, коллык һәм гаилә барлыкка килү белән борынгы җәмгыять таркала. Гаилә иң мөһим иҗтимагый күренешләрнең берсенә, җәмгыятьнең төп икътисади ячейкасына әверелә, балалар тәрбияләү функциясе ыруглык общинасыннан аңа күчә. Гаилә тәрбиясе тәрбиянең массачыл формасына әверелә. Әмма "яшьләр йортлары" да яшәүләрен дәвам итә, шулай ук мәктәпләр барлыкка килә башлый.

Халыкның хакимлек итүче төркемнәре (жрецлар, юлбашчылар, ыру башлыклары) белем бирүне физик хезмәт таләп итүче эшләргә өйрәтүдән аерырга омтылалар. Белем ялгыларын (басуларны үлчәү, су басуларны алдан әйтү, кешеләрне дәвалау алымнары һ. б.) хакимлек

итүче төркемнәр үз кулларында туплыйлар, шуның белән үз өстенлекләрен ныгыталар. Бу белемнәргә өйрәтү өчен махсус учреждениеләр — мәктәпләр төзелә. Алар юлбашчыларның, жрецлар, ыру башлыкларының хакимлеген ныгытуда файдаланыла. Мәсәлән, Борынгы Мексикада аксөяк балалары физик хезмәттән азат ителә, аерым бинада укыйлар һәм гади кешеләрнең балаларына мәгълүм булмаган фәннәрне өйрәнәләр (пиктографик язу, йолдызларны күзәтү, мәйданнар исәпләү h. б.). Шушы хәл аларны башкалардан өстен итә.

Физик хезмәт изелүчеләр өлешенә кала. Аларның гаиләләрендә балалар бик яшьли эшкә өйрәнә, ата-аналары аларга үз тәҗрибәләрен тапшыралар. Оешкан төстә мәктәпләрдә тәрбияләнү өстен хокуклы кешеләрнең балаларына гына мөмкин була.

**2.1. Вопросы для самоконтроля**

1. В чем, на ваш взгляд, заключаются перемены в понимании демократизма образования в постсоветской России?
2. Что вы можете рассказать о деятельности экспериментальных учебно-воспитательных учреждений России 1980-1990-х гг.?
3. Какие идеи гуманистического воспитания предлагают современные отечественные педагоги?
4. С какими проблемами сталкивается современная российская школа при обучении и воспитании молодого поколения?

**2.2. Задания для практики.**

1. Назовите основные факторы, обусловившие возникновение воспитания и формы воспитания в условиях первобытнообщинного строя.
2. Что общего и чем отличаются подходы к воспитанию в Древнем Египте, Древней Индии и Древнем Китае?
3. Каковы основополагающие идеи античной педагогики и их преломление в современной практике образования?
4. В чем суть сократического метода?
5. В чем смысл религиозного идеала Средневековья? Приведите известные вам системы средневекового воспитания.
6. Каковы главные этапы развития педагогической мысли и образования в средневековом исламском мире?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 2» , добавить вопросы для самоконтроля.

## 2.3. Глоссарий по теме 2

**Авторитарное воспитание** — воспитательная концепция, предусматривающая подчинение воспитанника воле воспитателя. Подавляя инициативу и самостоятельность, А. в. препятствует развитию активности детей, их индивидуальности, ведет к возникновению конфронтации между воспитателем и воспитанниками. *Авторитарный стиль педагогического руководства* представляет собой стрессовую воспитательную систему, основанную на властных отношениях, игнорировании индивидуальных особенностей обучаемых, пренебрежении к гуманистическим способам взаимодействия с воспитанниками. *Принцип авторитарной педагогики* — учитель — субъект, а ученик — объект воспитания и обучения. Тщательно разработаны средства управления ребенком: угроза, надзор, приказание, запрещение, наказание. Урок жестко регламентирован, акцент — на воспитывающем обучении. Яркий представитель — Иоганн Фридрих Гербарт (1776—1841). Такой стиль порождает в педагоге особые профессиональные черты: догматизм, чувство непогрешимости, педагогическую бестактность, безапелляционность в суждениях. Одно из его проявлений в педагогической деятельности — *морализирование.*

**Антропология педагогическая** — философская база воспитания, которая позволяет понять структуру воспитания, лишь соотнеся ее со структурой целостной природы человека; «изучение человека во всех проявлениях его природы со специальным приложением к искусству воспитания» (К.Д. Ушинский); воспитание в А. п. понимается как атрибут человеческого бытия.

**Антропология философская** — учение о сущности человека, его происхождении и смысле жизни, о закономерностях бытия; ориентирована на синтез конкретно-научных знаний о человеке и на построение его целостного образа в человекознании.

## 2.4. Использованные информационные ресурсы.

1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.

6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.

## Тема 3. *КОЛБИЛӘҮЧЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР*

**Аннотация.** Данная тема раскрывает о возникновении школы и педагогических идей, а также появление воспитания в первобытном обществе.

**Ключевые слова.** Педагогическая идея, педагогический процесс, школа, первобытное общество.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### *КОЛБИЛӘҮЧЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР*

Тарихи үсеш нәтиҗәсендә борынгы община строе яңа иҗтимагый формация — **колбиләүчелек строе** белән алышына. Борынгы Көнчыгышта беренче сыйнфый җәмгыятьләр барлыкка килә, матди һәм рухи мәдәнияткә нигез салына. Моны исә алардан күпмедер дәрәҗәдә Греция һәм Рим халыклары кабул итә, үзенчә эшкәртә.

**Борынгы Көнчыгыш илләрендә мәктәп.** Борынгы Көнчыгыш илләрендә мәктәп торган саен халыкның хакимлек итүче төркеме хокукына әверелә бара.

Бик борынгы заманнарда мәктәп Һиндстанда туа һәм ныгый. Анда гади җир эшкәртүчеләр ачкан община мәктәбе меңнәрчә ел эшләвен дәвам итә. Шул ук вакытта шәһәрләрдә аксөякләр һәм байлар гыйбадәтханәләрендә ачылган мәктәпләр дә зур әһәмияткә ия була.

Мәктәпләр шулай **Кече Азия һәм Африкада** да киңрәк үсеш ала. Биредәге күп кенә дәүләтләрдә әледән-әле кабатланып торган елгалар ташу кебек табигать күренешләрен файдаланып, ясалма сугаруга бәйле җир эшкәртү булган.

Кешеләр табигать күренешләрен күзәткәннәр, су басуларны алдан әйтергә өйрәнгәннәр, плотиналар һәм төрле корылмалар төзү тәҗрибәсен туплаганнар. Астрономия, геометрия, арифметика, медицина фәннәренең яралгылары күренә; төзелешләр өчен иң гади машиналар барлыкка килә. Барлык шушы мәгълүматлар халыкның хакимлек итүче катлаулары кулында туплана, еш кына гайре табигыйлек, серлелек пәрдәсенә төрелә. Ябык жрецлар яисә сарай мәктәпләреннән тыш, дәүләт һәм хуҗалык белән идарә итү ихтыяҗ-ларына хезмәт итүче мәктәпләр дә туа. Болар — күчереп язучылар, хезмәткәрләр һ. б. мәктәпләр. Әкренләп кайбер илләрдә язу ысулы да үзгәрә. Мәсәлән, Мисырдагы жрецлар мәктәпләрендә катлаулы иероглиф язуына ("изге язучы") өйрәтәләр, ә күчереп язучылар мәктәбендә гади (иератик) язу файдаланыла.

Язарга һәм санарга өйрәткәндә кайбер укытуны җиңеләйтүче ысуллар, мәсәлән, төрле төстәге ташлар ярдәмендә санау, исәпләүнең гадиләштерелгән алымнары һ. б. кулланыла. Барлык халык-ларда да бармак белән санау киң таралган була.

**Борынгы Кытайда түбән һәм югары мәктәпләр булган.** Югары мәктәпләрдә өстен хокуклыларның балалары укырга һәм катлаулы иероглиф ысулы белән язарга өйрәнгәннәр, философия һәм мораль (дини характердагы), язучылар һәм шагыйрьләр иҗатлары белән танышканнар. Шунда ук астрономиядән дә кайбер мәгълүматлар алганнар.

Бик борынгы кульъязмаларда (Кытай, Һиндстан, Мисыр һ. б.) тәрбия турында, укытучыга һәм укучыга таләпләр турында кыйммәтле фикерләр очрый.

Дисциплина, аеруча күчереп язучылар мәктәпләрендә, бик каты була, тән җәзалары киң кулланыла. **"Баланың колагы — аркасында",**— диелә бер борынгы Мисыр кульъязмасында.

Күпчелек гади кешеләрнең һәм колларның балалары мәктәпләрдә әзерлек үтмиләр; хезмәткә һәм үз-үзеңне тоту нормаларына бәйле төп белем һәм күнекмәләрне аларга ата-аналары һәм тирә-юньдәгеләр бирә.

**Борынгы Грециядә тәрбия, мәктәп һәй педагогик фикер.** Борынгы Греция — зур булмаган берничә колбиләүчелек дәү-ләтеннән (полислардан) торган ил. Аларның мөһимрәкләре Лакония (баш шәһәре — Спарта) һәм Аттика (баш шәһәре — Афина) булган. Бу

дәүләтләрнең һәр икесендә аерым тәрбия системасы урнашкан: спарта һәм афина тәрбия системалары.

Бу ике системаның аермасына дәүләтләрнең икътисади һәм сәяси үсешендәге кайбер үзенчәлекләр һәм аларның мәдәни хәлләре сәбәп булып тора. Әмма ике дәүләт тә колбиләүчелек дәүләте була, һәм иҗтимагый тәрбия системасы фәкать колбиләүче балаларына гына хезмәт күрсәтә. Грециядә колларга "сөйләшә торган корал" итеп кенә карыйлар. Алар бөтен хокуклардан, шул исәптән мәктәпләрдә уку хокукыннан да мәхрүм ителгән була.

**Лакония (Спарта) Пелопоннесның** (көньяк-көнчыгышындагы) уңайлы гаваньнары булмаган территорияне биләгән. Илдә коллар хезмәтенә нигезләнгән җир эшкәртү хакимлек иткән. Тулы хокукларга ия булмаган азсанлы ярым азат җирле халыкның күпчелеге һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Тугыз мең колбиләүче гаиләсе 250 меңнән артыграк халыкны кол итеп тоткан. Спартада колларны рәхимсез эксплуатацияләгәннәр, һәм еш кына коллар баш күтәргәннәр. Спарталыларның тормышы төп бер таләпкә буйсындырылган — даими хәрби хәзерлектә тору, колларга карата рәхимсез көч куллану.

Тәрбияне дәүләт тормышка ашырган, ул спарталыларның балаларыннан ныклы, чыдам сугышчылар, булачак колбиләүчеләр әзерләүне бурыч итеп куйган.

Моңа кадәр өйләрендә тәрбияләнгән спарта малайлары, җиде яшь тулгач, дәүләт карамагындагы махсус тәрбия учреждениеләренә урнаштырылганнар. Агелла дип аталган бу учреждениеләрдә аларны 18 яшькә кадәр укытканнар, тәрбияләгәннәр. Агелла җитәкчесе итеп властьларга мәгълүм кеше — педоном билгеләнгән. Үсмерләрнең физик тәрбиясенә аерым игътибар бирелгән: аларны чыныктырганнар, суыкка, ачлыкка, эссегә, авыртуларга түзәргә өйрәткәннәр. Хәрби-гимнастик күнегүләргә зур игътибар бирелгән. Яшь спарталыларны йөгерергә, сикерергә, диск һәм сөңге ыргытырга, көрәшергә, кул сугышы алымнарына, сугышчан җырлар җырларга өйрәткәннәр. Физик тәрбиягә музыка, җыр һәм сугышчан рухтагы дини биюләр кушылган.

"Уку һәм язу мәсьәләсенә килгәндә,— дип яза грек тарихчысы Плутарх,— балалар иң кирәкле нәрсәләргә генә өйрәнгәннәр, калган тәрбия исә бер генә максатка хезмәт иткән: карусыз тыңлау, чыдамлык һәм җиңү фәне".

Үсеп килүче колбиләүчеләрдә колларга нәфрәт, аяусызлык тәрбияләү төп бурыч булган. Шушы максатларда алар **"криптияләрдә"**, ягъни төннәрен **коллар аулауда** катнашканнар. Бу болай эшләнгән: яшь спарталылар отряды, шәһәрнең берәр кварталын яисә шәһәрдән читтәге районны чолгап алып, теләсә нинди кол-илотны үтергән.

**Әхлакый һәм сәяси тәрбия** дәүләт җитәкчеләренең яшьләр белән махсус әңгәмәләре вакытында бирелгән. Алар ул әңгәмәләрдә борынгы бабаларының ватан дошманнары белән көрәштәге нык-лыгы, батырлыгы турында, геройлар турында сөйләгәннәр. Бала-ларны анык һәм кыска җавап бирергә ("лаконик сөйләмгә") өйрәткәннәр.

18-20 яшьлекләр, махсус эфеблар төркеменә күчерелеп, хәрби хезмәткә тартылганнар. Кызларның хәрби һәм физик тәрбиясенә зур игътибар бирелгән. Ирләр сугышка яисә баш күтәргән колларны бастырырга киткәндә, хатын-кызлар шәһәр һәм торакларны саклаганнар, колларны буйсындырып тотканнар.

**Афина тәрбиясе башкача оештырылган була**. Афинада икътисади тормыш Спартадагы шикелле чикләнмәгән. Коллар шәхси милек булып исәпләнгән.

Афинада безнең эрага кадәр V—IV гасырларда мәдәният бик нык үсә. Грек философиясенең күп төрле формаларында дөньяга карашның хәзерге барлык төрләренең яралгысы була. Шушы чорның кайбер философларның карашларында материализм элементлары да, диалектика элементлары да күренә. Табигать белеме, математика, тарих, сәнгать, әдәбият, гүзәл грек архитек-турасы һәм скульптурасы үсә.

Афиналылар физик яктан да, әхлакый яктан да гүзәл кешене генә идеал дип исәпләгәннәр, акыл, әхлак тәрбиясен, эстетик һәм физик тәрбияне кушарга омтылганнар. Ләкин бу идеал тулысынча югары социаль катлауга—колбиләүчеләргә генә кагылган. Физик хезмәт бары тик колларның гына бурычы дип саналган. Шулай да, катлауларга аерылу сәбәпле, колбиләүчеләр арасыннан тумыштан азат һәм ireккә җибәрелгән аз милекле шактый зур төркем аерылып чыга. Алар һөнәрчелек яисә башка төр эшчәнлек белән, шул исәптән укытучылык белән дә, шөгыльләнергә мәҗбүр булалар. Бай колбиләүчеләр аларга кимсетеп, җирәнеп карый.

Афинада балалар җиде яшькә кадәр өйдә тәрбияләнә. Җиде яшьтән малайлар мәктәпкә йөри башлый. Кызлар тәрбияне гаиләдә алалар,

йорт эшләренә өйрәнәләр. Афинада хатын-кызның гомере җәмгыятьтән читтә, йортның хатыннар ягында (гинекеядә) уза.

Иң әүвәл балалар (7 яшьтән 13-14 яшькә кадәр) **грамматист һәм кифарист** мәктәпләрендә укыйлар (йә бер үк вакытта, яисә башта — грамматист, аннары кифарист мәктәбендә). Бу мәктәпләр хосусый һәм түләүле булганлыктан, тумыштан ирекле, әмма байлыгы булмаган кеше балаларының (демосларның) шактый өлеше анда укый алмаган. Мәктәпләрдә дәресләрне **укытучы-дидаскаллар** алып барган (**"дидаско"** — мин укытам, соңрак: **"дидактика"** — укыту теориясе). Малайларны мәктәпкә берәр кол озата барган, ул кол педагог дип аталган (**"пайс"** — бала, **"вгогейн"** — алып барырга дигән сүзләрдән).

Грамматистны мәктәптә укырга, язарга, санарга өйрәткәннәр. Хәрефләрне кушып укыту ысулы кулланылган: балалар әүвәл хәрефләрнең исемнәрен (альфа, бета, гамма һ. б. ш.) өйрәнгәннәр, аннары алардан иҗекләр, сүзләр ясаганнар. Язарга өйрәтү өчен балавызлы такталар кулланылган, ул такталарга нечкә таяклар (стильләр) белән хәрефләр язганнар. Санарга бармаклар, ташлар һәм счетка охшаганрак исәпләү тактасы (абака) ярдәмендә өйрәнгәннәр. Кифарист мәктәбендәге малай, гадәттә, әдәби белем һәм эстетик тәрбия алган: музыкага, җырга, шигырь сөйләргә өйрәнгән ("Илиада" һәм "Одиссея"дан өзекләр укыганнар).

13-14 яшьлек малайлар **палестра** дип аталган уку йортына (көрәш мәктәбенә) күчкәннәр. Биредә алар ике-өч ел буена физик күнегүләр белән шөгыльләнгәннәр, бишле ярыш дип аталган бу системага йөгерү, сикерү, көрәш, диск һәм сөңге ыргыту, йөзү кергән. Алар белән сәяси һәм әхлакый темаларга әңгәмәләр үткәрелгән. Палестрада физик тәрбия һәм әңгәмәләр белән иң атаклы кешеләр җитәкчелек иткән.

Аннары яшьләрнең баерак өлеше гимназияләргә кергән (соңрак — гимназияләр). Алар анда, дәүләтне идарә итүдә катнашырга әзерләнү өчен, философия, сәясәт, әдәбият өйрәнгәннәр, гимнастика белән шөгыльләнүләрен дәвам иткәннәр.

Ниһаять, Спартадагы кебек үк, 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге егетләр **эфебияга** күчкәннәр, анда аларның **хәрби һәм сәяси тәрбияләре** дәвам иткән. Алар ныгытмалар төзергә, хәрби машиналарны идарә итәргә өйрәнгәннәр, шәһәр гарнизоннарында

хезмәт иткәннәр, диңгез эшенә өйрәнгәннәр, җәмәгать бәйрәм-нәрендә һәм театр тамашаларында катнашканнар.

Афина республикасындагы колбиләүчелек җәмгыятенең эчтән катлауларга бүленүе тәрбия өлкәсендә дә күренә: күпьяклы тәрбия алу бай колбиләүче балаларына гына мөмкин була. Тумыштан ирекле төп халык массаларының (демос) балалары мәктәпләрдә укый алмый. Әтиләре балаларын һөнәргә, кайберләре исә укырга-язарга да өйрәтә. Бу законда каралган була: закон нигезендә аз милекле ата-аналар балаларын нинди дә булса һөнәргә өйрәтергә тиеш булалар, шулай булмаган очракта аларның балалары карт ата-аналарының матди хәлен кайгыртудан азат ителә. Физик хезмәт белән шөгыльләнүче тумыштан иренлеләргә колбиләүче аксөякләр түбәнсетеп карый. Коллар исә "сөйләшә торган корал" буларак кына бәяләнә.

**Борынгы Грециядә педагогик теориянең тууы**. Борынгы грек галим-философлары **Сократ, Платон, Аристотель һәм Демокритның** халык алдында ясаган чыгышларында һәм хезмәт-ләрендә тәрбия һәм укыту турында кыйммәтле фикерләр бар.

**Сократ (б. э. к. 469-399 еллар)** — философ-идеалист. Чыгышы буенча гади халыктан булуына да карамастан (ярлы һөнәрче — сынчы малае), ул җирбиләүче консерватив аксөякләр идеологы була. Бу аның фәлсәфи һәм педагогик карашларында чагылыш таба. **Сократ**: дөньяның төзелешен, әйберләрнең физик табигатен танып белү мөмкин түгел, кешеләр фәкать үз-үзләрен генә танып белә алалар, гомуми һәм үзгәрмәс әхлакый төшенчәләр бар, дип санаган.

Тәрбиянең максаты, **Сократ** фикеренчә, әйберләрнең таби-гатен өйрәнү түгел, ә үз-үзеңне таный белү, әхлакны камилләштерү булырга тиеш.

**Сократ** — трибун философ, әхлак темаларына мәйданнарда һәм башка җәмәгать урыннарында чыгышлар ясаган. Чыгышларында әзер положениеләр һәм нәтиҗәләр бирмәгән, сораулар һәм җаваплар ярдәмендә тыңлаучыларын "хакыйкатьне" үз көчләре белән эзләргә дәртләндергән. Бу ысул **Сократ** ысулы дигән исем алган, соңрак шуннан юнәлеш бирүче сораулар ысулы белән Сократ әңгәмәсе дигән ысул барлыкка килгән.

**Платон (б. э. к. 427-347 еллар)** — философ-идеалист, Сократның шәкерте, объектив идеализм теориясен тудыручы, ул "идеяләр дөньясын" - беренчел, ә тоеп беленә торган әйберләр дөньясын икенчел дип санаган, әйберләрнең җисемсез формалары (ул аларны

"төрләр" яисә "идеяләр" дип атаган) барлыгы фикерен алга сөргән. Ул дөньяны идеяләр дөньясына һәм күренешләр дөньясына бүлгән. Аныңча, идеяләр мәңгелек һәм үзгәрешсез. Әйберләр исә бары идеяләр дөньясының күләгәсе генә.

**Платон**, Афина аксөякләренең вәкиле, аксөякләрнең мәңгелек хакимлеге теориясен күтәреп чыккан. Идеаль аксөякләр дәүләте конституциясен төзегән. Анда өч иҗтимагый төркем: философлар, сугышчылар, һөнәрчеләр һәм җир эшкәртүчеләр яшәргә тиеш булган. Философлар идарә итә, сугышчылар дәүләт тәртибен саклый, ә өченче төркем эшләп теге икесен ашата, киендерә. Бу дәүләттә коллар да була. Коллар кебек үк, һөнәрчеләр һәм җир эшкәртүчеләр дә хокуксыз. Түбән җанлы бу кешеләр карусыз, тыңлаучан булырга тиеш.

Бу дәүләтнең максаты, **Платон** фикеренчә, — иң югары бәхет идеясенә якынаю: ул беренче чиратта тәрбия юлы белән тормышка ашырыла, шуңа күрә тәрбиягә аеруча әһәмият бирелә.

Тәрбия, ди **Платон**, дәүләт тарафыннан оештырылырга һәм хаким төркемнәр — философлар һәм сугышчыларның мәнфәгатьләренә туры килергә тиеш. Платон педагогик системасында үзенең идеяләрен канәгатьләндерә торган Спарта һәм Афина тәрбияләрен бер системага берләштерергә омтылган.

3 яшьтән 6 яшькәчә балалар дәүләт тарафыннан билгеләнгән тәрбиячеләр җитәкчелегендә мәйданчыкларда уеннар уйныйлар. Тәрбия чарасы буларак сабыйларның уенына, шулай ук балаларга сөйләү өчен материал сайлауга Платон зур әһәмият бирә. Ул аларга бик кечкенәдән җәмгыять тәрбиясе бирүне яклый.

7 яшьтән 12 яшькә кадәрге балалар, дәүләт мәктәпләренә йөреп, укырга, язарга, хисапка, музыка һәм җырга өйрәнәләр, ә 12 яшьтән 16 яшькә кадәр — физик тәрбия мәктәбенә — гадәти гимнастик күнегүле палестрага йөриләр. Палестрадан соң 18 яшькә кадәрге яшүсмерләр, күбесенчә гамәли максатларда (сугышчылар әзерләү өчен) арифметика, геометрия һәм астрономия өйрәнәләр. 18 яшьтән 20 яшькә кадәр — эфебия, ягъни хәрби-гимнастик әзерлек. Акыл хезмәтенә сәләте күренмәгән егетләр 20 яшьтән сугышчылар булып китәләр. Яшьләрнең абстракт фикер йөртүгә сәләте азрак өлеше 30 яшькә кадәр белем алуның өченче, югары баскычын уза. Алар философия, шулай ук арифметика, геометрия, астрономия һәм музыка теориясен, әмма инде фәлсәфи-теоретик планда өйрәнәләр. Дәүләт хезмәтенә әзерләнәләр. Аеруча сәләтле бер өлеше философиягә

өйрәнүен тагын 5 ел (35 яшькә кадәр) дәвам итә, аннары алар 35 яшьтән 50 яшькә кадәр дәүләт белән җитәкчелек итәләр.

**Платон** фикеренчә, хатын-кызларны тәрбияләү Спартадагы шикелле булырга тиеш.

Платон системасында бөтен тәрбия физик хезмәткә тирән нәфрәт рухында корыла, булачак философларга һәм сугышчыларга "хәтта ул турыда уйлау да" тыела. Кол балалары белем алуга якын да җибәрелми.

Платон мәктәпкәчә тәрбия, дәүләт тәрбиясенең эзлекле системасы турында күп кенә мөһим фикерләр әйтә, уңай мисал белән тәрбияләү таләбен күтәреп чыга һ. б.

Аристотель (б. э. к. 384-322 еллар) — Платон шәкерте, Александр Македонскийның тәрбиячесе, борынгы Грециянең бик зур философы һәм галиме була. Ф. Энгельс болай дип яза: "Борынгы Греция философлары барысы да тумыштан стихиячел диалектиклар булганнар һәм Аристотель, алар арасында иң универсаль башлы кеше, диалектик фикерләүнең иң әһәмиятле формаларын тикшергән инде".

Дөньяны идеяләр һәм күренешләр дөньясына бүлгән укытучысы Платонның капма-каршысы буларак, Аристотель: дөнья бердәм һәм әйберләр идеясе әйберләрнең үзләреннән аерылгысыз, дип таный. Идеяне, Аристотель фикеренчә, формага тиңләштерергә мөмкин. Һәм предметта без матдә һәм форманы аерабыз. Матдәдә әйбер мөмкинлекләре бар: матдә, теге яисә бу форманы алып, әйбергә әверелә. Мәсәлән, мәрмәр матдәсе, билгеле бер форма алгач, статуя була ала.

Бөтен тормыш – үсеш процессы ул. Бу процесс тышкы көчләр йогынтысында түгел, ә эчке үсеш буларак бара. Аристотель тышкы дөньяның чынлыгына шикләнмәгән һәм танып белүнең нигезенә тоеп белү тәҗрибәсен, сизүне салган. Танып белүдәге ялгышлар, Аристотель уенча, ялган фикер йөртүдән, ягъни тоеп белү тәҗрибәсен ялгыш аңлатудан килеп чыга. Шунысы әһәмиятле, Аристотель форма һәм эчтәлек берлеген күрсәтә һәм үсеш идеясен күтәреп чыга.

Кешедә Аристотель материя һәм форма кебек аерылгысыз яши торган тән һәм җанны күрә. Аристотель фикеренчә, өч төрле җан бар: үсемлек җаны (туклануда һәм үрчүдә күренә); хайван җаны (үсемлекләрдәге үзлекләрдән тыш, тою һәм теләкләрдә күренә); акылга ия җан (үсемлек һәм хайваннардагы үзлекләрдән тыш, аңа фикер йөртү

яки танып белү хас). Кешедәге җанның хайван өлешен, акылга буйсындырылганлыктан, ихтыярлы дип әйтергә була.

Ә аның өч төренә, Аристотель фикеренчә, тәрбиянең өч ягы туры килә: физик тәрбия, әхлакый тәрбия һәм акыл тәрбиясе.

Тәрбиянең максаты, аныңча, җанның иң югары — акылга ия һәм ихтыярлы якларын үстерү. Һәрбер матдәдә үсеш мөмкинлеге булган шикелле үк, кешегә дә табигать сәләтнең яралгыларын гына бирә; үсеш мөмкинлеге тәрбия белән тормышка ашырыла. Табигать җанның өч төрен дә бик тыгыз беркеткән, тәрбиядә дә без, физик, әхлакый һәм акыл үсешен бергә бәйләп, табигатькә ияргә тиешбез.

Дәүләтнең, Аристотель фикеренчә, гомумән алганда ахыргы максаты бер — барлык кешеләргә дә бердәй тәрбия кирәк, һәм бу тәрбия шәхси инициатива эше булырга тиеш түгел, ә аны дәүләт кайгыртырга тиеш. Гаилә һәм җәмгыять тәрбиясе үзара бәйләнгән булырга тиеш. Дәүләт бердәй тәрбия бирүне кайгыртырга тиеш дию белән Аристотель, билгеле, колларны күз алдында тотмаган.

Кешелекнең тарихи тәҗрибәсен берләштереп, Аристотель яшь чорларын билгеләгән һәм үсеп килүче кеше гомерен өч чорга бүлгән: 1) 7 яшькә кадәр, 2) 7 яшьтән 14 яшькә кадәр (җенси өлгергәнлек чоры), 3) җенси өлгергәнлек чорыннан 21 яшькә кадәр. Аныңча, чорларга шулай бүлү кешенең табигатенә туры килә дә инде.

Аристотель гаилә тәрбиясе мәсьәләсендә дә күп кенә киңәшләр бирә. 7 яшькә кадәр балалар гаиләдә тәрбияләнә. Балага яшенә туры килгән ризык ашатырга, хәрәкәт гигиенасын тәэмин итәргә һәм аны әкренләп чыныктырырга кирәк. 7 яшьтән малайлар дәүләт мәктәпләренә йөрергә тиеш була.

Физик тәрбия акыл тәрбиясеннән алда барырга тиеш. Малайларны иң элек гимнастика укытучылары кулына тапшырырга кирәк, әмма аларның артык аруына юл куярга ярамый. Организм ныгыганчы, җиңел күнегүләр генә эшләтергә кирәк. Аристотель фикеренчә, физик, әхлакый һәм акыл тәрбиясе үзара бәйләнгән. Башлангыч белем бирү чорында, гимнастикадан тыш, укырга, язарга, грамматикага, рәсем һәм музыкага өйрәтергә кирәк. Үсмерләр мәктәптә җитди белем алырга: әдәбият, тарих, фәлсәфә, математика, астрономия һәм музыканы өйрәнергә тиеш. Музыканы, рәсем шикелле үк, профессиональ максатларда түгел, ә матурлык хисен үстерү өчен өйрәнергә кирәк. Хатын-кызлар, Аристотель уйлавынча, табигатьләре белән ирләрдән аерылып торганлыктан, алар шикелле белем ала алмыйлар.

Үз фәлсәфәсендә ихтыяри, эшлекле башлангычларны алга сөргән Аристотель әхлак тәрбиясе өлкәсендә әхлакый эш-гамәлләрдә әхлак күнекмәләре һәм күнегүләренә зур әһәмият биргән. Табигый сәләт чаткылары, күнекмәләрне үстерү (өйрәтү, кирәкле эш-гамәлләрне еш кабатлау) һәм акыл — әхлак тәрбиясенең өч чыганагы менә шушылар.

Яхшылык тәрбияләү өчен әхлакый тотыш гадәтләрен һәм күнекмәләрен формалаштыручы яхшы уйланылган күнегүләр кирәк, һәрбер теләктә һәм эшчәнлектә, Аристотель фикеренчә, кимлек, артыклык (арттырып җибәрү) һәм уртаклык булырга мөмкин. Һәрнәрсәдә бары тик уртаклык, бары тик тигезләнеш яхшы һәм файдалы. Үз-үзеңне тотуда арттырып җибәрүләргә дә, җитешсезлекләргә дә юл куймау — яхшылык була. Үз-үзеңне шулай тотарга күнегү зарури. Платоннан аермалы буларак, Аристотель: гаилә тәрбиядән читләшми, әхлак тәрбиясен кайгырту күбрәк гаилә өстенә төшә, дип саный.

**Аристотельнең карашлары антик педагогика үсешенә зур йогынты ясый.** Әмма урта гасырларда, Аристотель фәлсәфәсе бик популяр чорда, поплар, Аристотельдәге җанлы нәрсәләрне үтереп, үлене мәңгеләштерделәр...

Атомистик теорияне тудыручы күренекле фәлсәфәче — материалист **Демокритның (б.э.к. 460-370 еллар)** карашлары Борынгы Греция фәлсәфәсенең иң югары ноктасы булып тора. Ул үз хезмәтләрендә тәрбия мәсьәләләренә күп игътибар бирә, таби-гать законнарына, имеш-мимешләргә ышану һәм куркуны җимерә торган чын белемгә мөрәҗәгать итә. Ул аллага ышануны кире кага, "аллалар ихтыяры" — уйдырма, кешеләр хыялы гына дип саный.

**Демокрит** беренчеләрдән булып тәрбиянең табигатькә ярашлылыгы мәсьәләсен күтәрә. "Табигать һәм тәрбия охшашлар",- дип яза ул. "Укыту хезмәт нигезендә генә гүзәл нәтиҗәләргә китерә",- ди Демокрит. Тәрбия эшендә хезмәтнең роле зурлыгын ассызыклап, "бер күнеккәч җиңеләя торган даими хезмәт" таләп итә. Ул начар мисалга иярүдән кисәтә һәм әхлакый эш-гамәлләрдә күнегүне бик әһәмиятле дип саный.

Демокрит колбиләүчелек нигезләренә тәнкыйди караш уята, табигатьне чын-чынлап танып белергә, тәрбияне хезмәт белән бәйләргә чакыра.

**Борынгы Римда тәрбия һәм мәктәп.** Рим республикасында колбиләүчелек үсә; байлык туплану халыкның катлауларга аерылуына

китерә, бу исә мәктәпләрнең, байлык һәм чыгышка карап, башлангыч һәм югарырак баскычтагы грамматик мәктәпләргә, ә соңрак оратор мәктәпләренә бүленүенә сәбәп була.

**Башлангыч мәктәпләр хосусый һәм түләүле була.** Анда тумыштан ирекле булмаган ярлы сыйныфларның (плебейларның) балаларын укырга, язарга һәм хисапка өйрәткәннәр, илнең законнары белән таныштырганнар. Бай, аксөяк балаларына башлангыч белемне өйдә бирүне кулай күргәннәр.

**Грамматик мәктәпләр дә хосусый һәм түләүле булган,** аларда өстен хокуклыларның балалары латин һәм грек телләрен, риторика (әдәбият һәм тарихтан кайбер мәгълүматлар белән сөйләү осталыгы) өйрәнгәннәр. Мондый мәктәпләр сайланып куела торган җитәкче урыннарга омтылучыларга ораторлык сәнгатенә өйрәнү өчен кирәк булган.

Рим республикасының соңгы йөзьеллыгында махсус **риторлар (ораторлар) мәктәпләре** барлыкка килә. Анда киләчәктә югары дәүләт хезмәтенә урнашырга теләгән аксөяк балалары зур түләү исәбенә риторика, фәлсәфә һәм хокук белеменә, грек теле, математика һәм музыкага өйрәнгәннәр. Греция тарафыннан яулап алынганнан соң (б. э. к. II гасыр) Римда грек мәдәнияте тарала, аксөякләр грек телендә сөйләшә башлый.

Рим империясе барлыкка килгәннән башлап, грамматик һәм риторлар мәктәпләре **дәүләт мәктәпләре** итеп үзгәртелә. Ул мәктәпләрнең бурычы император хакимиятенә тугрылыклы түрәләр әзерләү була. Андагы укытучыларны императорлар үз сәясәтләрен карусыз үткәрүчеләргә әверелдерергә тырышканнар, шуның өчен аларга хезмәт хакы түләгәннәр һәм төрле өстенлекләр биргәннәр. Риторлар мәктәпләренә аларның игътибары аеруча зур булган.

Христиан дине хакимлек итүче дин һәм император хакимлегенең таянычы дип игълан ителгәч, укытучылар итеп христиан дине вәкилләрен билгели башлаганнар, мәктәпнең бөтен эше ачыктан-ачык чиркәүгә йөз тота. Христианнар борынгы грек мәдәниятенә, антик фән һәм мәктәпкә дошман караштa торганнар.

**Борынгы Римда педагогик һәм методик положениеләр эшләү.** Рим педагогларыннан иң атаклысы **Марк Фабий Квинтилиан (б. э. к. 42-118 еллар)** булган. Аның **"Оратор тәрбияләү турында"** дигән әсәренең сакланып калган өзекләреннән авторның төп педагогик карашлары турында хөкем йөртеп була. Квинтилиан үз заманындагы

грек һәм Рим фәлсәфи-педагогик әдәбияты белән яхшы таныш булган. Риторлар мәктәбе укытучысы буларак, ул үзенең бай тәҗрибәсен дә гомумиләштергән. Педагогика тарихында бу, һичшиксез, мәктәп практикасы белән тыгыз бәйләнгән беренче эшләрдән берсе була.

Квинтилиан азат гражданнарның балалары табигый сәләткә күбрәк ия дип санаган. Аныңча, алар арасында томана һәм сәләтсезләр сирәк очрый. Бала мәктәптә тәрбияләнсен, укытучы һәр балага сак һәм игътибарлы мөнәсәбәттә булсын. Укытучы үзе белемле, тотнаклы булырга, балаларны яратырга, уңга-сулга бүләк һәм җәза өләшмәскә, укучыларына үрнәк булып торырга һәм аларны игътибар белән өйрәнергә тиеш. Һәр укытучы укытуның бөтен баскычларын да узарга тиеш. Югары типтагы мәктәп укытучысы әүвәл башлангыч мәктәптә укытырга тиеш була.

**Квинтилиан** баланың кече яшьтән сөйләмен үстерүгә зур әһәмият биргән. Бу максатларда ул өйгә дөрес, сөйләмле нянялар алырга, балага уйнар өчен иптәшләр сайларга, бала аралаша торган иптәшләренең үз-үзләрен тотышына игътибар бирергә, начарларын читләштерергә тәкъдим итә. Тел һәм музыкага өйрәнү, **Квинтилиан** фикеренчә, дөрес сөйләшергә ярдәм итә, сөйләм стилен яхшырта, аны сәнгатьлерәк итә. Логик фикерләү, фикер төзеклеге һәм эзлеклелеге булдыру максатларында ул математика (арифметика һәм геометрия) өйрәнү кирәклеген, укытуны теоретик киңәшләргә, охшату һәм күнегүләргә нигезләнеп төзү зарурлыгын күрсәткән. Белем нигезләрен ашыкмыйча, ныклы итеп салу аеруча мөһим дип саналган.

**Квинтилиан** киңәшләрендә укытучы-практик тавышы тоемлана. Аның Яңарыш чорында өр-яңадан ачылган әсәрләрен бик күп укытучылар сүрелмәс кызыксыну белән өйрәнгәннәр һәм ул бүген дә актуаль.

**3.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. Определите тенденции развития воспитания в первобытном обществе.
2. Чем по своим целям и содержанию афинская система воспитания отличалась от спартанской, и какими факторами это было обусловлено?
3. Какие важные черты характеризуют христианскую педагогику?
4. В чем выразились изменения в направленности и характере образования в эпоху Возрождения?

5. Кратко охарактеризуйте особенности университетов в эпоху средневековья.
6. Какие проблемы, значимые для современной теории и практики образования, ставили и решали педагоги средних веков, Возрождения и Реформации?

**3.2. Задания для практики.**

Ознакомиться с текстом документа «Тема 3» , добавить вопросы для самоконтроля.

**3.3. Глоссарий по теме 3.**

**Воспитание** (как пед. явление) — 1) целенаправленная профессиональная деятельность педагога, содействующая максимальному развитию личности ребенка, вхождению его в контекст современной культуры, становлению как субъекта собственной жизни, формированию его мотивов и ценностей; 2) целостный, сознательно организованный пед. процесс формирования и образования личности в учебно-воспитательных учреждениях специально подготовленными специалистами; 3) целенаправленная, управляемая и открытая система воспитательного взаимодействия детей и взрослых, в крой воспитанник является паритетным участником и есть возможность вносить в нее (систему) изменения, способствующие оптимальному развитию детей *(в этом определении ребенок является и объектом, и субъектом);* 4) предоставление воспитаннику альтернативных способов поведения в различных ситуациях, оставляя за ним право выбора и поиска своего пути; 5) процесс и результат целенаправленного влияния на развитие личности, ее отношений, черт, качеств, взглядов, убеждений, способов поведения в обществе *(в этой позиции ребенок — объект пед. воздействия);* 6) целенаправленное создание условий для освоения человеком культуры, перевода ее в личный опыт через организованное длительное воздействие на развитие индивида со стороны окружающих воспитательных институтов, соц. и природной среды, с учетом его потенциальных возможностей с целью стимулирования его саморазвития и самостоятельности; 7) (в самом узком, конкретном значении) составные части целостного воспитательного процесса: умственное, нравственное и т. д. воспитание. **Воспитание духовное** — формирование ценностного отношения к жизни, обеспечивающего устойчивое и гармоническое развитие человека. В. д. — это воспитание чувства долга, справедливости, искренности,

ответственности и др. качеств, способных придать высший смысл делам и мыслям человека.

**3.4. Использованные информационные ресурсы**

1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.

## Тема 4. *ФЕОДАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР*

**Аннотация.** Данная тема раскрывает историю о воспитании в феодальном обществе. Рассматриваются формы и виды воспитания.

**Ключевые слова.** Воспитание, формирование, общество.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### *ФЕОДАЛЬ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ТӘРБИЯ, МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИК ФИКЕР*

**Борынгы феодализм чорында тәрбия.** Феодаль җәмгыятьтә, барлык җирләрне биләп, үзләренә буйсынган крестьяннарны эксплуатацияләүче феодаллар һәм руханилар хакимлек итә. Чиркәү феодаль җәмгыятьтә югары катлауның идеологик таянычы була. Ф.Энгельс күрсәткәнчә, феодаль үсеш стадиясен узучы көнбатыш дәүләтләрдә "интеллектуаль белемгә монополия поплар кулында була, һәм шулай итеп белем алу үзе күпчелек дини характер ала".

Балалар һәм өлкәннәрне укытуның бөтен эчтәлеге дин белән сугарылган була. Барлык диннәр дә гади кешеләрне хуҗаларга

буйсынырга, алар мәнфәгатенә хезмәт итәргә өйрәтә. Христиан дине бу максатта кеше табигатенең тумыштан гөнаһлылыгы турындагы тәгълиматны эшкә җигә, тыелуга, суфыйлыкка, киләчәктә теге дөньяда җанны коткару өчен тән рәхәтләреннән ваз кичәргә өнди.

Иран, Сүрия, Палестина, Мисырда һәм Африканың бөтен төньяк яр буенда VII – VIII гасырларда гарәпләрнең яулап алулары нәтиҗәсендә зур дәүләт барлыкка килә, ул Кытай, Һиндстан, Европа белән тыгыз икътисади элемтәләр урнаштыра. Гарәпләр тарафыннан яулап алынган илләрнең мәдәнияте югарырак була, яулап алынган илләр шул мәдәниятне кабул итәләр.

VIII гасырда гарәпләр Пиреней ярымутравын басып алалар, һәм Көнбатыш Европа территориясендә күп кенә югары мөселман мәктәпләре ачыла. Шуларның иң әһәмиятлесе Кордованың университет тибындагы югары мәктәбе, анда Көнбатыш Европаның төрле илләреннән студентлар җыелган. Кордова хәлифәлеге Урта гасырлар башында Көнбатыш Европага бик күп антик әсәрләр, аерым алганда Аверроэс исеме белән мәгълүм булган гарәп философы, Ибн-Рөшд (XII гасыр) шәрехләмәсендә Аристотель хезмәтләре үтеп керүдә күпер ролен үти.

Рим империясе IV гасырда Көнбатыш һәм Көнчыгыш империяләренә бүленә. Көнбатыш империя берничә дәүләткә таркала. Тарихка Византия исеме белән кергән Көнчыгыш империя мең ел диярлек яши. Византиядә, христиан дине өстенлек итүгә карамастан, антик мәдәниятнең кайбер элементлары сакланып кала. Мәктәпләрдән тыш, күп кенә шәһәрләрдә чиркәү карамагындагы югары мәктәпләр булган, анда изге язма текстлары белән беррәттән антик философлар, шагыйрь һәм язучылар хезмәтләрен өйрәнгәннәр. Тәре походлары чорында Көнчыгыш белән Көнбатышның аралашуы сәбәпле, антик дөньяның күп кенә әсәрләре Көнбатыш Европага да мәгълүм булган. Көнчыгыш Европада Византия мәдәнияте таралуда славяннарның роле зур була. Бу мәдәният (шул исәптән кайбер дини-тәрбияви трактатлар) Борынгы Руська да үтеп керә.

Византия империясен төрекләр яулап алган чорда (XV гасыр) күп кенә Византия галимнәре Европага күчеп китәләр һәм шунда антик философия әсәрләрен тараталар.

Көнбатыш Европада чиркәү мәктәпләре. Көнбатыш Европа илләре тормышында католик чиркәве зур әһәмияткә ия була. Ул бөтен белем алу системасын үз кулында тота. Урта гасырлардагы монастырьларда

гыйбадәт ихтыяҗларында китаплар күчереп языла, күчереп язучылар әзерләнә, китапханәләр һәм мәктәпләр төзелә.

Иң әүвәл монастырь мәктәпләре формалаша. Кайбер монастырьларда эчке һәм тышкы мәктәпләр була: эчке мәктәпләрдә ата-аналары монахлыкка биргән малайлар укый, аларның яшәүләре дә монастырьда була; тышкы мәктәпләрдә шул чиркәү мәхәлләсендәге кешеләрнең балалары белем ала.

Чиркәү идарәсе үзәкләрендә балаларны укырга бирә торган епископ тулай торакларыннан собор, яисә кафедра мәктәпләре (епископ кафедрасы каршында оештырылган мәктәпләр) үсеп чыга. Күп кенә урыннарда алар эчке мәктәпләргә (укучылар шунда яшиләр) һәм тышкы мәктәпләргә бүленәләр (тышкы монастырь һәм кафедра мәктәпләрендә, кагыйдә буларак, дворян балалары һәм, сирәк кенә булса да, шәһәрнең танылган кешеләренең балалары укый).

Һәм, ниһаять, күп кенә мәхәллә чиркәүләре каршында, мәхәллә мәктәпләрендә, укыту беркадәр системага салынган була. Мәктәпләрдә малайлар гына укый. Мәхәллә мәктәпләре йә чиркәү бинасында, яисә балаларны укытырга алынган дин әһеленең фатирында урнаша. Анда латинча догалар укырга, чиркәүдә җырларга һәм, сирәгрәк булса да, язарга өйрәтәләр. Чит телдә укыганнарының мәгънәсен еш кына балалар үзләре аңламаганнар.

Монастырь һәм собор мәктәпләренең кагыйдә буларак, уку өчен аерым биналары да булган; анык укыту сроклары билгеләнгән. Укытучылар — уку-укыту күнекмәләре алган руханилар булган.

Мәхәллә мәктәбендә уку берничә ел дәвам иткән: балалар белән бергә яшьләр һәм хәтта "китап гыйлеменә" өйрәнергә карар иткән өлкәннәр дә укыган. Баштарак укытучы материалны балаларга аңлаешсыз латин телендә укыган, тегеләре аны кычкырып кабатлаганнар; ә укучылар яза белгән җирләрдә дәресне балавызлы тактага язып барганнар, аннары, ятлагач, сөртен ташлаганнар, һәрбер укучыны такта янына чакырганнар, ул шунда белгәннәрен сөйләргә тиеш булган.

Латинча укырга хәрефләр кушу ысулы белән өйрәткәннәр, ә ул механик рәвештә ятлауга нигезләнә, шуңа күрә уку процессы бик авыр булган. Уку материалы булып дини китаплар хезмәт иткән, аларның эчтәлеген балалар аңламаган. Китап басу барлыкка килгәнче төрле кул белән язылган кулъязма китаплардан файдаланганнар, ә бу исә уку

техникасын үзләштерүне бик кыенлаштырган. Шулай ук язу техникасы да гаять катлаулы булган.

Укытучы укучыларын хаталары өчен бер дә аямаган: каты тән җәзалары киң таралган булган. Чиркәү дә тән җәзасын хуплаган, ул: "кеше табигате белән гөнаһлы", тән җәзасы җанны коткарырга булыша, "иблисне куа", дип өйрәткән.

Түбән мәктәпләргә (башлангыч мәктәпләргә) баштарак католик руханиларының балаларын гына кабул иткәннәр. Ә XI гасырдан, руханиларга никах тыелгач, ул мәктәпләргә шәһәр кешеләре һәм кайбер крестьян балаларын ала башлаганнар. Мәктәпләрдә чиркәү хезмәтчесе яки монах булырга җыенмаганнар да укый башлаган.

Төп халык массасы мәктәпләрдә белем алмаган; ата-аналары балаларны көндәлек хезмәт процессында тәрбияләгәннәр. Гаиләләрдә һәм һөнәрче остаханәләрендә һөнәр өйрәнчеклеге системасы барлыкка килгән. Эшкә өйрәтү һәм эш үзе берьюлы башкарылган: хезмәт күнекмәләре алып, укучылар зур осталык һәм җитезлек күрсәткәннәр.

Монастырьларда һәм собор мәктәпләрендә укыту курсы әкренләп киңәя барган, аларга грамматика, риторика һәм диалектика (дини философия башлангычлары) кертелә, ә кайберләрендә арифметика, геометрия, астрономия һәм музыкага да өйрәтәләр. Шулай итеп, монастырь һәм собор мәктәпләренең бер өлешендә югарырак белем бирелгән. Аның эчтәлеген "ирекле җиде сәнгать" тәшкил иткән. Моннан тыш, "фәннәр таҗы" дип саналган дини тәгълимат укытылган.

Аеруча зур әһәмият грамматикага бирелгән, латин теленең грамматик формаларын өйрәнгәннәр, төрле дини китапларны тикшергәннәр, дини-мистик эчтәлекле аерым грамматик формалар һәм гыйбарәләрне ятлаганнар. Риторика баштарак чиркәү законнары җыентыкларын өйрәнүгә һәм чиркәүләрнең эш кәгазьләрен төзүгә кайтып калган, аннары аңа чиркәү вәгазьләре хәзерләү бурычы йөкләнгән. Укучыларны диалектика дини темаларга бәхәскә әзерләгән, дин кануннарын якларга өйрәткән. Арифметика дәресләрендә укучылар өч гамәл, яисә, сирәгрәк булса да, дүрт гамәл (бүлү гамәле ул чорда бик катлауландырылган булган) белән танышканнар, саннарның мистик мәгънәләрен үзләштергәннәр. Астрономияне белү пасха көннәре билгеләү өчен исәпләүләрдә һәм йолдызлар буенча күрәзәлек итүгә булышкан; музыкага өйрәтү чиркәүдә гыйбадәт кылуга бәйле булган. Уку предметларының һәммәсенә дә дини-мистик төсмер бирелгән.

Асыл зат феодаллар тәрбияләү. Рыцарь балалары — “җир һәм крестьян хуҗалары" — башкача тәрбияләнә, аларда хәрби-физик күнекмәләр, крепостниклар әхлагы, тәкъвалык тәрбиялиләр, "югары җәмгыятьтә" үзләрен ничек тотарга өйрәтәләр.

Рыцарь тәрбиясенең эчтәлеген "җиде рыцарь әхлагы" тәшкил иткән: атта йөрү, йөзү, сөнге, кылыч һәм калкан тота белү, кылыч ярышы, ау, шахмат уены, шигырь чыгарып аны җырлый белү. Шахмат уены тырышлык һәм дөрес ориентлашу сәләте тәрбияләү чарасы итеп корылган. Шигырь чыгарып җырлый белү югары җәмгыятьтә аерылып тору, сугышчан батырлыкларны данлау һәм сөйгән ярыңны мактау өчен кирәк булган. Рыцарьга укый-яза белү мәҗбүри булмаган, урта гасырлар башындагы рыцарь катлавының бик күп вәкилләре (графлар, герцоглар) укый-яза белмәгән. Рыцарь балаларын дини хакыйкатьләр белән гадәттә ,берәр рухани таныштырган.

Феодалларның өлкән уллары 7 яшькә кадәр гаиләдә тәрбияләнгәннәр; 7 яшь тулгач аларны өлкән феодал (сюзерен) замогына, феодал хатынының ярдәмчесе вазифаларын башкарырга җибәргәннәр; 14 яшь тулгач, аларга тантаналы шартларда кылыч тоттырганнар; 14 яшьтән 21 яшькә кадәр алар сюзеренның корал йөртүчесе булганнар, атта йөрергә, корал тотарга өйрәнгәннәр. Яшь егет походларда һәм ауда сюзерен янында булган, рыцарь турнирларында һ. б. катнашкан; 21 яшь тулгач махсус йола буенча аларга рыцарь исеме бирелгән. Күренекле феодалларның башка малайлары гаиләдә калган. Алар анда рыцарь әхлагы күнекмәләре һәм замок капелланыннан дин сабаклары алганнар, кайвакыт уку-язуга өйрәнгәннәр, ә кайберләре, епископ сараена барып, чиркәү хезмәтенә әзерләнгәннәр.

Затлы гаилә кызларының белеме егетләрнекенә караганда югарырак булган. Аларның күбесе монастырьларда махсус уку курслары узган. Кайберләре латин авторларының проза һәм поэзия әсәрләре белән таныш булганнар.

Схоластика. Урта гасырларда университетларның барлыкка килүе һәм үсеше. Цех, гильдия һәм шәһәр мәктәпләре. XII – XIII гасырларда Көнбатыш Европа илләре арасында икътисади элемтәләр ныгый, феодаль йомыклык кими бара, шәһәрләр үсә, аларда һөнәрчелек һәм сәүдә алга китә. Югары җәмгыять мәдәнияте үсә. Хөкем сөрүче дин кагыйдәләренә каршы килә торган дини тәгълиматлар (ересь) барлыкка килә һәм тарала. Динне философия белән ныгыту зарурлыгы,

сукырларча ышанмау, әмма ышанган нәрсәңне аңлау зарурлыгы туа. Бу бурычны XII – XIII гасырларда схоластика үз өстенә ала, ул инану һәм акылны, дин һәм фәнне, килештерүне максат итеп куя. Номинализм һәм реализм теорияләре барлыкка килә. Номинализм теориясе тарафдарлары гомуми төшенчәләр юк, алар бары тик исемнәр, кеше акылының абстракт төшенчәләре генә, дип раслыйлар; реализм юнәлеше вәкилләре исә, киресенчә, гомуми төшенчәләр әйберләрдән дә алданрак яшәгән, диләр. Маркс номинализмны материализмның беренче, әлегә йомшаграк чагышылы дип әйткән. Номинализм белән реализм арасында кискен көрәш бара, дини-фәлсәфи темаларга диспутлар оештыра. Схоластика ул чорда формаль-логик фикерләүне үстерә, кагып калган дини-фәлсәфи фикерне җанландыра. Әмма соңрак схоластика юкка чыга, еш кына файдасыз фәлсәфә сатуга кайтып кала, алга таба хәрәкәт итүдә киртә була. Мәктәп һәм мәгариф өлкәсендә ул укучыларның еш кына схоластик сорау-җавап формасында бирелгән әзер билгеләмәләрне ятлауларына, мөстәкыйль фикер йөртүдән баш тартуга китерә.

XII гасырда Италия, Франция, Англиядә, аннары башка илләрдә дә университетлар ачыла. Урта Европада XIV гасырда Чехиядә (Прагада), бераз соңрак Польшада (Краковта) университет ачыла.

Кагыйдә буларак, урта гасыр университетлары галимнәр инициативасы белән барлыкка киләләр һәм үзидарә хокукыннан файдаланалар, ягъни яшәү тәртипләрен үзләре билгелиләр, хезмәт урынындагы кешеләрне (ректор һ. б.) үзләре сайлап куялар һәм үз хокукларын бик тырышып яклыйлар.

Чиркәү, укытуга монополиясеннән файдаланып, шундук университетларны үзенә буйсындырырга омтыла, аларга төрле өстенлекләр һәм матди ярдәм (бенефицияләр) бирә, үз университетларына нигез сала. Мәсәлән, XII гасырда Париж университетына нигез салына, ул башка католик университетларына үрнәк була. Әкренләп чиркәү университетларга баш булып ала, дини тәгълимат факультеты иң мөһим факультетка әверелә.

Урта гасыр университетларында дүрт факультет була. Әзерлек, ягъни артистлык (сәнгать) факультетында "ирекле җиде сәнгать" укытыла. Урта мәктәп ролен уйнаган бу факультетта 6-7 ел укыгач, аны тәмамлап чыгучылар сәнгать магистры дәрәҗәсен алалар. Аннары төп өч факультетның берәрсендә (дини тәгълимат, медицина яисә

юридик факультетта) укуны дәвам иттерү мөмкинлеге бирелә. Анда 5-6 ел укыганнан соң фәннәр докторы исемен алырга була.

Университетта укытуның төп формасы лекция була: профессор китаптан текстны укый һәм шәрехләп бирә. Шулай ук алдан хәбәр ителгән доклад тезислары нигезендә диспутлар оештырыла.

Шәһәрләрдә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләрне чиркәү мәктәпләре канәгатьләндерми, алар чиркәүнең мәгариф өлкәсендә монополиясенә каршы көрәшәләр.

Һөнәрчеләр үзләренең цех мәктәпләрен ачалар, анда аларның балалары туган телләрендә укырга-язарга, хисапка өйрәнәләр, дин сабаклары алалар, һөнәргә исә өйдә, әтиләренең остаханәләрендә өйрәнәләр. Купецлар да шундыйрак программалы гильдия мәктәпләре ачалар. Бу мәктәпләрдә белем бирү чиркәү мәктәпләрендәгедән шактый аерыла. Әкренләп алар шәһәр үзидарәсе (магистрат) карамагындагы шәһәр башлангыч мәктәпләренә әвереләләр.

Яңарыш чорында (XIV – XVI гасырларда) мәктәп һәм педагогик фикер. Феодаль җәмгыятьтә капиталистик җитештерү ысулының яралгылары барлыкка килү, мануфактура, сәүдә һәм шәһәрләр үсеше, яңа, ул вакыт өчен прогрессив сыйныф — буржуазия килү — Яңарыш чорының үзенчәлекләре әнә шулар.

Буржуазия феодализм белән көрәштә үз идеологиясен булдыра. Буржуазиянең фәнгә ихтыяҗы була, шуңа күрә ул чордагы фәннең чиркәүгә каршы восстаниесендә катнаша. Яңарыш чорында математика, астрономия, механика, география, табигать белеме зур үсеш ала. Бу төрле өлкәләрдәге бөек ачышлар һәм уйлап табулар чоры була: Европада китап басуга нигез салына, һиндстанга диңгез юлы һәм Америка ачыла.

Яңарыш чоры эшлеклеләре — гуманистлар — алгы планга кеше культын куялар һәм шәхесне коллыкка төшерүче дөньяга — дини карашка каршы нык көрәшәләр. Әмма алар күтәреп чыккан прогрессив таләпләр чикләнгән күләмдәге кешеләргә — җәмгыятьнең югары катлавына гына кагыла. Алар крестьяннарны изүгә каршы чыкмыйлар, крестьяннарның белемгә хокукын якламыйлар, халыкны мәгърифәтле итү турында аз кайгырталар, гади халыкның төп шөгыле физик хезмәт булырга тиеш дип саныйлар.

Гуманистлар асыл сөяк балаларының тулы кыйммәтле физик һәм эстетик тәрбия алуларын, антик әдәбият җәүһәрләрен өйрәнү өчен кирәкле латин һәм грек телләрен белүләрен таләп итәләр.

Белəм бирү программасына шулай ук математика, астрономия, механика, табигать белеме кебек табигать фəннəрен кертəлəр.

Гуманистлар бала шəхесенə ихтирам белəн карыйлар, схоластик укыту һəм каты тəртиплəргə каршы чыгалар.

Гуманист педагоглар җитəкчелек иткəн мəктəплəрдə уку эчтəлегенə чиркəү йогынтысы аз була, əмма шулай да дин шактый мөһим урын били.

Гуманистларның педагогик карашлары аксөяк һəм бай балалары укыган аерым мəктəплəр практикасында гына чагылыш таба.

Шул ук вакытта шəһəр мəктəплəре дə үсүлəрен дəвам итə, ул мəктəплəрдə һөнəрче һəм сəүдəгəр балалары башлангыч белем ала. Кызлар мəктəплəре ачыла (кагыйдə буларак, хосусый мəктəплəр). Шəһəр мəктəплəренең күбесендə уку туган телдə бара. Башлангыч мəктəплəр белəн беррəттəн, XVI гасырда югары (латин мəктəплəре) һəм урта мəктəплəр (коллегиум, гимназиялəр) эшлəгəн. Хəлле кешелəрнең балалары өчен ачылган бу мəктəплəрдə 8-10 ел укытканнар. Католик чиркəвенə каршы көрəшүче кайбер сектант оешмалары, мəсəлəн, Урта Европадагы анабаптистлар, Чехиядəге таборитлар һ. б., үз секталарына кергəн кешелəрнең балалары өчен туган телдə гомуми башлангыч белем бирүне оештырганнар.

Яңарыш чорында педагогик фикер төрле иллəрдə төрлечə үскəн, чөнки ул һəр илнең үзенə генə хас үзенчəлеклəрен чагылдырган.

Мəсəлəн, Италиядə антик фəлсəфə белгече гуманист Витторино да-Фельтре (1378-1446) "Сөенеч йорты" исемле мəктəп оештыра. Бу мəктəп гуманлы педагогика принципларына нигезлəнə.

Мəктəпне табигать кочагындагы менə дигəн сарайда ачалар. Бинаны баштанаяк Витторино күрсəтмəлəре нигезендə мəктəп ихтыяҗларында махсус рəвештə яңадан җиһазландыралар. Урта гасыр мəктəплəреннəн аермалы буларак, яңа мəктəп чиста һавалы, якты була. Укучыларның физик тəрбиясенə аеруча зур игътибар бирелə. Классик теллəр һəм классик əдəбият төп укыту предметлары була, укучылар математика, астрономия белəн шөгыльлəнəлəр, табигатькə экскурсиялəр ясыйлар. Уенга, кешенең физик һəм рухи көчлəрен үстерүгə зур əһəмият бирелə.

Гуманизм идеялəре Италиядəн Франциягə дə үтеп керə.

Яңарыш чоры педагогик фикеренең иң күренекле вəкиллəреннəн берсе француз язучы — гуманисты Франсуа Рабле (1494-1553) була. Атаклы "Гаргантюа һəм Пантагрюэль" романында ул Урта гасыр

схоластик тәрбиясен тасвирлауда үткен сатира алымы куллана, схоластик тәрбиягә гуманистик тәрбияне каршы куя. Гуманистик тәрбия бала өчен яхшы уйланган режим, күпъяклы белем алу, мөстәкыйль фикерләүне, иҗат һәм активлыкны үстерүне күздә тота.

Романның эчтәлеге болай: улы Гаргантюаны тәрбияләү өчен король һәммә нәрсәне ятларга мәҗбүр итүче схоласт галимнәрне чакыра. Гаргантюа кайбер схоластик китапларны баштан ахырына кадәр һәм, киресенчә, ахырыннан башына кадәр сөйли алырлык итеп ятлый, нәтиҗәдә томаналана гына.

Шуннан соң әтисе, схоласт укытучыларны куып чыгарып, гуманист укытучы чакыра. Бу укытучы бөтен нәрсәне кискен үзгәртә. Гаргантюа физик күнегүләргә күп вакыт бирә, фәннәрне дөрес һәм эзлекле үзләштерә башлый. Урман-кырларга чыгып табигатьне күзәтә, үсемлекләрне җыеп гербарий төзи; йолдызларны күзәтеп астрономияне өйрәнә. Укыту күргәзмә әсбаплар кулланып китаплар уку, әңгәмәләр юлы белән алып барыла. Гаргантюа берничә музыкаль инструментта уйнарга, җырларга өйрәнә. Фәннәрне аңлап үзләштерә.

Рабле укытуның күргәзмәлелеге, тормышчанлыгы идеясен яклый. Ул укытуны әйләнә-тирә чынбарлык белән бәйләргә киңәш итә.

Яшь буынны хезмәт эшчәнлеге процессында тәрбияләү фикерен беренче булып инглиз гуманисты Томас Мор (1478-1535) әйтә. Теоретик белем бирүне хезмәт белән берләштерү идеясен дә нәкъ менә ул күтәреп чыга.

"Иң яхшы дәүләт төзелеше һәм Утопия исемле яңа утрау турында файдалы һәм кызыклы алтын китап" дигән әсәрендә (1516) Англиянең гаделсез социаль җәмгыятен кискен тәнкыйтьли һәм аңа Утопия исемле фантастик утраудагы идеаль стройны каршы куя. Ул утрауда хосусый милек булмый. Морның социализмы фәнни түгел, бары хыялый гына була. Мор җәм-гыятьнең барлык әгъзаларының ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен дворяннардан, дин әһелләре һәм башка эшлексезләрдән котылу җитә дип исәпли. Шул ук вакытта ул "Утопия"дәге бөтен авыр һәм пычрак эшләрне хәрби колларга һәм үлем җәзасыннан йолынган җинаятьчеләргә йөкли. Болар утопик социализмга нигез салучының карашлары җитлекмәгән һәм тарихи яктан чикләнгән булуын раслый.

Томас Мор тәрбиягә зур әһәмият бирә. Аның сурәтләвенчә, "Утопия" утравында барлык балаларга — малайларга да, кызларга да — бертигез иҗтимагый тәрбия һәм башлангыч белем бирелә; бөтен

кеше киң белем ала. Укыту туган телдә алып барыла. Уку һәм язудан тыш, мәктәпләрдә арифметика, геометрия, астрономия, музыка, диалектика, табигать белеме өйрәтелә. Утопиялеләр күргәзмә әсбаплардан киң файдаланалар.

Мор яшь буынны хезмәт эшчәнлегенә әзерләүгә зур игътибар бирә һәм шәхеснең төрле яклап үсеше турында кыйммәтле фикерләр әйтә. Ул болай ди: барлык утопиялеләр дә шөгыль-ләнергә тиешле бер эш бар, ул да булса — җир эшкәртү. Балалар җир эшкәртү теориясен мәктәпләрдә өйрәнәләр, ә практиканы шәһәр тирәсендәге кырларда үтәләр. Җир эшкәртүдән тыш, һәрбер утопиялегә тагын нинди дә булса махсус һөнәр билгеләнә, һәрбер кеше аны өйрәнергә тиеш була. Физик хезмәт һәрбер утопияле өчен мәҗбүри булса, акыл хезмәте исә иң зур хозурлык санала. Бик аз кешеләр генә, фәкать акыл хезмәте белән шөгыльләнеп, физик хезмәттән азат итәләр. Болар — аерым билгеләнгән җәмәгать йортларында фән белән шөгыльләнүче галимнәр. Ләкин өметне акламасалар, аларны яңадан һөнәрчелек һәм җир эшкәртүгә кайтаралар.

Буш вакытларын утопиялеләр китапханә һәм музейларда үткәрәләр, бик мавыгып белемнәрен күтәрәләр. Теләүчеләрнең барысына да дәүләт шул китапханә һәм музейлардагы китаплар, приборлар һ. б. дан файдаланырга тулы хокук бирә. Күп кенә гади гражданнар, үзлекләреннән тирән белем алып, галимлеккә күчереләләр.

Педагогик фикерне үстерүдә Томас Морның педагогик идеяләре зур әһәмияткә ия була. Ул гомуми белем бирү принцибын тәкъдим итә, хатын-кызлар һәм ирләрнең бертөрле белем алырга тиешлеген әйтә, үзлегеңнән белем алуны, өлкәннәрне укытуны киң оештыру фикерен күтәреп чыга, хезмәт белән тәрбияләүнең мөһимлеген ассызыклый, акыл һәм физик хезмәт арасындагы каршылыкны бетерү мөмкинлеге турындагы идеяне беренче булып әйтә. Туган телдә укытуны таләп итә, уку предметларының үзәгендә табигать белеме булган киң даирәсен билгели. Мор башлангыч утопик социализм педагогик идеяләренең беренче хәбәрчесе була.

Шулай итеп, феодаль җәмгыять эчендә капиталистик җитештерү ысулы туу һәм үсү тәрбиягә карашта шактый зур үзгәрешләргә китерә. Яңа теорияләр туа. Яңа сыйныфның белем алу ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешле мәктәпләр дә барлыкка килә.

**4.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. В чем состоит особенность начального периода развития просвещения на Руси? Какими были идеалы воспитания?

2. Что являлось характерным для школьного обучения в Русском государстве в XIV – XVI вв.? Охарактеризуйте принципы организации школ, содержание обучения в них.

3. Каковы были главные изменения, произошедшие в воспитании и обучении в 1700-х гг. в России?

**4.2. Задания для практики.**

Назовите основные, на ваш взгляд, противоречия в развитии школы и педагогической науки России первой половины XIX в.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 4» , добавить вопросы для самоконтроля.

**4.3. Глоссарий по теме 4.**

**Воспитание нравственное** — формирование нравственных отношений, способности к их совершенствованию и умений поступать с учетом общественных требований и норм, прочной системы привычного, повседневного морального поведения. **Воспитание политическое** — формирование у учащихся политического сознания, отражающего отношения между государствами, нациями, партиями, и умений разбираться в них с духовно-нравственных и этических позиций. Осуществляется на принципах объективности, вариативности, свободы выбора позиции и оценок в границах общечеловеческих ценностей. **Воспитание половое** — систематическое, сознательно планируемое и осуществляемое воздействие на формирование полового сознания и поведения детей, подготовка их к семейной жизни. **Воспитание правовое** — процесс формирования правовой культуры и правового поведения, заключающийся в осуществлении правового всеобуча, преодолении правового нигилизма, формировании законопослушного поведения.

**Воспитание трудовое** — совместная деятельность воспитателя и воспитанников, направленная на развитие у последних общетрудовых умений и способностей, психол. готовности к труду, формирование ответственного отношения к труду и его продуктам, на сознательный выбор профессии. Путь В. т. — включение школьника в полную структуру труда: его планирование, организацию, осуществление, контроль, оценку.

**Воспитание умственное** — формирование интеллектуальной культуры, познавательных мотивов, умственных сил, мышления, мировоззрения и интеллектуальной свободы личности. **Воспитание физическое**— система совершенствования человека, направленная на физическое развитие, укрепление здоровья, обеспечение высокой работоспособности и выработку потребности в постоянном физическом самосовершенствовании. **Воспитание художественное** — .формирование у воспитанников способности чувствовать, понимать, оценивать, любить искусство, наслаждаться им, развитие потребностей в художественно-творческой деятельности и создании эстетических ценностей. **Воспитание экологическое** — целенаправленное развитие у подрастающего поколения высокой экологической культуры, включающей в себя знания о природе и гуманное, ответственное отношение к ней как к наивысшей национальной и общечеловеческой ценности.

**Воспитание экономическое** — целенаправленное взаимодействие воспитателей и воспитанников, направленное на формирование у последних знаний, умений и навыков, потребностей, интересов и стиля мышления, соответствующих природе, принципам и нормам рационального хозяйствования и организации производства, распределения и потребления.

**Воспитание эстетическое** — целенаправленное взаимодействие воспитателей и воспитанников, способствующее выработке и совершенствованию в подрастающем человеке способности воспринимать, правильно понимать, ценить и создавать прекрасное в жизни и искусстве, активно участвовать в творчестве, созидании по законам красоты.

**4.4. Использованные информационные ресурсы.**

1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.

**Тема 5.** ***МОНОПОЛИСТИК КАПИТАЛИЗМГА КАДӘРГЕ ЧОРДА МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИКА. ЯН АМОС КОМЕНСКИЙНЫҢ ПЕДАГОГИК ТЕОРИЯСЕ***

**Аннотация.** Данная тема раскрывает педагогические идеи Я.А. Коменского.

**Ключевые слова.** Великая дидактика, педагогические идеи, мыслители.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

## *МОНОПОЛИСТИК КАПИТАЛИЗМГА КАДӘРГЕ ЧОРДА МӘКТӘП ҺӘМ ПЕДАГОГИКА. ЯН АМОС КОМЕНСКИЙНЫҢ ПЕДАГОГИК ТЕОРИЯСЕ*

XV – XVII гасырларда халык массаларының феодаль дворяннар һәм феодализмның идеологик терәге булган католик чиркәү белән көрәше кискенләшә. Феодализмга каршы протест еш кына дини-демократик, сектантлык хәрәкәте формасын ала.

Шундый демократик сектант оешмалары арасында Чехиядә XV гасырда христиан-коммунистик таборитлар общинасы була, общинаның исеме шушы хәрәкәтнең үзәге Табор шәһәреннән алынган. Таборитлар Чехиядәге гусит милли-дини хәрәкәтенең төп, плебейлар канаты булып, бу хәрәкәт чех халкын изүче немец дворяннарына һәм католик чиркәүгә каршы юнәлә. Таборитлар әйтүенчә, тиздән "әфәнделәр дә, ялчылар да" булмаячак, бөтен кеше бертигез булачак, шәхси милек бетәчәк, һәммә нәрсә уртак булачак.

Феодаль реакциянең берләштерелгән көчләре XV гасырның беренче яртысында таборитлар общинасын тар-мар итә. Аның калдыкларыннан "чех (богема) туганнар" дигән уртачыл карашлы демократик община оеша, аңа крестьяннар һәм һөнәрчеләр керә. Бу община чех халкының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшүче патриотларны туплый. Чехларның азатлык хәрәкәте феодализмга каршы Европа халыклары алып барган көрәшнең бер өлеше була.

Утыз еллык сугыш чорында (1618-1648) чех протестантлары илләреннән куыла.

"Чех туганнар" общинасының юлбашчыларыннан берсе бөек славян педагогы **Ян Амос Коменский (1592-1670)** була. Ул "чех туганнар" общинасына кергән гаиләдә туа, община акчасына урта һәм югары белем ала, аннары общинаның священнигы итеп сайлап куела һәм аның туганнар мәктәбен җитәкли. **Коменский** немец дворяннары һәм католик чиркәве золымына каршы көрәштә актив катнаша. Утыз еллык сугыш вакытында общинаның башка әгъзалары белән ул да эзәрлекләнә, илен ташлап китәргә мәҗбүр була. "Чех туганнар"ның бер өлеше килеп урнашкан Польша шәһәре Лешнода **Коменский** туганнар мәктәбен җитәкли, соңрак епископ итеп сайлана. Бирелә 1631 елда ул "Телләрнең һәм барлык фәннәрнең ачык ишеге" дигән уку китабы төзи, бу китапта латин телен үзләштерү әйләнә-тирә дөньяны өйрәнү белән бергә бара. Сөргендәге авыр тормыш шартларына да карамастан, **Коменский** бу чорда үзенең атаклы **"Бөек дидактика"** әсәрен яза (1632), бу хезмәт укыту процессы турындагы фәнгә нигез сала. Китап бик күп телләргә тәрҗемә ителә һәм Коменскийны бөтен дөньяга таныта. Шул ук елларда **Коменский** мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләү буенча "Ана мәктәбе" дигән дөньяда беренче махсус кулланма яза (1633).

Үзенең күп газаплар чигүче иленә хезмәт итүне Коменский бөтен дөньяга хезмәт итү белән бергә алып барырга тырышкан. Ул төрле яклап социаль үзгәртеп корулар идеясе белән чыккан. Канлы сугышлар һәм каты сәяси һәм дини ызгышлар чорында ул дөньяда тынычлыкны саклауны, сәясәт, фән һәм мәгърифәт өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек урнаштыруны таләп иткән. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм иҗтимагый тормышны яхшырту максатларында дөньяның барлык илләре белән элемтә тотучы универсаль үзәк төзергә тәкъдим итә. **Коменский** "Кешеләрнең эш-гамәлләрен төзәтү турында гомуми киңәш" дигән бик зур хезмәтнең 7 томын яза. (Үзе исән чагында нибары 2 томы дөнья күрә, калганнары 1935 елда гына табыла һәм соңрак Чехословакия Республикасында басылып чыга.) Китапта ул гуманлы һәм демократик "**Һәммә кешеләрне һәммә нәрсәдә төрле яклап төзәтү**" программасын билгели.

Аның халыкара элемтәләре бик киң була. Англиядә ул табигать һәм җәмгыять турында бөтен кешегә дә аңлашырлык энциклопедик белемнәр җыелмасы "Пансофия" өстендә эшли.

Мәсхәрәләнгән иленә Швециянең ярдәм итүенә өметләнеп, Коменский шунда яши, телләр укыту методикасы һәм дәреслекләр төзи. Ул шулай ук Венгриядә дә яши, анда мәктәп мәсьәләләре буенча консультант булып эшли. Күп кенә фәлсәфи һәм педагогик әсәрләрен, шул исәптән "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә" дигән гүзәл уку китабын, шунда яза. Бу китап бик күп телләргә тәрҗемә ителә.

1656 елда Швеция — Польша сугышы вакытында "чех туганнар" общинасының соңгы сыену урыны булган. Лешно шәһәре яндырылгач, Коменский Голландиянең Амстердам шәһәренә килә, шунда 1670 елда вафат була.

**Коменскийның дөньяга карашында стихиячел материализм, гуманизм һәм демократизм.** Коменскийның әсәрләрендә шул чорның яңа идеяләре тирән чагылыш таба. Шул вакыттагы халык хәрәкәтләреннән, аерым алганда "чех туганнар"дан, Коменский демократизм, хезмәт ияләренә тирән мәхәббәт, дворяннарга һәм католик чиркәвенә тискәре мөнәсәбәт ала. Ул ачу белән: хәзерге стройда берәүләр артыгын ашый, икенче берәүләр исә ачтан интегә, өстәвенә күпчелек авыр хезмәткә дучар ителгән, дип билгеләп үтә. Коменскиинын демократлыгы бердәм мәктәп булдыруны, нинди катлаудан булуларына, байлыкларына һәм җенесләренә карамастан туган телдә гомуми мәҗбүри белем бирүне таләп итүендә күренә.

Коменскийның дөньяга карашындагы күп кенә сыйфатлар Яңарыш чоры мәдәнияте йогынтысында барлыкка килә. Яңарыш чорыннан ул гуманизм, көр күңеллелек, оптимизм кебек сыйфатлар ала. Урта гасырлардагы караңгы суфыйлыкка, кеше табигатенең гөнаһлылыгы турында чиркәү өйрәтүләренә каршы буларак, Коменский: кеше — иң камил, иң гүзәл җан иясе, "гаҗәеп микрокосм", дип өйрәтә. Коменский әйтүенчә, "табигать җитәкчелегендә кеше һәммә нәрсәгә ирешә ала". Кеше — тән һәм җан гармониясе ул. Мәктәпне Коменский "гуманлылык остаханәсе" дип саный.

Яңарыш чоры гуманист педагогларыннан аермалы буларак, Коменский тәрбия системасын аерым кешеләр өчен түгел, җәмгыятьнең аксөяк югары катлавы өчен түгел, ә халыкның демократик катлаулары, халык массасы өчен иҗат итә.

**Коменский дидактикасының** төп идеяләр сенсуалистик характерда: чынбарлык дөньяны тоеп белү нигезендә танып белү, реализм, күргәзмәлелек принцибы. Коменский раславынча, "интеллектта элек сиземләүләрдә булмаган берни дә юк". Бу Бэконның сенсуалистик фәлсәфәсенә туры килә, ә ул **инглиз материализмына** һәм **хәзерге заманның тәҗрибәләр ясаучы** фәненә чын нигез салучы була. Коменский Бэконның "Фәннәрне бөек торгызу" әсәрен фәлсәфәнең туып килүче яңа гасырындагы иң якты әсәр дип атый. Бэконның индуктив методында ул "табигать серләренә үтеп керү" юлын күрә.

**Коменский** барлык балаларны да — баймы ул, ярлымы, аксөякләр нәселеннәнме, гади нәселдәнме, малаймы ул, кызмы, шәһәрдә яшиме, авылдамы — туган телләрендә укытуны таләп итә. Башкача әйткәндә, Коменский гомуми башлангыч белем бирү идеясен күтәреп чыга. Аның "ярлылар арасында еш кына гаҗәп сәләтле кешеләрнең күренми калып юкка чыгуларына" ачуы кабара.

**Коменскийның** дөньяга карашларында, бер яктан, стихиячел материализм, реализм элементлары, тормышка, тәҗрибәгә таяну омтылышы, икенче яктан, динилек бергә үрелеп бара. Аныңча, дөнья — "ходай иҗаты", танып белү — "һәммә нәрсәдән ходайны эзләү". Фани дөньяны Коменский бакый дөньяга әзерлек кенә дип саный һәм тәрбиянең максатын шунда күрә. Дөньяга карашындагы шушындый капма-каршылык аның педагогикасында да чагылыш таба.

**Коменский** фикеренчә, **тәрбиянең** өч баскычы, өч бурычы бар: үз-үзеңне һәм әйләнә-тирә дөньяны таный белү (акыл тәрбиясе), үз-үзеңне идарә итү (әхлакый тәрбия) һәм аллага омтылу (дини тәрбия). Урта гасыр педагогларыннан аермасы буларак, ул беренче бурычны хәл итү бик мөһим дип санаган.

**Коменский** тәрбиянең ролен бик югары бәяли. Кеше — тәрбияләнгәнгә күрә генә кеше була, ә тәрбияләү өчен иң кулай вакыт — балачак, ди ул. Аныңча, "теләсә нинди баланы чын кеше итәргә мөмкин". Сәләтле, тырыш һәм педагог йогынтысына тиз бирелүчән балалар белән беррәттән, бик аз гына булса да сәләтсез, ялкау һәм кире балалар да бар, әмма аларын да тәрбияләргә һәм укытырга кирәк, дип исәпли.

Коменскийның бөтен педагогик әсәрләрендә, аеруча төп иҗаты булган "Бөек дидактика" әсәре аша кызыл җеп булып дөрес тәрбия һәр очракта да табигать белән ярашырга тиеш дигән фикер уза.

Тәрбиянең табигатькә муафыйклыгы принцибы, Коменскийдан башлап, XVIII, XIX гасырлар педагогик системаларында еш очрый, шуның белән бергә атаклы педагогика теоретикларының һәрберсе (**Коменский, Руссо, Песталоцци**, **Дистервег** һ. б.) бу принципны үзенчә аңлый.

Коменский, **табигатьнең бер өлеше буларак кеше аның төп, гомуми законнарына буйсына, бу законнар үсемлек һәм хайваннар дөньясында да, шулай ук кешегә мөнәсәбәттә дә гамәлдә,** дип исәпли. Аныңча, "мәктәпнең төгәл тәртибен табигатьтән алырга кирәк", "табигать гамәлләрендә күренә торган процессларны" күзәтүдән чыгып эш итәргә кирәк. Ул тәрбия закончалыкларын табигать законнарына охшатып билгеләргә тиеш. Коменскийның дөрес дидактик фикерләрен аның бәян итү формасыннан аера белергә кирәк.

Коменский үзенең тәрбия һәм укыту өлкәсендәге тирән гомумиләштерүләренә җәмгыять тормышын, тәрбия тормышын күзәтүләрдән, педагогик тәҗрибәдән чыгып килгән. Үзенең укытучылык эшчәнлеге һәм чорның алдынгы педагогик тәҗрибәсе нигезендә Коменскийда "Бөек дидактика" әсәрендә чагылыш тапкан тирән теоретик фикерләр туа һәм формалаша. Педагогик тәҗрибәсен ул фәлсәфи яктан нигезли. Элек һәрбер педагогик положениене дини дәлилләр, гадәттә, изге язмалардан алынган өзекләр белән нигезләгәннәр.

Коменский, бу иске ысулдан һич кенә дә баш тартмыйча, дәлилләүнең Яңарыш чоры алып килгән яңа ысулын — табигатькә таянуны кертә һәм табигать белән тәрбиянең гомуми закончалыкларын формалаштырырга тырыша.

Табигать законнары турында сөйләгәндә, ул табигатьне ходай иҗаты дип саный. Хәер, мондый тарихи чикләнгәнлек ул чорның барлык галимнәренә, хәтта чиркәү тәгълиматларын кире кагучы, табигатьнең төрле өлкәләрендәге чын законнарны ачучыларына да, хас була.

Тәрбиянең табигатькә муафыйклыгы принцибының табигатьнең гомуми законнарына иярү икәнлеген аңлау белән бергә, Коменский яшь чорларына бүлү, мәктәп системасын һәм кайбер дидактик принциплар һәм кагыйдәләрне нигезләгәндә кешенең табигатенә (тумыштан килгән сыйфатларга) һәм балаларның табигый яшь үзенчәлекләренә таяна.

**Яшь чорларына бүлү. Мәктәпләр системасы һәм укытуның эчтәлеге.** Коменский, кешенең табигатеннән чыгып, үсеп килүче буынны дүрт яшь чорына бүлә, аларның һәрберсе алтышар ел:

- **балалык чоры — туганнан алып 6 яшькә кадәр,**
- **үсмерлек чоры — 6 яшьтән 12 яшькә кадәр,**
- **яшьлек чоры — 12 яшьтән 18 яшькә кадәр,**
- **балигъльк чоры — 18 яшьтән 24 яшькә кадәр.**

Бу бүленешнең нигезенә ул яшь үзенчәлекләрен куя: балалык чорында буй һәм сизу органнары яхшы үсә; үсмерлек чорында хәтер һәм хыял, шулай ук аларның башкаручы органнары - тел һәм кул үсеш ала; яшьлек чоры, күрсәтелгән сыйфатлардан тыш, фикерләү ("аңлау һәм хөкем йөртү") үсешенең югарырак дәрәҗәсе белән характерлана; балигъльк чорында ихтыяр һәм гармония саклау сәләте үсә.

Бу яшь чорларының һәрберсе өчен, яшь үзенчәлекләреннән (баланың табигатеннән) чыгып, **Коменский белем алуның аерым баскычларын билгели.**

6 яшькә кадәрге балалар өчен ул әниләр мәктәбе тәкъдим итә, биредә ана җитәкчелегендәге мәктәпкәчә тәрбия күздә тотыла. Үсмерлек чорына (ягъни 6 яшьтән 12 яшькә кадәрге балалар өчен) һәр общинада, авылда алты еллык **туган тел мәктәбе** каралган. Яшьләргә (12 яшьтән 18 яшькә кадәр) һәр шәһәрдә **латин мәктәбе**, яисә **гимназия** булырга тиеш. Балигъ булган яшьләргә (18 яшьтән 24 яшькә кадәр) һәрбер дәүләттә, яисә зур өлкәдә **академия** ачуны күздә тота.

Һәр алдагы баскыч үткәннең дәвамы булып тора. Шул рәвешле, Коменский **бердәм мәктәп демократик принцибын күтәреп чыга.**

Академиядән кала һәр баскыч өчен Коменский укыту эчтәлеген җентекләп эшли. **Әниләр мәктәбе**, балаларның табигый үзенчәлекләрен исәпкә алып, алты яшькә кадәр балаларга безне чолгап алган табигать һәм җәмгыять тормышы турында башлангыч мәгълүматлар, җанлы тәэсирләр бирергә тиеш. Балалар табигать белеме өлкәсеннән су, җир, һава, ут, яңгыр, кар, боз, таш, тимер, агач, үлән, балык, кош, үгез һ. б. боларның нәрсә икәнлеген белергә тиеш. Бала астрономиядән нәрсәнең һава, кояш, ай, йолдыз дип аталуын, аларның кайда чыгып кайда батуын белә. Шулай ук ул географиядән дә башлангыч мәгълүмат ала (тау, үзән, елга, авыл, шәһәр һ. б.).

Коменский балаларны бик кечкенәдән хуҗалык алып барырга, хезмәткә өйрәтергә, моның өчен аларны йорт кирәк-яраклары һәм аларның кулланылышы белән таныштырырга киңәш итә. Мәктәпкәчә

яшьтәге балаларның әхлак тәрбиясе, ди ул, аларда чама хисе, пөхтәлек, эш сөючәнлек, өлкәннәргә ихтирам, тыңлаучанлык, туры сүзлелек, гаделлек һәм, иң мөһиме, кешеләрне ярату хисе тәрбияләүдән гыйбарәт.

Коменскийның иң зур хезмәте шунда ки, ул мәктәпкәчә тәрбия буенча "Әниләр мәктәбе" дигән дөньяда беренче кулланма эшли.

Туган тел мәктәбе, Коменский фикеренчә, алты еллык булырга тиеш. Анда, нинди катлаудан, нинди милләттән булуларына һәм нинди дин тотуларына карамастан, малайлар да, кызлар да белем алсын.

Ул заманнардагы башлангыч мәктәпләр ике-өч еллык кына булган, анда догалар ятлау, уку, язу һәм иң гади исәп-хисапка өйрәтү белән чикләнгәннәр. Коменскийның бик зур хезмәте шунда: ул **башлангыч мәктәпнең әһәмиятен күтәргән,** ягъни укуның вакытын арттырган, аның туган тел мәктәбе булуына басым ясаган (ә руханилар кулындагы чиркәү мәктәпләрендә балаларга аңлаешсыз латин телендә укытканнар), башлангыч мәктәптә укыту эчтәлеген геометрия, география, табигать белеменнән башлангыч мәгълүматлар бирү, җыр һәм хезмәт укыту белән киңәйтелгән. Әлбәттә, дин сабагына зур урын биргән.

**Латин мәктәбендә (гимназиядә) укыту эчтәлеген** Коменский шул чордагы урта мәктәптә укыту предметлары даирәсеннән алган: бу "ирекле җиде сәнгать". Әмма шул чордагы схоластик мәктәпнең шушы фәннәренә ул яңа уку предметлары өсти. Болар: физика (табигать белеме ул чагында шулай атала), география, тарих. Гимназиядә латин, грек телләре, туган тел һәм тагын берәр яңа тел укытыла.

Коменский: телне (грамматиканы) өйрәнгәннән соң укучылар табигать белеме (физика), математика, аннары этика, диалектика кебек фәлсәфи фәннәрне өйрәнүгә күчәргә, ә уку курсын риторика өйрәнү белән тәмамларга тиеш, чөнки шушы эзлеклелектә сөйләмнең матурлыгы өстенә эчтәлеклелек һәм тирәнлек тә өстәлә, дип саный. Мәктәп системасындагы гимназиянең алты классының һәрберсенең үз исеме була: грамматика, физика, математика, этика, диалектика һәм риторика класслары.

Фәннәрне ул чор өчен гадәти булмаган шушы эзлеклелектә куюы белән Коменский үзенең фәлсәфи карашларыннан — сенсуализмнан чыгып эш итә, шул заманның новаторы була, әмма бер фәнне (яисә үзара якын берничә фәнне) бер вакытта укыту, аннары гына башка фәннәрне өйрәнүгә күчү ягында була. (XVIII гасыр азагында бер үк

вакытта төрле предметлар укытыла башлый. Хәзерге уку планнары шушы принципның алга таба үстерелеше булып тора).

Академиядә Коменский дини тәгълимат, юридик һәм медицина кебек, ул чор өчен гадәти факультет булырга тиеш дип саный.

**Коменскийның** дидактик карашлары. Сенсуалистик фәлсәфәгә ияреп, Коменский танып белү һәм уку нигезенә тоеп белү тәҗрибәсен куя, **күрсәтмәлелек принцибын** теоретик яктан нигезли һәм җентекләп ачып бирә. Күрсәтмәлелек аңа кадәр дә кулланылган. Аның хакында гуманист педагоглар да, мәсәлән, "Утопия" утравындагы укытуны тасвирлаганда Томас Мор да әйткән булган. Кульязма китапларда да, басма китапларда да рәсемнәр элек тә булган, әмма бу күрсәтмәлелек Коменский биргән теоретик нигезләрдән башка гына, тәҗрибәгә таянып кына кулланылган. Коменский күрсәтмәлелекне киң мәгънәсендә, күрү органнарын гына түгел, ә тою, сизү органнарының барысын да әйберләр һәм күренешләрне яхшырак, ачыграк тоюда эшкә җигү дип аңлый. Ул дидактиканың "алтын кагыйдәсен" игълан итә: "Мөмкин булган һәммә нәрсәне хис-тойгы белән: күренә торганны — күз белән; ишетелә торганны колак белән; исләрне — борын белән; тәмне — авыз белән; сизеп тоя торганны — капшау юлы белән сиземләп тою мөмкинлеге бирелергә тиеш. Нинди дә булса предметларны берьюлы берничә төрле тойгы белән сиземләп тоеп була икән, аларны берничә тойгы эләктереп алсын".

Коменский укытуны әйберләр турында сүз сөйләүдән түгел, ә аларны конкрет күзәтүдән башлауны таләп иткән. Мөмкин булган һәрнәрсәне табигый хәлендә күзәтергә кирәк, ә турыдан-туры күзәтү мөмкин булмаганда әйберләрне картина, модель, рәсемнәр алыштыра.

**Иң мөһим дидактик принципларның берсе буларак күрсәтмәлелекне** эшкәртүдә Коменский зур хезмәт куя: күрсәтмәле укытуның инде шул чорда булган беркадәр тәҗрибәсен нигезли, гомумиләштерә, тирәнәйтә, киңәйтә, үзенең дәреслекләрен рәсемнәр белән баетып, күрсәтмәлелекне гамәлдә киң куллана.

Реаль дөньяны тәҗрибә аша өйрәнергә чакырып, Коменский "яшьләрнең башына сүз, фикер боткасы тутыручы" схоластик укытуны тәнкыйтьли, "схоластика чытырманлыгыннан чыгарга" (аның бер хезмәтенең исеме шундый) чакыра.

Мәгънәсез, механик ятлауга каршы Коменский аңлы уку таләбен куя. Ул болай дип яза: "Акыл белән яхшы аңланмаган бернәрсәне дә ятлатырга ярамый". Укучылар "укыганнарының көндәлек тормышта

нинди файда китерүен укытучы ярдәмендә ачык аңларга тиешләр. Күренешләрне өйрәнгәндә укучыларны бу күренешләрнең сәбәбен аңлауга китерергә кирәк. "Һәрбер предметны тәмам аңлап бетерми торып өйрәнүдән туктамаска кирәк", ("тәмам аңлап бетергәнче өйрәнергә кирәк").

Коменский **укытуның системалылыгын** яклый. Укучыларга күренешләр арасындагы бәйләнешне аңлауга китерү һәм уку материалын балаларга тәртипсез рәвештә түгел, ә төп положениеләр рәвешендә кыскача гына итеп бирү зарурлыгына күрсәтә. Укытуда, ди ул, фактлардан һәм мисаллардан аларны системалаштыручы нәтиҗәләргә һәм кагыйдәләргә килергә кирәк; конкреттан—абстрактка, җиңелдән—авырга, гомумидан—өлешкә килергә; башка предмет яисә күренеш турында гомуми күзаллау бирергә, аннары аның аерым якларын өйрәнүгә күчәргә кирәк, ди.

Коменский фикеренчә, **укытуның эзлеклелеге** зур әһәмияткә ия. Укучыларга үзләштерергә тәкъдим ителгән материалны шундый итеп бирергә кирәк, ул инде яңа материалны өйрәнүгә әзерлек булсын. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, Коменский башта аларның хис-тойгыларын, аннары хәтерләрен, фикерләүләрен һәм, ниһаять, сөйләмнәрен һәм кулларын үстерергә киңәш итә, чөнки укучы үзләштергәнен дөрес сөйләп бирә һәм эштә куллана белергә тиеш.

Коменский, укыту **балалар көче җитәрлек** булырга тиеш, дигән дидактик таләп белән чыга. Балалар үзләштерәсе материал аларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә тиеш. Укытуның көч җитәрлек, аңлаешлы булуына ачык аңлату, төп фикерне сырлап-бизәкләп тормый җиткерү белән ирешелә.

Укучыларның материалны **нык үзләштерүләре** дидактик таләбен күтәреп, Коменский "ныклы нигез" салу зарурлыгын, укытканда ашыгу ярамавын, укучыларның материалны әйбәтләп үзләштерүләренә ирешү кирәклеген искәртә; бер-берсенә бәйләү мөмкинлеге булган предметлар "бәйләнештә" укытылырга тиеш. Һәр темага кыска, төгәл кагыйдәләр ярдәмендә йомгак ясалырга тиеш.

Яңа материалны яхшылап үзләштерүдә күнегүләрнең һәм үткән материалны кабатлауның әһәмияте гаять зур. Укытучы, яңа материалны аңлаткач, берәр укучыны такта янына чыгарып, әле генә сөйләгәннәрен кабатлата; шуны ук эшләү өчен тагын бер укучыны чыгара. Шундый күнегүләр һәм кабатлаулар ярдәмендә укытучы үзе

сөйләгәннәрдән балаларның нәрсәне аңламаган-лыкларын бик ачык күрә. Берничә тапкыр кабатланган материал хәтердә бик нык кала. Шулай кычкырып кабатлаганда үзләштергән материалыңны сөйләп бирү күнекмәсен үстерүнең әһәмияте бик зур, үзләштерү үзе дә аныграк, ныграк була. Коменский бу максатта укучыларга үзләштергән материалны башкаларга да аңлатырга тәкъдим итә.

"Эшлисе эшне эшләп карап өйрәнергә кирәк",— ди Коменский, күнегүләр оештыру кагыйдәләрен биреп. "Мәктәпләрдә язу осталыгына — язып, сөйләү осталыгына — сөйләп, җырлау осталыгына — җырлап, нәтиҗә чыгару осталыгына — нәтиҗә чыгарып һ. б. өйрәнсеннәр, мәктәп — эш кайнап торган остаханә булырга тиеш". Күнекмәләргә дөрес өйрәтү өчен укучыларга башкарылырга тиешле эшнең билгеле бер формасын һәм нормасын бирү тиеш; инструментларны ничек куллану (мәсәлән, сызым сызганда һ. б.) турында сөйләп кенә калмаска, ә эштә кулланып күрсәтергә кирәк. Күнегүләрне тулы эш башкарудан түгел, ә кечкенә элементлардан башларга кирәк; бу укуга да (башта — хәрефләр һәм иҗекләр, аннары — сүзләр, иң ахырдан — җөмләләр), язуга да, грамматикага да, башка күнекмәләргә дә кагыла.

Балаларга охшату үрнәген күрсәтеп, укытучы башта формага төгәл охшатуны таләп итәргә тиеш, соңыннан бу эш ирекләрәк башкарылырга мөмкин. Укучылар җибәргән барлык төгәлсез-лекләрне укытучы шунда ук төзәтә, кагыйдәләргә таянып искәрмәләр ясый. Укытканда синтез анализ белән берләштерелергә тиеш.

Коменский укучыларның **танып белү сәләтләрен** мөмкин кадәр ныграк **үстерергә**, "белемгә сусау һәм укуга кайнар дәрт кабызырга" омтылган, моның өчен, дигән ул, күңелле нәрсә белән файдалы нәрсәне берләштерергә, балаларның кызыксынучанлыгын хупларга кирәк. "Укучыларымда мин һәрвакыт күзәтүдә, сөйләмдә, практикада һәм кулланылышта мөстәкыйльлек үстерәм",— дип язган ул.

**Мәктәптә укытуны оештыру. Класс-дәрес системасы.** Коменский чирекләргә бүленгән уку елы, каникул төшенчәсен гамәлгә серткән, уку көнен оештыруны билгеләгән (туган тел мәктәбендә I уку сәгате, латин мәктәбендә 6 сәгать), укытуның класс-дәрес системасын теоретик эшкәртеп гамәлдә кулланган.

Ул чорда укучыларны мәктәпкә төрле вакытта, бөтен ел буена кабул иткәннәр. Укучылар класста бергә утырсалар да, күпчелек очракта аларның барысы белән берьюлы күмәк дәресләр

уздырылмаган: һәр укучы үзенә бирелгәнне аерым өйрәнгән, һәр укучының шәхси уку-өлгерү тизлеге булган. Укытучы һәр укучы белән аерым шөгыльләнгән. Коменский мәктәпкә укучыларны елына бер тапкыр гына кабул итүне, укытучының бөтен класс белән күмәк эш алып баруын яклаган. Ул укытуда класс-дәрес системасына нигез салган, дәресләрне планлаштыру һәм алып бару буенча күрсәтмәләр биргән, дәреснең бер өлеше — укучылардан сорауга, икенче өлеше яңа материалны аңлатуга һәм шул материалны хәтердә ныгыту күнегүләренә бирелергә тиеш дигән. Анынча, һәр дәреснең аерым темасы һәм төп бурычы булырга тиеш. Укытучы барлык укучыларның да дәресләрдә актив катнашуларын игътибар белән күзәтергә һәм дәрес вакытында класста тәртип сакларга тиеш.

Коменский төзегән дәреслекләр. Коменский дәреслекнең нинди булырга тиешлеге хакында күп кенә файдалы теоретик фикерләр әйткән, шул чор өчен үрнәк булырдай берничә дәреслек төзеп, үзенең теоретик положениеләрен гамәлгә ашырган. Ул, дәреслектә уку материалы җитәрлек дәрәҗәдә тулы, ләкин дәреслек үзе кыска булырга тиеш, аңда игътибарны төп нәрсәдән читкә юнәлтерлек артык детальләр булмасын, дип таләп итә. Дәреслектә материал системалы урнаштырылып, балаларга аңлаешлы, ачык, гади телдә язылган булырга тиеш.

Коменский төзегән дәреслекләрдән икесе — "Телләрнең һәм барлык фәннәрнең ачык ишеге" (1631) һәм "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә" (1658) — аеруча киң танылa.

Бу дәреслекләрнең беренчесендә Коменский, үзенең дидактик принципларына туры килгән һәм әкренләп катлаулана барган җөмләләр (фразалар) сайлап, бер үк вакытта тел дәреслеге дә, баланы төрле өлкәләрдән ул аңларлык белемнәр белән таныштыручы китап та бирә.

Икенче дәреслек ("Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә") үзенә күрә балалар өчен рәсемнәр белән бизәлгән башлангыч белемнәр энциклопедиясен тәшкил итә, һәрберсе рәсемле 150 кыска мәкаләдә табигать (галәм, географиядән мәгълүматлар, үсемлекләр, хайваннар, кеше тәне турында) кеше эшчәнлеге (һөнәрләр, авыл хуҗалыгы, транспорт, мәдәният һ. б.), иҗтимагый тормыш (дәүләтидарәсе, суд) турында мәгълүматлар бирелә. Шул ук вакытта зур педагогик осталык белән укучыларның сөйләме дә баетыла: дәреслек туган тел һәм латин теленнән мәгълүматлар бирә.

Китап бик күп телләрдә тәрҗемә ителә һәм 150 елдан артыграк башлангыч белем бирүдә яхшы дәреслек хезмәтен үти. XVIII гасырның икенче яртысында бераз эшкәртелеп төрле исемнәр белән ("Күренеп торган яктылык", "Галәм тамашасы") берничә тапкыр Россиядә басылып чыга. Бөек немец шагыйре Гете XIX гасыр башында аны үзе шуннан белем алган үрнәк уку китабы буларак искә ала.

Әхлак тәрбиясе. Тәртип мәсьәләсе. Кешенең үзен идарә итүе, Коменский фикеренчә, тәрбиянең өч максатыннан берсе. Аңа әхлак тәрбиясе нигезендә ирешелә.

Платон һәм Аристотельгә ияреп, Коменский төп, кардиналь яхшылык дип акылны, чама хисен, батырлык һәм гаделлекне санаган. Әйберләр турында дөрес хөкем — игелекнең нигезе, шуңа күрә акыл — игелекле, тормышның җитәкчесе. Чама хисе кешегә һәр нәрсәдә чама белү өчен, беркайчан да күңел бирү, күңел кайтуга кадәр барып җитмәс өчен кирәк. Батырлыкка үз-үзеңне тота алу, чыдамлык, кирәк булганда файда китерергә әзер тору, бурычыңны үтәү кебек сыйфатлар керә.

Шуңа төп яхшылыклардан тыш, Коменский балаларда тыйнаклык, тыңлаучанлык, киң күңеллелек, җыйнаклык, пөхтәлек, итәгатьлелек, өлкәннәргә ихтирамлылык, хезмәт сөючәнлек тәрбияләргә киңәш иткән.

Әхлакый тәрбия чаралары итеп Коменский түбәндәгеләрне санаган: ата-ана, укытучылар, иптәшләренең үрнәге; үгет-нәсихәт, балалар белән әңгәмәләр; балаларның әхлаклы тоту күнегүләре (мәсәлән, батырлык тәрбияләгәндә); бозыклык, ялкаулык, уйлап эш итмәү, тәртипсезлек белән көрәш. Әхлакый тәрбия процессында әйбәт гадәтләр булдыруның әһәмияте бик зур.

Дисциплинаның әһәмиятенә күрсәтеп, Коменский "Дисциплинасыз мәктәп — сусыз тегермән белән бер" дигән чех мәкален китерә. Коменскийның бик зур хезмәте шунда, ул урта гасыр мәктәбендәге таяк дисциплинасына каршы чыга, балаларга кешелекле мөнәсәбәт күрсәтергә чакыра, әмма шул ук вакытта укытучының балалар арасында тиешле дисциплинаны да саклавын таләп итә. Тәртипне күбрәк "яхшы үрнәк, ягымлы сүз, һәрчак ихлас һәм ачыктан-ачык әйбәт мөнәсәбәт белән" сакларга кирәк, ди ул.

Коменский, балаларга тән җәзасы бирүгә кискен каршы чыга. "Чыбык һәм таяк — ирекле кешеләр өчен бөтенләй дә яраксыз коллык кораллары, аларга мәктәптә гомумән урын булмаска тиеш, алар

мәктәптән куылырга тиеш, мин катгый рәвештә шуны таләп итәм". Әмма аның икеләнүе тән җәзасы мәсьәләсендә дә күренә: ул укуда начар өлгергән өчен тән җәзасы куллануны катгый кире кага, ләкин укучы көферлек күрсәткән, яисә киреләнгән очракта рөхсәт итә.

"Яхшы оештырылган мәктәп законнары" дигән кечкенә генә әсәрендә Коменский кыска гына кагыйдәләр рәвешендә мәктәп режимын дөрес оештыру, мәктәпне идарә итү, укытучыларның Вазыйфалары, укучыларның үз-үзләрен тотышына кагылышлы бик күп файдалы күрсәтмәләр бирә.

Кагыйдәләрдә җентекләп укучыларның белемен исәпкә алу тәртибе һәм ысуллары билгеләнгән: кизүчеләр көн саен барлык укучыларның да белемен тикшерә; укытучы һәр дәрестә берничә укучының белемен тикшерә; мәктәпнең ректоры айга бер тапкыр сынау юлы белән өлгерешне тикшерә. Сынаулар шулай ук һәр чирек азагында үткәрелә, ә уку елы беткәч, класстан класска күчерү имтиханнары була.

Укучылар мәктәпкә соңга калмый килергә һәм билгеләнгән урыннарына утырырга тиеш. Ниндидер сәбәп белән укучы дәрескә килә алмаса, әти-әниләре бу хакта кизүчегә хәбәр итәргә тиеш, кизүче исә укытучыга әйтә. Дәресләрдә укучылар укытучы сөйләгәнне игътибар белән тыңларга тиеш. Укучылар мәктәптән тыш та үзләрен тыйнак һәм әдәпле тотарга тиешләр. Коменский болай дип яза: "Тәртипне көлү яисә нәфрәт уятырлык шаяртып яки ачу белән түгел, ә курку һәм ихтирам уятырлык җитдилек белән сакларга кирәк. Шулай булгач, яшьләр белән җитәкчелек иткәндә — җитди сабырлык, шелтәләгәндә — мәсхәрәсез кисәтү, җәза биргәндә — рәхимле таләпчәнлек булырга тиеш".

Укытучының роле һәм аңа таләпләр. Коменский укытучыга бик зур әһәмият биргән, укытучылык эшен бик мактаулы, "җир йөзендәге һәммә профессияләрдән өстен", дип санаган. Бу укытучыга карата яңа, прогрессив караш була, чөнки элегрәк укытучы эшен, аеруча башлангыч мәктәп укытучысының эшен ихтирам итмәгәннәр. Коменский, бер яктан, халыкның укытучыны ихтирам итүен, икенче яктан, укытучының, җәмгыятьтә нинди мөһим функция башкаруын аңлап, үз дәрәҗәсен саклавын таләп иткән. Укытучы, дип язган ул, намуслы, эшлекле, үз дигәнендә нык торучан, игелеклелекнең үрнәге булырга, шул сыйфатларны укучыларына да сеңдерергә, белемле һәм эш сөючән булырга тиеш. Эшен чиксез яратырга, укучыларын

аталарча кайгыртырга, аларда белем алу омтылышы уятырга тиеш. "Укытучы иң әүвәл укучыларын үз үрнәгенә ияртү хәстәрен күрергә тиеш". Укытучының динлелеген Коменский иң мөһим сыйфатларның берсе дип санаган.

Коменскийның педагогик теориясенең аннан соңгы гасырларда педагогиканы һәм мәктәп практикасын үстерүдәге әһәмияте. Ян Амос Коменский бөтен дөньяда педагогик фикер һәм мәктәп үсешенә бик зур йогынты ясаган. Аны мәктәп эшен яхшырту өчен төрле илләргә (Англия, Швеция, Венгриягә һ. б.) чакырганнар. Төрле телләргә тәрҗемә ителгән дәреслекләре бик күп илләрдә, шул исәптән XVIII һәм XIX гасырларда Россиядә дә, киң таралган, алар 150 елдан артыграк башлангыч белем бирүдә иң яхшы уку китапларыннан исәпләнгәннәр һәм башка алдынгы педагоглар өчен дәреслек язу үрнәге булып хезмәт иткәннәр.

Бөек рус педагогы К. Д. Ушинский XIX гасырның 60 нчы елларында болай дип яза: фәнне балалар өчен яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып педагогик бәян итүнең башлангычы итеп "без инде Комениусның "Әйберләр дөньясы рәсемнәрдә"сен саный алабыз".

Коменский дидактика өлкәсендә уку эшен оештыруның бик күп тирән, прогрессив дидактик идея, принцип һәм кагыйдәләрен (уку елы, каникуллар: уку елын чирекләргә бүлү, балаларны мәктәпкә бер генә вакытта — көз көне алу, сыйныф-дәрес системасы, укучыларның белемнәрен исәпкә алу, уку көненең озынлыгы һ. б. ш.) тәкъдим итүче новатор булган. Аның бу мәсьәләләргә караган тәкъдимнәре әле дә булса тулаем алганда төрле илләр мәктәпләрендә кулланыла.

Педагогиканы үстерүдә Коменский, Лейбниц фикеренчә, философияне үстерүдә Декарт һәм Бэкон, астрономияне үстерүдә Коперник кебек үк роль уйнаган. Шуның белән бергә аның педагогика өлкәсендә тәкъдим иткән яңалыклары (гомуми белем бирү, бердәм мәктәп, башлангыч мәктәптә алты ел укыту идеяләре, кайбер башка дидактик принциплар һәм кагыйдәләр) бик әкрен юл ярган. Бөек педагогның алдан күреп әйткән бик күп идеяләре, хыяллары 200-250 елдан соң гына (анда да чикләнгән күләмдә) мәктәп практикасына кертелә.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, прогрессив педагоглар Коменскийның әһәмиятен торган саен ныграк аңлый башлыйлар (аеруча славян илләрендә һәм Россиядә).

Коменскийның педагогик теориясе чех халкының милли азатлык хәрәкәте, шулай ук Европа халыкларының феодализмга каршы көрәше нәтиҗәсендә туа. Фәнни характердагы бу теория дөнья мәдәниятенә зур өлеш булып керә.

**5.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. Какие педагогические идеи Я.А. Коменского наиболее актуальны для современности?
2. В чем характерные особенности педагогики Я.А. Коменского?

**5.2. Задания для практики.**

Дайте общую характеристику особенностей и результатов развития школы и педагогики на Западе в эпоху Нового времени.

Почему Я.А. Коменского считают основоположником научной педагогики?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 5» , добавить вопросы для самоконтроля.

**5.3. Глоссарий по теме 5.**

**Самоопределение** (англ. self-determination) - процесс и результат выбора личностью своей позиции, целей и средств самоосуществления в конкретных обстоятельствах жизни; основной механизм обретения и проявления человеком свободы. До последнего времени тема С. была неактуальна для социокультурной ситуации нашей страны. Вычленялась и обеспечивалась лишь сфера профессионального С. (и то только в области выбора вида профессиональной деятельности). В остальных сферах С. носило формальный и декларативно-демонстративный характер. Актуализация этой темы обусловлена как минимум двумя социокультурными процессами. Во-первых, это нарастание глобальных изменений в обществе, порождающее для каждого человека необходимость выработки собственного отношения к происходящему - т.е. С. становится составной частью процессов, связанных с принятием человеком жизненно важных решений (от поиска новой работы или выбора сферы деловой активности до выбора кандидатов в органы власти). Во-вторых, это разрушение выстроенного в советское время идеологического барьера, который отделял советское «социальное пространство» от всего того, что составляет духовное богатство современного общества (достояний мировой культуры, философии, религии, искусства) - т.е. у человека в плане понимания собственной истории, личных «корней», принадлежности к культурным традициям и многому другому

возникают проблемы С, обусловленные образовавшимся «вакуумом» в том месте, которое ранее занимала идеология. Человек как субъект собственной жизни, характеризуется жизненным С. - более широким, чем профессиональное, нравственное или гражданское. Смысл жизненного С. - включение в систему ценностей, которые поднимают жизненную активность субъекта на принципиально иной уровень - уровень жизненного «пути» уже не столько человека как такового, сколько ценностей, с которыми он себя идентифицировал и занял свою позицию в социокультурном пространстве. Занимая определенную позицию, предвосхищая свое будущее, осознавая свои реальные достижения и недостатки, человек стремится к самосовершенствованию посредством собственной деятельности, общения с другими людьми. Он выступает как субъект собственного развития, определяющий свою жизненную программу. Для него возникает потребность в самосовершенствовании, в построении себя как личности. А расширение границ собственных возможностей есть управление развитием, которое можно описать формулой: «С. + самопреодоление». С. можно понимать как установление внутренних ограничений на собственную деятельность, как расширение границ собственных возможностей, направленных на реализацию замыслов, осуществляемых в рамках принятых ограничений. Саморазвитие обусловлено осознанием несовпадения Я-идеального и Я-реального, борьбой мотивов, преодолением недостатков через организацию деятельности и поведения. Суть процесса С. и состоит в актах выявления и утверждения индивидуальной позиции в проблемных ситуациях, когда человек оказывается перед необходимостью альтернативного выбора и должен принимать экзистенциальные или прагматические решения. Результат С. - выход человека на цели, направления и способы активности, адекватные его индивидуальным особенностям, и на формирование духовной самоценности, способности через целеполагание самобытно и самостоятельно реализовать свое природное и космическое предназначение. Ситуация С, а не просто выбора из альтернатив, С. как движения в основаниях своих действий, дел и деяний может рассматриваться как своеобразная единица творческого процесса развития личности. Концептуальная схема С. описана как движение в четырех смысловых пространствах: ситуативном, социальном, культурном и экзистенциальном. Поиск оснований для решений в проблемной ситуации в зависимости от типа

С. может разворачиваться: как ситуативное поведение, направляемое обстоятельствами (ситуативное пространство); как социальное действие, детерминированное локальной целью (социальное пространство); как рефлексия собственной деятельности и придание ей статуса «дела», вписываемого в некоторую культурную традицию (культурное пространство); как рефлексия бытия и, соответственно, движение в вечных ценностях и вопросах (экзистенциальное пространство). Последовательная рефлексия действий, деятельности, бытия выступает в схеме в качестве способа С, побуждением к которому служат оценивание результатов ситуативного поведения, анализ результатов и последствий самостоятельной деятельности, установление ограничений на собственные замыслы в процессе рефлексии их реализации. Кроме того, рефлексия служит ключом к реализации, средством интенсификации интеллектуальных функций (мышления, понимания, мыслекоммуникации, мыследействия). В сфере образования наряду с процессом передачи знаний происходит и другой процесс - передачи способов С. Образование становится той сферой, в которой создаются прецеденты и образцы С. Концепция С. по-новому ставит вопрос об «объекте» образования. Им не может выступать ни отдельная личность, ни класс (группа, коллектив), а лишь образовательный материал (предметы, явления, символы, модели, ситуации, ценности, деятельность, отношения, психологическая атмосфера), в процессе выбора, исследования и преобразования которого происходит С. и саморазвитие субъекта образования (учителя, ученика, взаимодействующей группы, сообщества и т.д.). С. лежит в основании инновационной педагогики, которая ведет к такому типу образования, к такой работе с обучающим, воспитывающим материалом, которые изменяют и сам материал, и самих субъектов образования, и их взаимодействие, взаимовлияние.

**Саморазвитие** - процесс активного, последовательного, прогрессивного и в целом необратимого качественного изменения психологического статуса личности. Саморазвитие возможно на определенной ступени возрастного развития, когда сформировались механизмы саморегуляции

**Самосовершенствование** - способность человека целенаправленно саморазвиваться, самовоспитываться, самообразовываться, ориентируясь на принятые нравственные нормы и идеал.

Самосовершенствование возможно только на основе развития духовных сил человека, нравственного сознания и через целенаправленную деятельность.

**5.4. Использованные информационные ресурсы.**

do.gendocs.ru/docs/index-12782.html?page=7

## Тема 6. *ДЖОН ЛОККНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ*

**Аннотация.** Данная тема раскрывает педагогические идеи Джона Локка.

**Ключевые слова.** Педагогические идеи, воспитание джентльмена.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### *ДЖОН ЛОККНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ*

Локкның социаль-сәяси һәм фәлсәфи карашлары. XVII гасырда Англия промышленность перевороты өчен җирлек әзерләгән буржуаз революция кичерә. Бу яңа заман, буржуазия хакимлеге заманы җитүен хәбәр итүче революция иде.

Анда буржуазия дворяннарның буржуаллашкан өлеше белән союзда чыгыш ясый, ул революциянең характерлы үзенчәлеге шунда була.

1688 елда сыйнфый компромисс — шушы ике социаль группа арасындагы килешү нәтиҗәсендә король тәхеттән төшерелде дип игълан ителә һәм аның урынына принц Вильгельм Оранский чакырыла. Оранский илнең буржуаз үсешен гарантияләүче "Хокуклар декларациясен" кабул итә. Маркс әйтүенчә, (данлы революция) Вильгельм III Оранский белән берлектә властька җиңел табыш артыннан куучы җирбиләүче һәм капиталистларны куя".

Энгельс сүзләре белән әйткәндә, Джон Локк "1688 елгы сыйнфый компромисс баласы иде". Маркс аны бөтен сыйфатлары белән яңа буржуазия вәкиле буларак характерлый.

Джон Локк 1632 елда провинция адвокаты гаиләсендә туа. Аның әтисе революциядә катнашкан була. Иске Вестминстер мәктәбендә

схоластипик урта белем алганнан соң, Локк Оксфорд университетына укырга керә, анда Декарт, Бэкон, Ньютон кебек зур галимнәрнең хезмәтләре белән мавыга, табигать фәннәре белән кызыксына, медицина белән шөгыльләнә. Университетны тәмамлагач, Локк анда грек теле һәм әдәбияты укытырга кала. Илдә җәелеп киткән революцион көрәшкә сагаеп карый, гади халыктан күтәрелгәннәрне яратмый. 1667 елда Локк либераль сәяси эшлекле Лорд Шефтсбери белән таныша, аларның гаилә табибы һәм оныкларының тәрбиячесе булып китә. Шефтсбери буржуазия ягыннан корольгә каршы чыга. Шуңа күрә аны, аның белән бергә Локкны да җәберли башлыйлар, һәм алар Голландиягә эмиграциягә китәргә мәҗбүр булалар. 1688 елдан соң Локк Англиягә кире кайта һәм шул чор буржуаз җәмгыятендә мактаулы урын били. 1704 елда үлә. Локк үзенең хезмәтләрендә король власте алышынуны һәм Англиянең яңа дәүләт төзелешен дәлилләргә омтыла. Ул дәүләт барлыкка килүнең килешү теориясен һәм "табигый хокук" теориясен яклый, кешеләр башта табигый халәттә яшәгәннәр, азат һәм тигез булганнар дип исбатлый. Алар үзләренең табигый хокукларын үз теләкләре белән хакимнәргә биргәннәр, шуның өчен хакимнәр аларның гомерләрен, ирек һәм мөлкәтләрен сакларга тиеш булганнар. Моннан: югары хакимият иясе халык булган, ул үзе биргән властьны, әгәр монарх үз вазифаларын үтәмәсә, кире дә ала алган, дигән нәтиҗә чыга.

"Кеше акылы турындагы тәҗрибә" дигән төп фәлсәфи хезмәтендә (1690) Локк кеше аңында "тумыштан килгән идеяләр" һәм күзаллаулар юк, бала күңеле "чеп-чиста язу тактасы шикелле" дип расларга тырышкан. Бу положениедән чыгып, кеше үсешендә тәрбиянең роле бик югары бәяләнә. Локкның, белем һәм идеяләр тоеп белү тәҗрибәсеннән килеп чыккан, дигән тәгълиматы буржуазияне феодаль аристократия идеологларының идеяләр, "рыцарьлык сыйфатлары", дәүләтне идарә итү сәләте, аксөякләрнең белем алуга аерым хокуклары тумыштан килә дигән, ул чакта киң таралган раслауларына каршы көрәшкә коралландыра.

Локкның тумыштан килгән идеяләрне тәнкыйтьләве материализмның идеализм белән көрәшендә уңай роль уйный. Шул тәнкыйтькә XVIII гасыр мәгърифәтчеләре таяна.

Күзаллаулар безнең аңыбызга тойгылар, сизү әгъзалары аша килә, ди Локк. Бу — дөньяны танып белүнең төп чарасы. Шул рәвешле, биредә ул материалистик сенсуализм позицияләренә баса. Әмма

Локкның философиясе дуалистик характерда. Аның фикеренчә, тышкы тәҗрибәдән башка, акылның үз эшчәнлеге булган эчке тәҗрибә дә бар. Бу нәрсә аның философиясендә идеалистик элементлар да булуын күрсәтә, моны хакыйкать безнең аңыбызда объектив чынбарлыкның чагылышы түгел, ә күзаллаулар һәм төшенчәләрнең үзара ярашуы, дигән раслаулар да бик ачык ассызыклый. Шушы положениеләрдән чыгып, Локк үз-үзеңне күзәтүгә нигезләнгән эмпирик психологиянең күп кенә мәсьәләләрен эшли. Ул без сайлаганга бәя бирүче, кешегә бәхет һәм файда китерә торган нәрсәне билгеләүче кеше акылының аерым әһәмиятен күрсәтә. Акыл тәрбиясе шуңа күрә аеруча әһәмияткә ия була.

Локкның этикасы тумыштан килгән әхлакый идеяләрне кире кагуга нигезләнә. Игелек — рәхәтлек китерә, яисә аны арттыра, газапны киметә һәм явызлыктан саклап кала алучы нәрсә. Явызлык — газаплар китерә, яисә арттыра, рәхәтлекне киметә яисә рәхәтлектән мәхрүм итә алучы нәрсә. Бу положениеләр феодаль дини этикага каршы юнәлгән була. Шул ук вакытта Локк бар нәрсәне тудыручы һәм иҗат итүче буларак ходайның барлыгын инкарь итми, бала күңеленә алла турында һәм диннең әһәмияте турындагы ныклы төшенчәләрне бик иртә сеңдерергә кирәк дип саный.

Локк үзенең педагогик карашларын "Тәрбия турында уйланулар" (1693) дигән китабында бәян итә.

**Джентльмен тәрбияләү.** Без үз гомеребездә очрата торган кешеләрнең уннан тугызы тәрбия аркасында яхшы яисә яман, файдалы яисә файдасыз була, дигән Локк. Тәрбиянең бурычы итеп ул гади кешене түгел, ә джентльмен, "алдын-артын уйлап, төрле эш итә белүче" джентльмен тәрбияләүне санаган. Ул — чыгышы белән дворян булырга, "нәзакәтьле мөгамәләсе белән аерылып" торырга, шул ук вакытта буржуаз эшкуар, эшлекле кеше сыйфатларына ия булырга тиеш.

Джентльмен физик, әхлакый һәм акыл тәрбиясе алырга тиеш, ләкин мәктәптә түгел, чөнки, Локк фикеренчә, мәктәп — "төрле катлаудан чыккан, начар тәрбия алган малайларның чуар төркеме җыелган учреждение ул". Чын джентльмен өй тәрбиясе ала, чөнки "хәтта өй тәрбиясенең кимчелекләре дә мәктәптә алган белем һәм күнекмәләрдән күпкә файдалырак". Локк, аксөяк гаиләләре практикасыннан чыгып, джентльмен тәрбияләү эшен яхшы әзерлекле, җитди тәрбиячегә тапшырырга киңәш иткән.

Локк физик тәрбиягә гаять зур әһәмият биргән. "Безгә исәнлек (сәламәтлек, эшләребез алга барсын һәм уңышлы булсын өчен кирәк",— дигән ул һәм җентекләп эшләнгән, шул чор фәне югарылыгында торган система тәкъдим иткән. "Сәламәт тәндә — сәламәт акыл",— дип кабатларга яраткан. Шуңа күрә бик кечкенәдән баланың тәнен чыныктыру, бала ару-талуларны, авырлыклар, үзгәрешләрне җиңел кичерерлек итүгә ирешү зарур. Локк бала тормышында катгый режимның әһәмиятен җентекләп нигезләгән, кием-салым, азык, һавага чыгу, спорт белән шөгыльләнү турында киңәшләр биргән.

Дөрес физик тәрбия кыюлык, ныклык кебек сыйфатлар булдыруга да ярдәм итә. "Джентльменга шундый тәрбия бирергә кирәк, ул теләсә кайсы вакытта корал тотып солдат булырга әзер торырга тиеш".

Локкның морале, әйтеп үткәнебезчә, файда һәм шәхес мәнфәгатьләре принцибыннан килеп чыга. Чын джентльмен үз бәхетен үзе таба белә, әмма шул ук вакытта бу мәсьәләдә башка джентльменнарга да комачауламый. Кешеләр "акыллы" булырга һәм теләкләренә ирешергә омтылырга гына түгел, реаль мөмкинлекләрен дә исәпкә алырга тиешләр. Шуңа күрә кеше үзен акыллы тотарга, дәрт-хисләрен йөгәнли белергә, тәртипле булырга, акылга буйсынып эш итәргә тиеш.

Характер һәм әхлак тәрбияләү, ихтыяр көче үстерү — тәрбиянең иң мөһим бурычлары. Баланы узындырырга ярамый, ләкин аның законлы теләкләрен үтәми калдырырга ярамый. Баштарак "курку һәм ихтирам хисләре" тәрбиячегә баланың үз-үзен тотышы белән идарә итү мөмкинлеге бирсә, соңрак бу хисне мәхәббәт һәм дуслык "алыштырырга тиеш".

Ниндидер сүз куерту түгел, ә һәрвакыт үрнәк, мохит, баланың тирә-юне төп тәрбия чарасы булачак. "Нинди генә вәгазьләр укымасыннар, көн саен нинди генә әдәплелек сабаклары бирмәсеннәр, барыбер баланың үз-үзен тотышына иң зур йогынтыны аның компаниясе һәм тирә-юнендәгеләрнең эш-гамәлләре ясаячак, шиксез хакыйкать шушы", — ди Локк. Балаларда ныклы әйбәт гадәтләр тәрбияләү аеруча мөһим.

"Балаларны хәтердән шунда ук чыгып китә торган кагыйдәләр белән тәрбияләргә ярамый. Аларны нәрсәгә булса да өйрәтергә уйласагыз, шуны җае чыккан саен гамәлдә куллану юлы белән ныгытыгыз һәм, мөмкин булса, ул җайны үзегез чыгарыгыз".

Гадәт тәрбияләү бик кечкенәдән башланырга тиеш. Тупаслык, көч белән уңай нәтиҗәгә ирешеп булмый; моңа ягымлы сүз, балалалар оныткан нәрсәне иплэп кенә исләренә төшерү рәвешендә җайлап кына аңлату белән ирешергә кирәк. Берьюлы берничә гадәткә дә өйрәтеп булмый. Башта бер гадәтне ныгытырга, аннары гына икенчесенә күчәргә кирәк,— тәрбиячененң бурычы шуннан гыйбарәт.

Бөтен тәрбия процессын дөрес юнәлтү өчен баланың шәхси үзенчәлекләрен игътибар белән өйрәнергә, "өстенлек итүче дәртләрен һәм хакимлек итүче гадәтләрен" ачыклар өчен, бала үзе сизмәгәндә аны күзәтергә кирәк, чөнки шушы сыйфатлар аермасына туры китереп сезнең методларыгыз да аерымланырга тиеш..."

"Коллар дисциплинасы кол характерын тәрбияли" дип, Локк тән җәзасына каршы булган. Ләкин бала үзсүзләнгән, тыңларга теләмәгән очракларда кулланырга мөмкин дип санаган.

Локк дини тәрбиягә әһәмият биргән, әмма иң мөһиме — балаларны йолаларга өйрәтү түгел, ә иң югары зат буларак аллага мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү дип исәпләгән.

Джентльменнар укыту эчтәлеге, Локк фикеренчә, ул чорда кабул ителгәннән шактый киңрәк. Джентельменны укырга, язарга, рәсем ясарга, туган телгә, француз, латин телләренә (латин теле һәммәсе өчен дә түгел: сәүдә эшләре, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүчеләргә бу тел кирәкми), география, арифметика, геометрия, астрономия, хронология, этикага өйрәтү тиеш, шулай ук аңа тарих һәм закон белеменнән, бухгалтериядән мәгълүматлар, атта йөрү һәм бию дәресләре бирергә кирәк.

Бу программа урта гасыр традицияләреннән кискен аерыла. Локк тәкъдим иткән һәр предмет укучыга билгеле бер файда бирергә, аны тормышка әзерләргә тиеш. Белемнәргә практик характер бирергә кирәк иде.

Локк укучыларына нинди дә булса һөнәр (столяр, токарь, балта остасы), яисә бакчачылык һәм авыл хуҗалыгы шулай ук парфюмерлык, лаклау һәм гравировкалау белән шөгыльләнергә тәкъдим иткән. Хезмәт тәрбиясенең зарурлыгын ул болай аңлаткан: саф һавада эшләү сәламәтлек өчен файдалы, ә һөнәр белүнең эш кешесенә, эшмәкәрлеккә кирәк булуы бар. Хезмәт мәгънәсез тырай тибүгә юл куймый.

Тәрбияче, бала белән шөгыльләнгәндә, анда укуга кызыксыну уятырга, аның белемгә омтылышын үстерергә тиеш. Укуны бала өчен

кызыксыз шөгыльгә әверелдерергә ярамый. Укытучы балаларның яңалыкка омтылышыннан файдаланырга, әмма шул ук вакытта аларны кызыксыз эшләрне дә эшләргә өйрәтергә тиеш. Баланың кызыксынучанлыгыннан киң файдаланырга кирәк, чөнки аннан белем алуга омтылыш туа. Балаларның сорауларына игътибарлы булырга кирәк, ялган яисә икеле-микеле җаваплар бирергә ярамый. Балаларда аңлау һәм мөстәкыйль фикер йөртү сәләте тәрбияләргә кирәк.

Локкның "эшче мәктәпләре" турындагы антидемократик проекты. Югарыда без инде Локкның мәктәпләргә тискәре мөнәсәбәтен билгеләп үткән идек. Ул булачак джентльменны "тупас гавам", кара халык балалары йогынтысыннан сакларга кирәк, дип санаган, Локк фикеренчә, алар зур осталык һәм елгырлык белән бакча басарга гына сәләтле.

Халыкка шушылай ачыктан-ачык нәфрәте Локкның "эшче мәктәпләре" турындагы язмасында аеруча нык чагылыш таба. Аның фикеренчә, "эшче халык балалары" һәрвакыт җәмгыять өстенә авыр йөк булып төшәчәк. Шуңа күрә һәрбер мәхәлләдә "эшче мәктәпләре" оештырырга кирәк, ярдәм сораган, хәерче ата-аналарның 3 яшьтән 14 яшькә кадәрге балаларын мәҗбүри тәртиптә шунда бирергә кирәк. Бу балалар мәктәптә бары "туйганчы ипи генә" ашаячак. Суык вакытта, кирәк дип табылса, ипигә өстәп бераз җылы ботка бирергә мөмкин. Шушы җитәр-җитмәс ризык өчен дә балалар эшләргә, мәсәлән, җеп эрләргә, бәйләм бәйләргә һ. б. тиеш. Балалар эшләгән әйберләрне сатып, акчасын аларга киткән чыгымны каплауга тотарга кирәк. Аеруча шунысы мөһим, ди ул, балаларны мәктәптән укытучы күзәтчелегендә чиркәүгә алып барырга бик уңай булачак, ә бу исә куәтле тәрбия чарасы булыр. Түләү бәрабәренә осталарга читтән өйрәнчекләр алу мөмкинлеге бирелә. Өйрәнчекләр акчаны мәктәпкә түләргә тиеш. Шулай итеп балалар осталарга да, фабрикантларга да эшләячәк.

Локкның тәгълиматлары педагогик системасыннан, бигрәк тә социаль һәм прогрессив юнәлешләре ягыннан, шактый нык аерылса да, Локкның фәлсәфи һәм педагогик хезмәтләре, дәүләтнең килешү нигезендә барлыкка килүе һәм "табигый хокук" теориясе француз мәгърифәтчеләренә сизелерлек йогынты ясый.

**6.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. На каких принципах Дж. Локк предлагал строить взаимоотношения между воспитателем и воспитанником?

2. В чем новаторский смысл такого высказывания Дж. Локк: «Пусть ваш воспитанник делает все, что он хочет, но пусть он хочет того, что желаете вы»?

3. Какими общими чертами со второй половины XIX в. характеризовались системы образования в развитых странах мира (США, Англия, Германия, Япония) и в чем проявляется их специфика в отдельных государствах (например, в Англии)?

**6.2. Задания для практики.**

Охарактеризуйте основные направления модернизации учебно-воспитательного процесса в зарубежной школе, покажите роль экспериментальных школ, новых технических средств массовой информации.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 6», добавить вопросы для самоконтроля.

**6.3. Глоссарий по теме 6**

**Актуализация** — воспроизведение имеющихся у человека знаний, умений, навыков, различных форм поведения и эмоционального состояния, перевод их из потенциального состояния в актуальное действие.

**Антиципация** — представление предмета, явления, результата действия и т.п. в сознании человека еще до того, как они будут реально восприняты или осуществлены.

**Воспитательная система школы** – совокупность взаимосвязанных компонентов (воспитательные цели, люди, их реализующие, их деятельность и общение, отношения, жизненное пространство), составляющая целостную соц.-педагогическую структуру школы и выступающая мощным и постоянно действующим фактором воспитания. Признаки *гуманистически ориентированной* В. с. ш.: наличие единой концепции развития школьной воспитательной системы, формирование здорового образа жизни, сочетание фронтальных, групповых и индивидуальных форм воздействия и взаимодействия, обеспечение защитных функций коллектива, разнообразная и многообразная совместная деятельность разновозрастных коллективов и объединений. Примерами гуманистически ориентированной В. с. ш. могут быть школы В. Караковского, А. Тубельского и др.

**Дедукция** — вывод по правилам логики; цепь умозаключений, звенья которой связаны отношением логического следования.

**Индукция** — логическое рассуждение, двигающееся от утверждений менее общего характера к утверждению более общего характера.

**6.4. Использованные информационные ресурсы**

1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.

## Тема 7. *ЖАН-ЖАК РУССОНЫҢ ПЕДАГОГИК ТӘГЪЛИМАТЫ*

**Аннотация.** В данной теме рассматривается педагогические взгляды Ж.-Ж. Руссо.

**Ключевые слова.** XVIII в., феодальный строй, Французские просвететели.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### *ЖАН-ЖАК РУССОНЫҢ ПЕДАГОГИК ТӘГЪЛИМАТЫ*

**XVIII гасыр уртасында Франциянең иҗтимагый-сәяси хәле. Мәгърифәтчелек фәлсәфәсе.** Франциядә капиталистик строй 1789-1794 еллардагы буржуаз революциягә кадәр бик күп элгәре урнаша. Нигездә аграр илдә XVIII гасырның икенче яртысында капиталистик мануфактура киң тарала. Ләкин феодаль мөнәсәбәтләр капитализм үсешенә нык тоткарлык ясый.

Илнең барлык халкы өч катлауга бүленә. Беренче катлау — гаять күп җирләргә хуҗа булган руханилар. Бу катлау салым түләүдән азат ителә, аның үз суды була. Икенчесе — җирләрнең шактый өлешенә

хуҗа дворяннар катлавы. Феодаль хокуклар бу катлауга крестьяннарны эксплуатацияләүдә киң мөмкинлекләр бирә. Өченче катлауның өстенлекләре булмый, аның күпчелек өлешен бөтенләй хокуксыз крестьяннар тәшкил итә. Феодаль түләүләр һәм авыр дәүләт салымнары нәтиҗәсендә крестьяннарның матди хәле бик авыр була. Өченче катлау бертөрле генә булмый: аңа һөнәрчеләр, эшчеләр, шәһәр ярлылары да керә. Өченче катлауда җитәкче урыннарны сәүдәгәрләр, фабрикант һәм банкирлар тота. Яшәү шартлары төрлечә булуга карамастан, алар барысы да феодаль тәртипләргә оппозициядә торалар. XVIII гасыр уртасында буржуазия, өченче катлау составына кереп, ашыкмыйча, акрынлап-акрынлап кына куәтле халык хәрәкәтенә кушыла һәм аның корольгә, руханилар һәм дворяннарның өстенлекләренә, катлауларга бүленгән тәрбия системасына каршы чыгышларына җитәкчелек итә.

Феодаль стройга каршы юнәлгән халык хәрәкәте XVIII гасырның бөтен сәяси тормышына зур йогынты ясый. Бу чорда буржуаз идеологияне чагылдыручы язучы һәм галимнәрнең феодаль тәртипләргә каршы көрәше җанлана. Әсәрләрендә алар революциягә кадәр бик күп элек дөньяга феодаль карашларны тәнкыйтьлиләр, рәсми диннәрне тар-мар итәләр (мәгърифәтчеләрнең кайберләре атеистлар була). XVIII гасырның 50-80 нче елларында, ягъни революция алдыннан, аларның чыгышлары аеруча үткен төс ала.

Француз мәгърифәтчеләре феодализмның аянычы буларак динне, феодаль стройны һәм феодаль идеологияне тәнкыйтьлиләр. Локк позицияләреннән чыгып, алар дәүләтнең килешү нигезендә килеп чыгуы теориясен яклыйлар (Руссо, Дидро һ. б.) һәм "кешенең" табигый халәтендә" һәрвакыт иреккә, тигезлек һәм туганлыкка "табигый хокукы" бар", дип исбатлыйлар.

XVIII гасыр мәгърифәтчеләре яңа эра, Җирдә акыл хакимлеге эрасы, җитүен көтәләр.

Бу чорда буржуазия идеологлары чын күңелдән үзләрен өченче катлау вәкилләре генә түгел дип саныйлар. Алар нинди дә булса аерым сыйныф вәкилләре ролендә түгел, ә газап чигүче бөтен кешелек ролендә чыгалар.

Ләкин властьны кулына алгач, үз хакимлеген урнаштырырга омтылыш, буржуазия хезмәт иясләренә каршы, үсеп килүче эшчеләр сыйныфына каршы һөҗүмгә күчә.

Француз мәгърифәтчеләре тәрбиянең куәтле көченә ышаналар. Яңа кеше тәрбияләп, шуның белән бөтен дөньяны яңарта-чакларына алар шикләнми. Алар фикеренчә, мәгърифәт үткәннән калган ялганны, хорафатлар, наданлыкны бетерәчәк, феодализмга хас барлык тискәре күренешләр юкка чыгачак.

Француз мәгърифәтчеләре арасында күренекле урынны Жан-Жак Руссо һәм фәлсәфәче-материалистлар тоткан.

**Жан-Жак Руссоның тормышы.** Руссо 1712 елда Женевада, һөнәрче-сәгатьче гаиләсендә туа. Системалы белем алмый. Күп еллар Франция һәм Швейцариядә ил гизә, бик күп һөнәрләргә тотынып карый. Формалашып җиткәч, утыз яшендә, Руссо Парижга килә һәм анда шул чорның яңа буржуаз интеллигенциясе, аның иң яхшы вәкилләре — публицистлар һәм философлар белән таныша. 1749 елда Дижон академиясе "Фән һәм сәнгать прогрессы әхлак яхшыруга яисә начараюга ярдәм иттеме?" дигән темага сочинение конкурсы игълан итә. Дидро киңәше белән Руссо шушы темага язарга алына. Бу әсәрендә ул социаль тигезсезлеккә, аксөякләр һәм эшлексезләргә, феодаль җәмгыять мәдәниятенә һәм фәненә кискен каршы чыга. Шул хезмәте өчен Руссо Дижон академиясе бүләген ала.

1755 елда Руссо "Кешеләр арасында тигезсезлекнең килеп чыгуы һәм нигезләре турында фикер йөртү" исемле икенче хезмәтен иҗат итә. Анда диалектика элементлары да була. Аннары "Иҗтимагый договор" пәйда була. Руссо тигезсезлекнең цивилизация белән бергә үсүен исбатлый. "Иҗтимагый договор" хезмәтендә, Локкның договор теориясен үстереп, ул цивилизацияле (ягъни феодаль) җәмгыятькә каршы идеал итеп, имештер, "табигый халәтендәге", ниндидер җәмгыятьне куя. Анда кешеләр азат һәм тигез булганнар, аннары эшләп тапкан мөлкәтләрен саклап калу өчен хокукларыннан баш тартканнар. Руссо туганлыкны, эксплуататорлар изүен тәнкыйтьләгән һәм, халык мәнфәгатьләренә җавап бирмәгән власть законсыз, башлангыч иҗтимагый килешүне боза; ул килешү буенча кешеләр үзләре сайлаган, халыкка хезмәт итәргә бурычлы властьларга ирекле рәвештә кайбер хокукларын биргәннәр, дип исбатлаган. Әдәби формага төрелгән бу әсәр корольне һәм феодаль тәртипләрне бәреп төшерергә чакыру була.

1762 елда Руссоның "Эмиль, яки Тәрбия турында" дигән роман-трактаты чыга, ул авторны бөтен дөньяга таныта. Бу әсәрендә Руссо яңа, ягъни буржуаз җәмгыятьнең ирекле кешесен тәрбияләү юлын

күрсәтә. "Эмиль" чыгу аксөякләр һәм руханиларның ярсуын кузгата. Гәрчә Руссо атеист булмаса да, хөр фикерлелеге өчен, китап Парижның бер мәйданында яндырыла, ә авторы чит илгә качарга мәҗбүр була. Бары үләр алдыннан гына, физик һәм мораль яктан арыган, талчыккан Руссо туган иленә кайту мөмкинлеге ала. Ул 1778 елда үлә.

Руссо әсәрләре революция алды буржуаз җәмгыятенең алдынгы вәкилләрен тирән дулкынландыра, бу әсәрләрнең йогынтысы Франциядән бик еракларга тарала.

Руссоның иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи карашлары. Хакимият һәм байлык тигезсезлек тудырды, ди Руссо, шуңа күрә кеше үзенең ирекен югалты. "Кеше туганда ирекле туса да, бөтен җирдә ул богаулы", — дип яза ул. Руссо хакимлекне халыкның үз кулында булырга тиеш дип саный, һәркем эшләргә тиеш дип таләп итә. Ул, вак милекне генә калдырып, дворян-феодаллар милкен юк итәргә чакыра. Руссоның бу тәгълиматы шул чор өчен революцион була. Ул вак милекчеләр (һөнәрчеләр, крестьяннар) мәнфәгатен чагылдыра һәм буржуаз строй урнашуга китерә. Руссоның идеалы — эшләп тапкан вак буржуаз милек һәм шушы милеккә, шулай ук һәркемнең хезмәтенә нигезләнгән җәмгыять төзелеше.

Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү мәсьәләсен караганда, Руссо сенсуалист буларак фикер йөртә: безнең аңыбызда сиземләү ярдәмендә, тою органнары аша алынмаган бер генә нәрсә дә юк. Ләкин ул бу положениедән материалистик нәтиҗәләр ясый алмаган. Руссо, рәсми динне кире кагып, "хисси динне" яклаган, һәрбер кеше үзенчә инанырга тиеш дип исәпләгән. Аныңча, "галәмне яратучы алла кулыннан чыккан һәммә нәрсә яхшы, һәммә нәрсә кеше кулында начарлана".

Руссо фикеренчә, кешене җәмгыять боза. Моннан шундый нәтиҗә чыга: баланы бозык җәмгыятьтән читтә, цивилизацияләрдән еракта, "табигать кочагында" тәрбияләргә кирәк.

Кешеләр үз хезмәтләре исәбенә яшәргә тиеш. Хезмәттән башка кеше нормаль яши алмый. Ләкин гаделсез, бозык дөньяда күпләр чит кешеләрнең хезмәт җимешләрен үзләштерә. Чын-чын-нан ирекле кеше — үз хезмәте белән яшәүче ул. Руссо фикеренчә, эш бирәүгә дә бәйле булмаган, үз ирекен бәяли һәм яклый белгән кеше тәрбияләүдә тора. Үз ирекенең кадерен белгән кеше, әлбәттә, хезмәткә нигезләнгән башкалар ирекен дә ихтирам итәргә өйрәнә.

Руссо: хезмәт ияләренең балаларын тәрбияләргә кирәкми, аларны тормыш тәрбияләгән инде, дигән. Феодалларны, аксөякләрне яңадан тәрбияләргә, аларның балаларына дөрес тәрбия бирергә кирәк, шул чагында дөнья үзгәрер. Шуңа да ул "Эмиль, яки Тәрбия турында" әсәрендә аксөякләр гаиләсеннән чыккан Эмильне төп герой итә. Тәрбия нәтиҗәсендә ул хөр фикерле булырга һәм үз кул көче белән яшәргә тиеш.

Табигый һәм ирекле тәрбия. Балалар, Руссо фикеренчә, табигатенә туры килә торган табигый тәрбия алырга тиеш. Бу — тәрбияләгәндә баланың табигатенә иярергә, аның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк дигән сүз. "Табигать балаларның үсеп җиткәнче бала булуларын тели",— дип яза Руссо. Ул тәрбияне өч чыганактан: табигатьтән, тирә-юньдәге кешеләрдән һәм әйберләрдән алалар дип исәпли. Табигать белән тәрбияләү, аның фикеренчә, кеше сәләтләренең "эчке" үсеше, сизү әгъзалары үсеше юлы белән тормышка ашырыла; кешеләр тәрбиясе — кешене шушы сәләтләр һәм әгъзалар үсешен файдаланырга өйрәтү; һәм, ниһаять, әйберләр тәрбиясе — кешенең үзенә очрый һәм аңа йогынты ясый торган әйберләрдән ала торган шәхси тәҗрибәсе. Дөрес тәрбия барлык өч фактор да (табигать, кешеләр, әйберләр яисә тышкы хәлләр белән тәрбияләү) үзара килешеп, бер юнәлештә эш иткәндә була.

Табигый тәрбия белән турыдан-туры бәйләнешкә Руссо ирекле тәрбияне дә куя. Кешенең табигый хокукларыннан беренчесе, ди ул,— ирек. Шушы положениегә таянып, ул ятлаулы, каты дисциплиналы, тән җәзалы һәм баланың шәхесен бастырып торучы схоластик мәктәпкә каршы чыга. Ул бала шәхесен ихтирам итүне, аның мәнфәгатьләре һәм ихтыяҗлары белән исәпләшүне таләп итә. Аның ирекле тәрбиягә чакыруының уңай ягы нәкъ менә шунда.

Руссо тәрбиячենең юнәлеш бирү ролен зур әһәмияткә ия дип санаган, ләкин бу рольне үзенчә аңлаган. Тәрбияче, дигән ул, укучысын мәсьәләне хәл итүгә юнәлтә генә, баланың мәнфәгатьләре белән аның үзенә сиздермичә идарә итә, башлыча читләтеп йогынты ясый. Бөтен мохитне, баланың тирәлеген шундый итеп оештыра, нинди дә булса карарга, нәтиҗәгә килергә ул мохит үзе ярдәм итә. Руссо тәрбия чарасы буларак мәҗбүр итүне кире кага.

Яшь чорларына бүлү. Укучысының тормышын Руссо дүрт чорга бүлә. Беренче чор — туганнан алып 2 яшькә кадәр, бу чорда баланың физик тәрбиясе игътибар үзәгендә торырга тиеш. Икенче чор — 2

яшьтән 12 яшькә кадәр, Руссо сүзләре белән әйткәндә, "акылның йоклаган чагы", бу чорда бала әле хөкем йөртә һәм логик фикерли алмый, монда башлыча "тышкы тойгыларны" үстерергә кирәк була, киләчәктә, өлкәнрәк яшьтә кулланыш табар өчен баланың көче туплана. Өченче чор — 12 яшьтән 15 яшькә кадәр, бу елларда акыл тәрбиясе киң җәелдерелә, баланың акыл ихтыяҗлары канәгатьләндерелә. Дүртенче чор — "давыллар һәм дәртләр чоры" — 15 яшьтән алып балигъ булганчыга кадәр. Бу чорда күбрәк әхлак тәрбиясе бирелә.

Баланың яшь үзенчәлекләре турындагы фикерләре Руссоның табигать тәрбиясенә карашлары белән туры килә һәм диалектикадан да мәхрүм түгел. Ул баланың табигый үсеш баскычларының һәрберсе өчен әйдәп баручы башлангыч табарга омтылган, тәрбия процессында төп игътибар шул чорда шул башлангычка юнәлтелергә тиеш. Шуның белән бергә һәр баскыч икенчесе белән тыгыз бәйләнештә була.

Руссо кешенең табигатен тирәнтен аңларга һәм аның үсеш үзенчәлеген ачыкларга омтылган. Әмма ул бала үсеше законнарын дөрес күрсәтә алмаган. 2 яшьтән 12 яшькә кадәр бала логик фикерләүгә сәләтсез, бу яшьтә балалар әхлак төшенчәләрен аңламыйлар дигән раслаулар дөрес түгел.

Руссо үсешне тәрбиядән анык аермаган, шуның белән ул тәрбия процессын биологияләштергән дип әйтергә була. Ләкин шунысы әһәмиятле, ул балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуны таләп иткән. Руссо, һәр бала тормышка аерым темперамент алып килә, шул темперамент аның сәләтен һәм холкын билгели, аны үзгәртергә яисә үстерергә һәм камилләштерергә кирәк була, дип язуы белән дә хаклы. Ул трафаретка, тәрбиягә бертөрле генә якын килүгә кискен каршы чыккан. Тәрбиячененң бурычы — баланың яшь үзенчәлекләрен яхшы белү, индивидуаль һәвәслекләрен һәм сәләтләрен тирәнтен өйрәнү.

Бик кечкенә яшьтә (ике яшькә кадәр) бөтен нәрсәнең нигезе — физик тәрбия. Мөмкин булса, баланы анасы үзе имезергә тиеш. Гадәттә баланы башын селкетмәслек итеп, аякларын турайтып, кулларын гәүдәсе буйлап сузып төреп яткыралар.

"Ярый әле сулыш алу мөмкинлеге калдырсалар!" — ди Руссо. Шул рәвешле тугач ук баланы ирегеннән мәхрүм итәләр, ә моны эшләргә, табигатькә комачауларга ярамый.

Руссо Эмильнең физик тәрбиясенә җентекләп туктала. Баланы чыныктыру, аның физик көчен ныгыту юлларын күрсәтә.

Ике яшьтән яңа тәрбия чоры башлана. Баланы бу яшьтә фикер йөртергә, хикәя һәм әкиятләр өйрәнергә мәҗбүр итү ярамый, аңа төрле үгет-нәсихәтләр уку да кирәкмәс. Бу яшьтә, Руссо фикеренчә, иң мөһиме — баланың тышкы хисләрен үстерү. Руссо бу өлкәдә бик күп күрсәтмәләр бирә. Элеккечә үк баланың сәламәтлеген ныгыту, аны физик яктан үстерү белән ныклап шөгыльләнергә кирәк. Әлегә аны укытырга ярамый. Кирәк дип тапкан очракларда бала үзе үлчәсен, санасын, чагыштырсын. 12 яшькә кадәр китапны бар дип тә белмәсә, бигрәк тә яхшы; ә инде укырга өйрәнгән икән, беренче һәм бердәнбер китабы "Робинзон Крузо" булсын, чөнки аның герое кеше яшәми торган утрауда үзенең табигать эчендәге гади генә көнкүреше өчен кирәкле бөтен нәрсәне үзе булдырган.

Руссо фикеренчә, балада бу яшьтә әхлак төшенчәләре булмый, әмма шунысы бәхәссез, бу чорда үрнәкнең тәрбияви роле бик зур. 12 яшькә кадәр бала бернинди әхлакый, абстракт төшенчәләрне дә аңламый, шулай да әйберләрнең үзләрен танып белүгә бәйле нәрсәләрнең кайбер аерым абстракт төшенчәләр формалаштырырга ярдәм итүе мөмкин. Руссо: бала бу яшьтә бер мөһим идеяне — милек идеясен тулысынча үзләштерә ала дип саный. Эмильнең бакчада эшлисе килә, ул борчак утырта. Әмма аның борчагы бакчачы Робертның кавын төрткән җиренә туры килә. Роберт белән бәрелешеп алганнан соң, бала милек идеясенең табигый рәвештә "хезмәт итү юлы белән беренче булып кулга төшерү" хокукына барып тоташуын аңлый. Шул рәвешле Руссо, үзенең бу яшьтә балада абстракт төшенчәләр формалаштыру мөмкин түгел дигән төп положениеләренә каршы килеп, милек идеясе бала аңына барып җитәрлек була ала, дип саный.

Җәза бирүләрне кире кагып, Руссо "табигый нәтиҗәләр" алымын күтәреп чыга. Баланың ирегён фәкать әйберләр генә чикли ала. Бала, табигать белән очрашкач, һичшиксез, аның законнарына буйсыну кирәклеген аңлаячак. Кешеләргә мөнәсәбәтнең нигезендә дә шушы ук фикерләр салынырга тиеш. Бала тоткан бер әйберсен вата икән,— ачуланмагыз, ватылырдай бөтен нәрсәне аннан ераграк кына куярга тырышыгыз. Үзе утырган урындыкны ваткан икән,— яңасын бирергә ашыкмагыз. Урындыксыз кыен икәнен аңласын. Үз бүлмәсендәге тәрәзә пыяласын вата икән,— яңа пыяла куймагыз, "акылсыз баладан томаулы бала яхшырак". Ә инде пыяла ватуын дәвам итә икән, караңгы бүлмәгә бикләргә кирәк: Руссо моны җәза дип түгел, бала гаебенең "табигый нәтиҗәсе" дип санаган.

Унике яшьлек Эмиль физик яктан нык, мөстәкыйль, тиз ориентлаша һәм иң мөһим нәрсәләрне тотып ала белә, ул үзенең тышкы сизү органнары аша әйләнә-тирә дөньяны танып белгән. Үсешенең өченче, акыл һәм хезмәт тәрбиясе тормышка ашырыла торган чорына аяк басарга ул инде әзер. Бу яшьтә балада, Руссо фикеренчә, җитәрлек дәрәҗәдә әхлак төшенчәләре булмый әле, һәм ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тиешенчә аңлый алмый, шуңа күрә үзен чолгап алган табигать белән бәйле нәрсәләрне өйрәнергә тиеш. Өйрәнү өчен предметлар сайлаганда баланың кызыксынуыннан чыгып эш итәргә кирәк. Баланың үзе күргән әйбер белән кызыксынуы табигый хәл, шуңа күрә аны география, астрономия, табигать белеме кызыксындыра. Руссо балага бу белемнәрне бирүнең күренешләрне ул үзе мөстәкыйль тикшерүгә нигезләнгән оригиналь методикасын тудыра. Ул Эмильне фәнни хакыйкатьләр ачучы, компас уйлап табучы тикшеренүче хәленә куя.

Руссоның дидактикасы балада үзенчәлелек, күзәтә белү, зирәклек үстерүгә нигезләнгән. Бөтен нәрсә балага иң югары күрсәтмәлелек белән тәкъдим ителергә тиеш. Аның фикеренчә, күрсәтмәлелек — Эмиль турыдан-туры үзе таныша торган табигать, тормыш фактлары ул. Яңа, ирекле кешенең акыл тәрбиясен сурәтләргә тырышып, Руссо баланың шәхси тәҗрибәсен фәндә чагылыш тапкан кешелек тәҗрибәсе белән бәйли алмаган. Ул реаль белемне китаплардан түгел, ә табигатьтән алуны яклый. Шуның белән бергә ул балада күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык һәм активлык тәрбияләүнең зур әһәмияткә ия булуын, аның табигать һәм тормыш белән турыдан-туры аралашуының укытуда мөһимлеген бик ачык күрсәткән.

Физик хезмәт — җәмгыятьтә кешенең котылгысыз бурычы. "Баймы ул — ярлымы, көчлеме — көчсезме, эшсез трай тибеп йөрүче һәрбер гражданин — мошенник". Шуңа күрә ирекле кеше төрле һөнәрләр һәм авыл хуҗалыгы эшләрен белергә тиеш, шул чагында гына ул чынлап та үзен туендыра һәм иреген саклый ала. Эмиль бик күп файдалы һөнәрләр өйрәнә.

Беренче чиратта бала столярлык һөнәренә өйрәнә (бу һөнәрнең тәрбияви әһәмиятен Руссо бик югары бәяли), аннары башка күп кенә һөнәрләр белән таныша. Эмиль һөнәрчеләрчә көн күрә, хезмәт кешесен, хезмәтнең үзен, хезмәттәшлекне ихтирам итә башлый. Ул үзе эшләп тапкан икмәкне ашап яши. Хезмәт — ирекле кешенең иҗтимагый бурычы, шулай ук тәрбия чарасы да.

Хәзер инде Эмильнең тормышка әзерлеге бар, һәм Руссо аны уналтынчы яшенә чыккач җәмгыятькә кайтара. Дүртенче чор — әхлак тәрбиясе чоры килеп җитә, ә әхлак тәрбиясен җәмгыятьтә генә биреп була. Хәзер инде бозык шәһәр җитәрлек чыныгу алган Эмильне куркытмый.

Руссо, тиздән революцион көрәшкә керешәчәк сыйныф вәкиле, "өченче катлауның" иң яхшы кешеләре — гомумкешелек идеалларын чагылдыручылар дип ихлас күңелдән ышана. Шуңа күрә Эмильне бөтен кешеләрне дә яратырга өйрәтү зарур, һәм Руссо әхлак тәрбиясенең өч бурычын күтәреп чыга: яхшы хисләр, яхшы фикер, яхшы теләк тәрбияләү.

Яшүсмер кешеләрнең газапларын, мохтаҗлык һәм хәсрәтләрен күрсен, ул шулай ук әйбәт мисаллар да күрәчәк; анда яхшы хисләрне әхлак турында фикер йөртүләр түгел, ә реаль эшләр тәрбияләячәк. Яхшы фикер тәрбияләү бөек кешеләрнең биографиясен, тарихны өйрәнү юлы белән тормышка ашырыла. Яхшы теләк исә яхшы эшләр башкарганда гына тәрбияләнә ала.

Бу яшьтә Руссо җенси тәрбия бирүне дә кирәк дип санаган. Иң элек ул тиешсез китаплар уку, аз хәрәкәтләнү кебек зарарлы гадәтләрне бетерергә тәкъдим иткән; яшүсмер эшлекле тормыш белән яшәргә; хәрәкәтләнергә, физик хезмәт белән шөгыльләнергә, күбрәк саф һавада булырга тиеш. Руссо фикеренчә, балаларның җенси тормыш турында сораулар бирмәве хәерлерәк, ә инде биргәннәр икән, "ялган җавап бирүдән аларны дәшмәскә мәҗбүр итү әйбәтрәк". Бала моңа гаҗәпләнмәячәк, ди ул, чөнки ул аңлый алмастай сорауларга тәрбияче элек тә җавап бирмәгән бит. Эмильне җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле дип тапса, тәрбияче, каушамыйча, җитди һәм гади җаваплар бирергә, баланың җенси тормыш турында читтән, яраксыз чыганаклардан мәгълүмат алуына юл куймаска тиеш.

Руссо фикеренчә, 17-18 яшькә кадәр балага дин турында сөйләү кирәкмәс. Ул Эмильнең әкренләп илаһи башлангычны танып белүгә үзе килүенә ышана. Балаларга дини хакыйкатьләрне җиткерүгә каршы була. Чын дин, - ди ул, — йөрәк дине. Галәмнең акыллы төзелеше турында фикер йөртеп, бала аның иҗатчысы турында фикергә киләчәк, дип саный Руссо.

Эмильнең кәләше Софи капма-каршы тәрбия алган булырга тиеш. Руссо аңлавынча, хатын-кызның бурычы ир-атныкыннан тамырдан аерыла. Башкалар фикеренә җайлашу, мөстәкыйль фикере, хәтта үз

дине дә булмау, башкалар ихтыярына буйсыну — хатын-кызның язмышы шул. Хатын-кызның "табигый халәте" — бәйлелек, "кызлар үзләрен буйсыну өчен яратылган дип хис итәләр", кызлар акыл хезмәте белән шөгыльләнергә тиеш түгел, дип саный Руссо. Аның ирләр һәм хатын-кызлар тәрбияләү эчтәлеген кискен каршы куюы аңлашыла, — ул гаилә идеалын һөнәрче, вак буржуа гаиләсендә күрә. Руссоның болай фикер йөртүе аның вак буржуа табигатенә туры килә һәм реакцион булып тора.

Руссоның педагогик теориясенең әһәмияте. Руссо 1789 елгы француз революциясен идеологик яктан әзерләүдә философ-мәгърифәтчеләр арасында мөһим урын били. Күп кенә каршылыклары һәм ялгышуларына карамастан, аның педагогик карашлары үзенең тарихи прогрессив ролен уйный. Аның карашлары феодаль педагогикасының капма-каршысы була һәм баланы яратуга нигезләнә. Руссо укытуның актив методларын, баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алуны, хезмәт тәрбиясен, укытуның тормыш белән тыгыз элемтәдә булуын таләп итә.

1789-1794 елгы француз буржуаз революциясе тәмамланганнан соң, буржуаз педагоглар Руссоның педагогик идеяләренә сагаеп карый башлыйлар. Демократ Руссо куркыныч тоела башлый, аның актив, мөстәкыйль фикер йөртә белүче, ирекле кеше тәрбияләү турындагы уйлары ныгый алган буржуаз җәмгыятьнең реакцион идеологиясенә каршы килә.

Н. Н. Крупская болай дигән: "Хәзерге заманның картаеп какшаган буржуазиясе Руссо мирасыннан баш тарта. Аның әле үз сыйныфлары мәнфәгатен халык эшеннән аермаган нигез салучылары Руссоны күкләргә чөяләр иде; хәзерге буржуазия, гәрчә традиция буенча аны "бөек" дип атаса да, һәрвакыт "утопист" дип тә өстәп куя, Руссога кимсетеп, салкын карый. Өстәвенә, әсәрләрендәге чыннан да утопик нәрсәләрне генә түгел, аның демократизмын, аның "кешегә", хезмәткә ихтирамын да утопия дип аңлый".

**7.1. Вопросы для самоконтроля.**

1. Система образования и воспитания, изложенная в романе Ж.-Ж. Руссо «Эмиль, или о воспитании».

**7.2. Задания для практики.**

Школа и педагогическая мысль в России в конце XVIII – начале XIX вв.

Концепция единой трудовой школы.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 7» , добавить вопросы для самоконтроля.

**7.3. Глоссарий по теме 7.**

**Гармоничное развитие** — одна из центральных идей в гуманистическом учении о целостном человеке; подчеркивает необходимость взаимного соответствия и согласованности в формировании и развитии различных человеческих качеств, такого их сочетания, которое обеспечивает органичное единство разума, воли и чувств.

**Гуманизация образования** — ориентация процесса обучения на развитие и саморазвитие личности, на приоритеты общечеловеческих ценностей, на оптимизацию взаимодействия личности и социума. Г. о. направлена на создание таких форм содержания и методов обучения и воспитания, которые обеспечивают эффективное раскрытие индивидуальности учащегося — его познавательных интересов, личностных качеств; на создание таких условий, при которых он захочет учиться, будет лично заинтересован в том, чтобы воспринимать, а не отталкивать воспитывающие воздействия. Понятие «гуманизация образования» нельзя отождествлять с его гуманитаризацией.

**Движущие силы процесса воспитания** – объективные противоречия между обновляющимися потребностями воспитанника и возможностями их удовлетворения, регулируемыми педагогом. Разрешение этих противоречий через активность самого школьника способствует его развитию.

**7.4. Использованные информационные ресурсы**


1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.

**Тема 8.** ***XVIII ГАСЫР ФРАНЦУЗ МАТЕРИАЛИСТЛАРЫНЫҢ (ГЕЛЬВЕЦИЙ, ДИДРО) ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ***

**Аннотация.** Данная тема раскрывает педагогические взгляды французских материалистов.

**Ключевые слова.** Материя, идеи, религия.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

## *XVIII ГАСЫР ФРАНЦУЗ МАТЕРИАЛИСТЛАРЫНЫҢ (ГЕЛЬВЕЦИЙ, ДИДРО) ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ*

**Француз материалистларының фәлсәфи карашларына кыскача характеристика.** Француз философ-мәгърифәтчеләре арасыннан карашларының эзлеклелеге һәм сугышчан принципиаль позицияләре белән философ-материалистлар аерылып торган. Алар феодаль дәүләт учреждениеләренә һәм чиркәүгә кискен каршы чыкканнар, француз революциясенең үткен идеологик коралын әзерләгәннәр. Дидро, Гельвеций, Гольбах әсәрләре тыелган, конфискацияләнгән, властьлар тарафыннан ут төртеп яндырылган, авторлар үзләре эзәрлекләнгән, еш кына башка илләргә китәргә мәҗбүр булганнар.

Француз материалистлары дин белән эзлекле, актив көрәшүчеләр булганнар, ал арның дөньяга атеистик карашларының замандашларына гына түгел, киләчәк буыннарга да йогынтысы гаять зур булган. Чиркәү һәм дин — феодализмның төп терәге, ә бу терәкне җимерү — революциянең зарур шарты була. Бу чорда динне тәнкыйтьләү һәрбер башка тәнкыйтьнең алшарты иде.

Философ-материалистлар диннең чыганагы наданлык, коллык, деспотлык һәм руханиларның халык массаларын алдаулары дип исбатларга тырышканнар. Руханиларның халыкны мәгърифәтле итүдә гамьнәре юк, диләр алар, халык никадәр мәгърифәтсез булса, аны алдавы да шулкадәр җиңелрәк. Әмма алар диннең социаль асылын аңламаганнар, аның белән көрәшүнең дөрес юлларын күрсәтә

алмаганнар. Француз материалистлары мәгърифәт барлык хорафатларны юкка чыгарыр дип санаганнар. Фән, сәнгать, һөнәрләр кешеләргә яңа көч бирә, табигать законнарын танып белүгә ярдәм итә, ул белемнәр аларны диннән баш тартуга китерергә тиеш.

Феодаль хөкүмәткә дин халык белән җиңелрәк идарә итү өчен кирәк, ләкин гадел, мәгърифәтле, игелекле хөкүмәткә ялган сафсаталар кирәк булмаячак. Шуңа күрә руханиларның мәктәпләр белән идарә итүенә юл куярга ярамый, мәктәптә дин сабагы да укытылырга тиеш түгел, укучыларны табигать законнарын танып белүгә китерүче предметлар кертергә кирәк. Яңа җәмгыятьтә үзеңне тотуның әхлак нормалары нигезләренә өйрәтүче предмет кертүдә максатка ярашлы, мораль курсы шундый предмет булырга тиеш.

Француз материалистлары тәгълиматы буенча, дөньяда бары бертуктаусыз хәрәкәттәге материя генә бар, материя — физик чынбарлык. Алар табигатьтәге һәм хәрәкәттәге гомуми үзара тәэсир итешүне материянең табигый үзлеге дип таныйлар. Ләкин француз материализмы хәрәкәтне механик аңлау чикләреннән чыкмый һәм метафизик, читтән торып күзәтү характерында була.

Локк сенсуализмына таянып, француз материалистлары танып белүнең башлангыч ноктасы итеп тышкы дөньядан алына торган хис-тойгыларны саныйлар. Дидро сүзләре белән әйткәндә, кеше музыкаль инструментка тиң, ә аның сизү органнары — клавишалар: табигать шул клавишаларга басса, инструмент тавыш чыгара — кешедә сиземләү һәм төшенчәләр барлыкка килә.

Табигатькә карашларында материалист буларак, француз философлары иҗтимагый үсеш законнарын аңлатуда идеализм позицияләрендә торалар. Алар, "дөнья белән фикерләр идарә итә", шулай булгач, фикерләрне үзгәртүгә ирешү белән бөтен феодаль калдыклар һәм диннәр юкка чыгачак, мәгърифәт таралачак, закон чыгару яхшырачак һәм акыл хакимлек итә башлаячак, дип раслыйлар. Димәк, кешеләрне инандырырга, яңадан тәрбияләргә кирәк, шул чагында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең характеры тамырдан үзгәрәчәк. Шуңа күрә француз материалистлары тәрбияне иҗтимагый стройны үзгәртү чарасы дип санаганнар. Алар, кешене әйләнә-тирә мохит һәм тәрбиянең пассив продукты итеп карый, мохит йогынтысына да артык зур бәя биргәннәр. Кешеләрнең мөхитне дә, шулай ук үз табигатьләрен дә үзгәртүче революцион эшчә илегенең ролен аңламаганнар. Иске материализмның өзлексезлеге аның идеаль этәргеч көч барлыгын

тануында түгел, дигән Ф. Энгельс, ә ераграк үтеп кирәргә, бу көчне булдырган сәбәпләргә барып җитәргә омтылыш ясамыйча (тырышмыйча), шуларда тукталып калуында.

**Француз материалистлары Гельвеций һәм Дидроның педагогик карашлары аеруча зур әһәмияткә ия була.**

**Клод Адриан Гельвецийның (1715-1771) педагогик карашлары.** 1758 елда Гельвецийның "Акыл турында" дигән атаклы китабы басылып чыга. Дингә һәм гамәлдәге стройга каршы килүдә гаепләп, властьлар бу китапны тыялар. Китап бөтен халык алдында яндырыла. Гельвеций чит илгә китә һәм **"Кеше, аның акыл сәләтләре һәм аны тәрбияләү турында"** дигән яңа әсәр яза (әсәр 1773 елда басылып чыга).

Гельвеций идеяләрнең тумыштан килүен танымый һәм, сенсуалист буларак, кешенең бөтен күзаллау һәм төшенчәләре тоеп сиземләү нигезендә барлыкка килә дип уйлый. Ул кешенең мохит һәм илдә хакимлек итүче иҗтимагый-сәяси строй йогынтысында формалашуына зур әһәмият бирә. Гельвеций сүзләре белән әйткәндә, **яшүсмернең яңа һәм төп тәрбиячеләре — ул яшәгән дәүләтне идарә итү формасы һәм халыкта шушы идарә итү формасы тудырган гореф-гадәтләр**.

Феодаль строй кешеләрне гарипләндерә, дигән ул. Чиркәү кешеләрнең холкын боза, дини әхлак икейөзле һәм шәфкатьсез. "Гражданнарын тәрбияләүне попларга ышанып тапшырган милләтләр бәхетсез", — ди Гельвеций. Аныңча, әхлак вәгазен дөньяви власть үз кулына алырга тиеш. Хәзерге әхлак ялгышлар һәм хорафатларга, дингә корылганлыктан, дөрес аңланучы, ягъни иҗтимагый мәнфәгатькә туры килүче шәхси мәнфәгатьтән килеп чыга торан яңа әхлак булдырырга тиеш. Әмма иҗтимагый мәнфәгатьне Гельвеций буржуаз позициядән чыгып аңлаган. Җәмгыятьнең нигезен ул шәхси милектә күргән.

Гельвеций барлык гражданнар өчен бердәм тәрбия максаты формалаштыру зарур дип санаган. Бу максат — бөтен җәмгыятьнең бәхетенә, мөмкин кадәр күбрәк гражданнарның хозурына һәм бәхетенә омтылу. Шәхси бәхет һәм "милләт бәхете" идеяләрен берләштерергә сәләтле патриотлар тәрбияләргә кирәк. Буржуаз акыл иясе буларак, Гельвеций милләт бәхетен чикләбрәк аңлатса да, тәрбия максатын шулай аңлау тарихи прогрессив характерда була.

Гельвеций раславынча, бөтен кешеләр дә белем алуга бер үк дәрәҗәдә сәләтле, чөнки аларның тугандагы рухи сәләтләре бертигез

була. "Кешеләрнең тумыштан тигезлеге турындагы" бу раслау демократизм белән сугарылган: ул социаль чыгышына бәйле рәвештә кешене табигать тигезсез яраткан диюче шул чорның дворян идеологлары теориясенә һөҗүм ясый. Әмма Гельвеций кешеләр арасында берниндн дә табигый аерма юк дию белән хаклы түгел.

Гельвеций фикеренчә, кеше фәкать мохит һәм тәрбия йогынтысында гына формалаша. Шул ук вакытта "тәрбия" төшенчәсенә ул бик киң мәгънә бирә. Гельвеций "гадәти мәгънәсендәге тәрбияне генә түгел, шәхеснең бөтен тормыш шартларының җыелмасын да" тәрбия дип аңлый. Гельвеций әйтүенчә, "Кешене тәрбия кеше иткән", "Тәрбия барысын да булдыра". Тәрбиянең дә, мохитнең дә ролен ул артык югары бәяләгән, кешене тирәлегендәге предметлар һәм хәтта очраклы хәлләр дә тәрбияли дип уйлаган. Болай аңлату кеше формалаштыруда стихияле факторларны артык югары бәяләүгә һәм оешкан теорияне бәяләп бетермәүгә китерә.

Аныңча, балаларның башын дин белән томалый торган схоластик мәктәп чын кешеләр генә түгел, гомумән аек фикерле кешеләр дә тәрбияли алмый. Шуна күрә мәктәпне тамырдан үзгәртеп кору, аны дөньяви, дәүләт мәктәбе итү һәм өстен хокуклы дворяннар кастасының белем алуга монополиясен бетерү кирәк. Халыкка мәгърифәт бирү, кешеләрне яңадан тәрбияләү зарур. Гельвеций мәгърифәт һәм тәрбия нәтиҗәсендә хорафатлардан, юкка-барга инанулардан азат кеше, чын атеист, патриот, бәхетен "милләтләр бәхете" белән берләштерә алучы кеше туачак дип өметләнгән.

**Дени Дидроның (1713-1784) идеологик карашлары.** Дени Дидро XVIII гасыр француз материализмының күренекле вәкиле була. Аның әсәрләрен властьлар дошманлык белән каршылый. Аның "Күзлеләргә гыйбрәт өчен сукырлар турында хатлар" әсәре дөньяга чыгуга, Дидроны кулга алалар. Иреккә чыкканнан соң, ул бөтен көчен "Фәннәр, сәнгать һәм һөнәрләр энциклопедиясен" әзерләү һәм бастыруга бирә. Ул чордагы буржуаз интеллигенциянең иң яхшы өлешен үз тирәсенә туплаган энциклопедия буржуаз француз революциясен идеологик яктан әзерләүдә гаять зур роль уйный.

Барлык француз фәлсәфәче-материалистлары арасыннан Дидро иң эзлеклесе була: ул материянең юкка чыкмавы, тормышның мәңгелеге, фәннең бөек роле турындагы фикерне кайнар яклаган.

Дидро тойгыларга зур әһәмият биргән, әмма танып белүне аларга гына кайтарып калдырмаган, ә бик хаклы рәвештә тойгыларны акыл

белән эшкәртүнең зур әһәмияткә ия булуын әйткән. Сизү органнары — бары шаһитлар гына, фикер йөртү ис сизү органнарыннан алынган мәгълүматлар нигезендә акыл эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Дидро тәрбиянең ролен югары бәяләгән, әмма Гельвеций белән бәхәсендә аның чиксез куәтен инкарь иткән. Ул диалог формасында үзенең мәгълүм "Гельвецийның "Кеше" китабын системалы рәвештә кире кагу" әсәрен яза (1773-1774).

Бер үзенчәлекле урынын китереп үтик:

"Гельвеций. Мин акыл, даһилык һәм яхшылыкны тәрбия продукты буларак карадым.

Дидро. Бары тәрбиянеке генәме?

Гельвеций. Бу фикер миңа әле дә дәрес кебек тоела.

Дидро. Ул ялган, шуңа күрә аны беркайчан да чын-чыннан ышандырырлык итеп исбатлап булмаячак.

Гельвеций. Тәрбиянең даһилыкка һәм кешеләр, халыклар холкына без уйлаганнан зуррак йогынты ясавы мәсьәләсендә минем белән килештеләр.

Дидро. Сезнең белән ризалашырдай нәрсә шушы гына да инде".

Дидро Гельвецийның тәрбия бөтенесе дә эшли ала дигән положениесен катгый рәвештә кире кага. Аныңча, тәрбия белән күп нәрсәгә ирешергә мөмкин, әмма ул балага табигать тарафыннан бирелгәнне генә үстерә. Тәрбия юлы белән яхшы табигый сәләтлелек билгеләрен үстерергә һәм начарларын киметергә була, ләкин моңа кешенең физик төзелешен, табигый үзенчәлекләрен исәпкә алган очракта гына ирешергә була.

Дидроның табигый аерымлыкларның кешеләр үсешендәге әһәмияте, тәрбияләгәндә баланың физик төзелеше һәм психикасындагы үзенчәлекләре белән исәпләшү зарурлыгы турындагы положениесе уңай бәягә лаек. Ләкин XVIII гасыр француз материалистик философиясенең чикләнгәнлеге сәбәпле, Дидро, ялгышып, кеше табигатен үзгәрмәүчән, абстракт бер нәрсә итеп карый. Асылда исә, кешенең табигате тарихи үсеш барышында үзгәрә.

Дидро, яхшы табигый сәләтлелек билгеләре аерым кешеләрдә генә дию дөрес түгел, киресенчә, аксөякләргә караганда гади халык арасында талантлар күбрәк очрый, дип санаган

Шул ук вакытта Дидро халык арасындагы талантлар күпләп һәлак була, чөнки начар иҗтимагый строй гади халыкның талантлы балаларын дөрес тәрбия һәм белем алудан мәхрүм итә дию белән

хаклы була. Ул киң халыкны мәгърифәтле итүне яклый, аның бик зур азатлык ролен таный. Дидро сүзләре белән әйткәндә, "мәгърифәт кешене абруйлы итә, һәм кол шундук үзенең кол булыр өчен тумаганлыгын аңлый".

Гельвеций шикелле үк, Дидро да француз феодаль тәрбия системасын тәнкыйтьләгән, руханилар кулындагы башлангыч мәктәпләр гади халык балаларын тәрбияләүгә игътибар итми, ә классик типтагы привилегияле урта мәктәпләр фәннәргә нпфрәт кенә тәрбияли һәм бик начар нәтиҗә бирә, дигән. Укыту һәм тәрбия системасы бөтенләе белән яраксыз, "халык мәгарифе методын нигезенә кадәр үзгәртү кирәк".

Нинди социаль катлаудан булуларына карамастан, балаларның һәммәсе дә укырга тиеш. Мәктәпләр, руханилар карамагыннан алынып, дәүләт карамагына бирелергә тиеш. Башлангыч белем алу түләүсез һәм мәҗбүри булырга тиеш, мәктәпләрдә җәмәгать туклануы оештыру зарур. Ярлы балалары укуның кадерен бай балаларына караганда күбрәк белә. Дидро катгый рәвештә урта мәктәпне үзгәртеп коруны таләп иткән. Урта классик белем мәктәпләренең зарарлы йогынтысына каршы чыккан, аларда фәнни нигездә математика, физика, химия, табигать белеме, астрономия укытуны тәэмин итү зарур дип санаган, реаль белем бирүне тормышка ашыруны таләп иткән.

1773 елда Екатерина II чакыруы буенча Дидро бер елга якын Петербургка килеп яшәгән. Мәгълүм булганча, Екатерина ул чорда "мәгърифәтле эшлекле" һәм эзәрлекләнгән фәлсәфәчеләрне канат астына алучы ролен уйнаган.

Дидро 1775 елда "Россия өчен университет планы" исемле Россиядә халык мәгарифен яңа нигезләрдә оештыру планын эшли (университет дигәндә ул бөтен халык мәгарифе системасын күздә тота). Екатерина, әлбәттә, Дидро планын тормышка ашырырга җыенмый да, чөнки ул артык радикаль план була.

**8.1. Вопросы для самоконтроля**

1. Сравните взгляды К. А. Гельвеция, Д. Дидро, Ж. - Ж. Руссо на место и роль воспитания в становлении человека.
2. Где должно осуществляться образование и чему необходимо учить детей по убеждению Дж. Локка, Ж.-Ж. Руссо?
3. Что понимал Ж. - Ж. Руссо под естественным и свободным воспитанием?

**8.2. Задания для практики.**

Перечислите основные направления модернизации учебно-воспитательного процесса в современной зарубежной школе.

Каковы содержание и методы обучения в современной зарубежной школе?

Ознакомиться с текстом документа «Тема 8» , добавить вопросы для самоконтроля.

**8.3. Глоссарий по теме 8**

**Дидро Дени** (1713 — 1784) — фр. просветитель-материалист XVIII в., автор «Энциклопедии наук, искусств и ремесел», сыгравшей не последнюю роль в идеологической подготовке буржуазной французской революции. Основные взгляды Д. на воспитание изложены им в книге «Систематическое опровержение книги Гельвеция "Человек"». Придавая большое значение воспитанию, он, в отличие от К. Гельвеция, не признавал этот процесс всемогущим. Воспитание может сделать многое, если оно будет учитывать физическую организацию человека и его природные особенности. Был сторонником просвещения широких народных масс. Выступал против сословной школы и неравенства в образовании. Считал, что школы должны быть изъяты у духовенства и отданы государству, в них, ограничив классическое образование, необходимо обеспечить преподавание таких дисциплин, как математика, физика, химия, естествознание, астрономия. В 1773 г. по приглашению Екатерины II Д. год жил в Петербурге и составил «План университета для России», который не был реализован из-за своего крайнего радикализма.

**Идеал воспитания** — цель педагогической деятельности; содержит в себе нравственные, эстетические и культурно-образовательные характеристики личности. С точки зрения нравственности идеальный человек является носителем общечеловеческих норм морали, высоких духовных ценностей. Он руководствуется только моральными принципами, свободен от конъюнктурных внешних влияний и соображений выгоды в выборе поведения, ответствен перед совестью и людьми. В общественной жизни он стремится к творческому самоутверждению и самовыражению, созиданию материального и духовного блага, заботится об экологической целостности природы, культурной, нравственной чистоте. Он непримирим к злу в любых его проявлениях. Эстетически идеальный человек характеризуется стремлением к достижению внутренней духовной целостности,

гармонии сознания, воли и поведения. Культурно-образовательная характеристика идеального человека состоит в том, что он непрерывно обогащает себя знанием духовных богатств, умениями и навыками самосовершенствования. Всем этим и достигается гармония истины, добра и красоты, реализуется идеал.

### 8.4. Использованные информационные ресурсы


1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования /Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.


## Тема 9. *ФРАНЦУЗ БУРЖУАЗ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЧОРЫНДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР ҺӘМ МӘКТӘП*

**Аннотация.** Данная тема раскрывает о педагогической идеи и школе во время буржуазной революции.

**Ключевые слова.** Кондорсе, обучение, школа, институт.

**Методические рекомендации по изучению темы.**

- Тема содержит лекционную часть, где в разделе «Лекция» имеются общие представления по теме;
- После прохождения предыдущей части, надо выполнить задание и подготовить вопросы по тексту;
- И напоследок есть раздел Обсуждений, где вы можете обсудить разные интересные факты, рассказать о чем-то новом, или же просто спрашивать то, чего не поняли.

### *ФРАНЦУЗ БУРЖУАЗ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЧОРЫНДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР ҺӘМ МӘКТӘП*

18 гасырның 70-80 елларында Франциядә революцион ситуация барлыкка килә.

Феодаль җәмгытьнең эчендә яңа капиталистик уклад формалары үсеп җитлегә. Әмма феодаль-абсолют монархия режимы капитализм, авыл хуҗалыгы, промышленность һәм сәүдә үсешен тоткарлый. 1789-1794 елгы француз буржуаз революциясе "өченче катлауның"

феодализм белән кискен бәрелеше була. Ул феодаль-монархия строен җимерә һәм капитализм үсешенә җирлек әзерли. Гәрчә үз чорының тарихи шартларында XVIII гасыр француз буржуазиясе алдынгы, революцион сыйныф буларак чыкса да, революциягә көч һәм колачны фәкать халык массалары гына бирде. Шунсыз аның җиңүе мөмкин булмас иде. Халык революциядә төп катнашучы, аның хәрәкәтләндерүче көче була. Халык феодаль контрреволюция белән көрәшнең бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татый, революцияне алга этәрә; халык массаларының революциядә иҗади катнашуы һәммә нәрсәдә, шул исәптән халык мәгарифе өлкәсендә дә күренә. Халык массалары мәгарифне оештыру белән кызыксына, белемгә омтыла. Күп гасырлар буенча феодаллар һәм руханилар халыкны караңгылык һәм наданлыкта тоталар. 1790 елда әле ирләрнең 53 проценты һәм хатын-кызларның 73 проценты укый-яза белми.

**Мәктәпне яңа нигездә төзү мәсьәләләре гомуми кызыксыну уята**. Бу өлкәдә тәкъдим ителгән проектларга француз мәгърифәтчеләре (аеруча Руссо) һәм француз материалистлары (Гельвеций, Дидро) идеяләре турыдан-туры йогынты ясый. Халык мәгарифен үзгәртеп кору проектлары тирәсендә кискен сыйнфый көрәш бара.

Ул чорда прогрессив буржуазия вәкилләре 1789-1794 елларда халык мәгарифе өлкәсендә күп кенә алдынгы идеяләр күтәреп чыгалар. Ләкин аларның берсе дә тормышка ашырылмый диярлек. 9 нчы термидор (1794 елның 27 июле) контрреволюцион переворотыннан соң, эре реакцион буржуазия властька килгәч, аның мәнфәгатьләренә җавап бирүче халык мәгарифе системасы урнаша.

Бу чорда хезмәт ияләре халык мәгарифе өлкәсендә революция елларында ирешелгән аз гына казанышлардан да мәхрүм ителәләр.

Буржуаз француз революциясе чорында халык мәгарифен үзгәртеп кору буенча иҗат ителгән проектлардан иң прогрессивлары Кондорсе һәм Лепелетье проектлары була.

**Кондорсе проекты. Жан Антуан Кондорсе** (1743-1894) күренекле философ, экономист, математик, физик, шулай ук жирондистлар партиясе җитәкчеләреннән берсе була. Ул проектын Закон чыгару мәҗлесе оештырган иҗтимагый мәгариф комитетына тәкъдим итә.

Кондорсе: халыкка белем бирү — дәүләтнең бөтен гражданнар алдындагы бурычы; мәктәпнең һәммә баскычларында да укыту

гомуми һәм бушлай, кыз һәм ир балалар өчен тигез булырга тиеш; дин сабагын укыту туктатылырга тиеш, дип игълан итә.

Кондорсе түбәндәге мәктәп системасын тәкъдим итә:

1)*Дүртьеллык курслы беренчел (башлангыч) мәктәп.* Нинди катлаудан һәм ата-аналарының нинди профессия кешеләре булуына карамастан, ул мәктәпкә барлык малайлар һәм кызлар да керергә тиеш. Бу мәктәпләр халкы 400 гә җиткән һәммә җирдә ачыла. Укыту программасы: уку, язу, грамматика һәм арифметикадан башлангыч мәгълүматлар, авыл хуҗалыгы һәм һөнәрләр белән, илдәге җитештерүнең гомуми торышы белән танышу. Моннан тыш, анда иҗтимагый строй һәм әхлак нигезләре өйрәнелә. Башкача әйткәндә, мәктәптә киң гомуми белем бирү программасы һәм хезмәткә өйрәтү күздә тотыла.

2)*Өчъеллык курслы икенче баскыч мәктәбе (икенчел мәктәп).* Аңа башлангыч мәктәпне тәмамлаучылар керә. Икенче баскыч мәктәбе халкы 4000 гә җиткән һәрбер шәһәр яисә округта ачыла. Укыту программасы: математика, табигать белеме, сәүдә буенча башлангыч мәгълүматлар, әхлак принциплары һәм җәмгыять белеме, һәрбер мәктәптә китапханә һәм машина модельләре, табигать белеменнән коллекцияләр, һөнәрчелек кораллары җыелмасы, метеорологик күзәтүләр өчен приборлар куелган кабинетлар булырга тиеш.

3)*Институтлар* — бишьеллык курслы уку йортлары, анда урта белем алу тәмамлана һәм яшьләр тормышта турыдан-туры катнашу өчен беркадәр профессиональ әзерлек алалар. Кондорсе бөтен илгә нибары 110 институт ачарга тәкъдим иткән, ягъни гади халыкка мондый төр белем алу мөмкинлеге булмаган. Институтларда, Кондорсе фикеренчә, профессиясенә карамастан, һәрбер кеше һәм гражданин өчен дә файдалы фәннәргә өйрәтәләр, һәм авыл хуҗалыгы, механика, хәрби эш, медицина буенча беркадәр профессиональ белемнәр бирәләр.

4)*Лицейлар* — югары уку йортлары (бөтен Франциядә унбер лицей) — аерым кешеләр, буржуаз җәмгыятьнең югары катлавы өчен феодаль реакциянең терәге булган схоластик университетлар урынына ачыла.

Шул рәвешле, Кондорсе үзенең проектында бердәм дөньяви мәктәп идеясен күтәреп чыга. Анда барлык баскычтагы мәктәпләр дә административ яктан һәм программалары белән үзара бәйле була, чөнки институтлар — үз департаментындагы мәктәпләр белән, ә

лицейлар үз округларындагы институтлар белән идарә итә. Уку йортларының бөтен системасы белән исә Фәннәр һәм сәнгать милли институты — административ һәм тикшеренү үзәге идарә итәргә тиеш.

Шушы системасын нигезләп, Кондорсе болай ди: *кеше акылы белем тәэсирендә чиксез үсешкә сәләтле, кешелекнең алга таба үсүе фән ирешкән уңышларга бәйле.*

Кондорсе проекты тулаем алганда прогрессив була, ләкин аның күп кенә положениеләрендә халык мәнфәгате түгел, ә күтәрелеп килүче буржуазия мәнфәгате чагылыш таба.

Мәсәлән, Кондорсе укучыларның матди хәлен яхшырту өчен берни дә тәкъдим итми, ә шул ук вакытта фәкыйрь ата-аналарның балаларын эшләтмичә укыту мөмкинлекләре булмаган. Дин урынына яңа, буржуаз җәмгыятьтә үзенең тотуның төп нормаларын ныгытырга тиешле буржуаз әхлак курсы кертелгән.

Ләкин Кондорсе проектында прогрессив таләпләр дә чагылыш таба: дин сабагын укыту бетерелә, дөньяви мәктәп яклана, физика-математика фәннәренең зур әһәмияте ассызыклап күрсәтелә, белем алуда ирләр һәм хатын-кызларның тигез хокуклыгы танылды.

**Кондорсе проекты Закон чыгару мәҗлесендә тыңлана, әмма кабул ителми. Аны Конвентка тапшыралар.**

Конвент 1793 елның 30 маенда нигезенә Кондорсе проекты салынган декрет кабул итә. Бу декретта дәүләтнең барлык гражданнарга башлангыч мәктәп күләмендә белем бирергә тиешлеге танылa, әмма укытуның түләүсезлеге һәм мәҗбүрилеге, белем алуга ирләр һәм хатын-кызларның тигез хокуклылыгы, укытуның дөньяви характеры турында берни дә әйтелми. Башлангыч мәктәпләрне 400 дән 1500 гә кадәр халкы булган торак пунктларда ачу күздә тотыла. Шул рәвешле, Кондорсе проектының күп кенә прогрессив идеяләреннән жирондистлар үзләре баш тарталар.

**Лепелетье проекты.** Жирондистлар Конвенттан куылгач, власть тулысынча ул чорда иң революцион партия — якобинчылар кулына күчә. Якобинчылар халык массаларының таләпләренә җавап бирә торган күп кенә чаралар үткәрәләр (спекуляция белән көрәш һ.б.), халык мәгарифе мәсьәләләрен дә башкача куялар. Иҗтимагый белем комитеты яңадан сайлана. Бу чорда Лепелетье проекты бик популяр була, аны "Якобинчылар клубы", Париж секцияләре энтузиазм белән каршылый, Конвентның бик күп депутатлары уңай бәяли. Бу уңышны ике нәрсә белән аңлатып була. Беренчедән, Кондорсе проектының

йомшак якларын исәпкә алып һәм хезмәт ияләре теләгенә туры китереп, Лепелетье белем бирүне халыкка аңлаешлы итәргә омтылган. Икенчедән, монда автор шәхесе дә зур роль уйнаган. Гәрчә **Луи Мишель Лепелетье** (1760-1793) аксөякләр гаиләсеннән булса да, мәсләге буенча ул якобинчыларга кушыла һәм корольгә үлем җәзасы бирүне яклап тавыш бирә, шуның өчен король гвардиясе офицеры тарафыннан үтерелә.

Лепелетье үлгәннән соң, аның проектын энесе мәгариф турында яңа закон әзерләү комиссиясенә бирә, ул комиссиянең башында якобинчыларның юлбашчысы Робеспьер тора. Заманына күрә иң прогрессив документ — Лепелетье проектында мәктәпне чын-чынлап бөтен халыкныкы итү һәм "бердәнбер байлыклары хезмәт булган граждан-пролетарийларга" ярдәмгә килү теләге ачык чагылыш тапкан. "Мескен бала,— ди Лепелетье,— сез аңа укырга тәкъдим итәсез, тик сез иң элек аңа бер сынык ипи бирегез". Нәкъ менә шушы позицияләрдән ул Кондорсе проектын кискен тәнкыйтьли. Бу проектта, ди Лепелетье, гомуми башлангыч белем бирү игълан ителгән генә, чынлыкта исә бу белемне халыкның фәкыйрь өлеше алу мөмкинлеген тәэмин итәргә кирәк.

Француз мәгърифәтчеләре эшен дәвам иттерүче Лепелетье яңа эшен иҗат итүдә тәрбиянең хәлиткеч ролен яклый. Шушы максаттан ул милли тәрбия йортлары оештырырга тәкъдим итә. Дәүләт акчасына көн күрүче бу йортларда барлык балалар да: 5 яшьтән 2 яшькә кадәрге малайлар һәм 5 яшьтән 11 яшькә кадәрге кызлар әзерлек ала. 600 гә кадәр балага исәпләнгән мондый "йортлар" шәһәрләрдәге һәрбер районга бирү һәм авылларда бер канунга бирү оештырылырга тиеш. Руссога ияреп, Лепелетье интернаттагы балалар мохитнең зарарлы йогынтысыннан аерылган булачаклар дип саный. Мондый "йортлар" конфискацияләнгән зорян замокларында һәм монастырь биналарында урнаштырырга мөмкин. Аларны тоту чыганакларының берсе керемгә карап салына торган прогрессив налог булырга тиеш, шул чагында «ярлы балалары байлар исәбенә тәрбияләнәчәк". Моннан тыш, балаларның үзләренең җитештерүчән хезмәте бу "йортларны" тотуга өстәмә чыганак булачак.

"Милли тәрбия йортларында" балаларның физик тәрбиясенә игътибар ителергә тиеш, ләкин гимнастик күнегүләр белән генә чикләнергә ярамый, басу-кырларда һәм махсус остаханәләрдә планлы рәвештә физик хезмәт оештырырга кирәк. Ул "йортларда"хезмәт

күрсәтүче персонал булырга тиеш түгел: барысын да балалар үзләре эшли. Эш тәнне чыныктыра, мускулларны ныгыта һәм, иң мөһиме, "хезмәткә күнегү" тәрбияли.

Лепелетье акыл үстерүнең киң программасын да тәкъдим итә: «йортларда" язу, хисап, геометрия элементлары, әхлак, иҗтимагый төзелеш ("Кеше һәм гражданин хокуклары декларациясе» н өйрәнү), ирекле халыклар һәм француз революциясе тарихыннан хикәяләр, авыл хуҗалыгы һәм йорт эшләре нигезләре өйрәнелергә тиеш.

Нәтиҗәдә, Лепелетье фикеренчә, яңа яшь буын, "көчле, эш сөючән, тәртипле һәм намуслы, яңа гражданнар, патриотлар булып тәрбияләнәчәк.

Лепелетье проекты, һичшиксез, революцион һәм демократик характерда, ләкин шул ук вакытта ул вак буржуаз утопия дә була.

"Милли тәрбия йортлары" оештыру "басынкы һәм тыныч революцияне" тормышка ашырачак, фәкыйрьләрне байлар исәбенә тәрбияләү юлы белән иҗтимагый тигезсезлекнең кимчелекләрен төзәтәчәк, дип саный Лепелетье, ләкин бу утопия була. Шул ук вакытта аның проекты мәгарифне халык мәнфәгатьләрендә катгый демократияләштерү юлларын билгели.

Конвентта проектны тәнкыйтьлиләр: аерым алганда, аны тормышка ашырган чакта туачак кыенлыкларны күрсәтәләр. 1793 елның 13 августында Лепелетье проекты кабул ителә, әмма түбәндәге төзәтмә белән: балаларны "милли тәрбия йортларына" бирү мәҗбүри түгел, "йортлар" белән беррәттән, килеп укучы балалар өчен дә мәктәпләр ачарга кирәк. Ләкин бу карар да шул ук елның октябрендә юкка чыгарыла. Лепелетье проектының язмышы Конвентның бик күп өлкәләрдәге, шул исәптән халык мәгарифе өлкәсендәге, зур башлангычларының ахырына кадәр җиткерелмәве турында сөйли.

Башлангыч мәктәпләр челтәрен җәелдереп җибәрү турындагы практик мәсьәлә дә хәл ителми. Гәрчә 1793 елның декабрендә Конвент мәҗбүри башлангыч белем бирү турында декрет кабул итсә дә, 1794 елның уртасына ачылырга тиешле 23 мең мәктәп урынына нибары 8 мең мәктәп эшли.

**Термидориан реакциясе чорында мәктәп.** Гракх Бабефның педагогик идеяләре. Халык мәгарифе өлкәсендә бераз гына ирешелгәннәр дә 9 нчы термидор переворотыннан соң яңа властьлар тарафыннан юкка чыгарылган. Мәсәлән, 1894 ел ахырында —

башлангыч белем бирүнең мәҗбүрилеге, ә бер елдан соң аның түләүсезлеге бетерелә.

Шул ук вакытта яшь гражданнар күбесе өчен югарырак белемгә омтылуның кирәксезлегенә басым ясала. Буржуазия балаларын укыту өчен хосусый мәктәпләр ачарга рөхсәт ителә. Урта белән үзәк мәктәпләрдә (330 мең халкы булган җирдә бер мәктәп) бирелә. Буржуазия балаларын "промышленность эшчәнлегенә" әзерләүче бу мәктәпләр программасында реаль белемнәргә: физика, математика, табигать белеменә зур игътибар бирелә.

Шул ук вакытта “Иҗтимагый эшләр үзәк мәктәбе” дигән атаклы югары мәктәп ачыла. Тиздән ул Политехник мәктәп дип йөртелә башлый һәм соңрак физика-математика фәннәрен үстерү эшендә күренекле роль уйный.

Бөтен мәктәп системасы гади халык балаларына белем бирүне чикләүне күздә тотып үзгәртеп корыла.

Термидориан реакциясе чорына хезмәт ияләренең килеп туган хәлдән ризасызлыгы көчәя. 1795-1796 еллар башында Гракх Бабеф торган революционерлар төркеме Директорияне бәреп төшерү һәм 1793 елгы конституцияне торгызу максатында восстание әзерли башлый. Бабеф гражданнарның тулы социаль тигезлегенә ирешү бурычын куя. Энгельс әйтүенчә, Бабеф революция чорындагы француз демократиясе идеяләреннән соңгы нәтиҗәләр ясый.

Бабеф һәм аның тарафдарлары революцион юл белән властьны алып, коммунистик строй урнаштыруны максат итеп куялар. Ләкин алар булачак стройны тигезләүчелек коммунизмы итеп күзаллыйлар. Восстаниене әзерләгән Комитет яңа кеше тәрбияләүгә бәйле күп кенә педагогик мәсьәләләрне дә тикшерә. Дөрес оештырылган тәрбияне Комитет социаль тигезлекнең нигезе итеп карый. Тәрбия милли булырга, яңа дәүләт власте тарафыннан оештырылырга, чын-чыннан гомуми һәм тигез, ягъни барлык балалар өчен дә бертөрле булырга тиеш. Тәрбиянең төп бурычы — ялкынлы патриотлык, революцион ватанга мәхәббәт үстерү. Яңа кешеләр белемле һәм яхшы физик үсешкә ия булачак. Авыл җирләрендә "тәрбия коммуналары" оештырылырга тиеш, анда балалар, җәмгыятьтән аерылып чын гражданнар һәм коммунистлар булып үсәчәк.

Ләкин Бабефта, бик кыйммәтле идеяләр белән беррәттән, карашларның чикләнгәнлеге нәтиҗәсе буларак, ялгыш положениеләр дә бар. Ул промышленностьның, пролетариат роленең әһәмиятен

аңлмаган, шәһәргә тискәре караштa торган, җәмгыять үсешендә фәннең әһәмиятенә бәя бирмәгән.

Бабефның педагогик карашларына һәм "Тигезләр заговоры" комитетының тәрбия мәсьәләләре буенча тәкъдимнәренә Руссо һәм Лепелетьеның йогынтысы бик зур була.

1789-1794 еллардагы француз буржуаз революциясе чорында халык мәгарифен үзгәртеп кору буенча күп кенә проектларда чагылыш тапкан педагогик идеяләр дөньяның бик күп илләрендә прогрессив педагогик фикер үсешенә зур йогынты ясый.

**9.1. Вопросы для самоконтроля**

1. Сравните взгляды К. А. Гельвеция, Д. Дидро, Ж. - Ж. Руссо на место и роль воспитания в становлении человека.
2. Какие вопросы создания новой системы образования находились в центре полемики на Западе в XIX в.?
3. Назовите основные направления и их авторов в реформаторской педагогике Западной Европы конца XIX в.

**9.2. Задания для практики.**

Какой вклад внес Дидро в разработку теории и практики педагогического образования?

Какие важные особенности были присущи зарубежной школе и педагогике в первой половине 1900-х гг.?

Охарактеризуйте основные течения в реформаторской педагогике Западной Европы конца XIX - начала XX вв.

Ознакомиться с текстом документа «Тема 9» , добавить вопросы для самоконтроля.

**9.3. Глоссарий по теме 9**

**Идеологическое воспитание** — воспитание в процессе общественной жизни, предполагающее формирование у воспитанников основ мировоззрения, убеждений, эмоционального отношения к явлениям действительности.

**Идеологическое образование** — овладение системой ключевых, ведущих, системообразующих идей о законах развития природы и общества, знание различных идеологических направлений и способность критического отношения к ним.

**Историческая школа** — направление, основанное на историческом понимании процессов, на их самом детальном исследовании.

**Отражение в воспитании** — восприятие, познание, понимание воспитателем воспитанника и себя как участников взаимодействия. О.

в в. — механизм обратной информации, обратной связи, показывающий последствия воспитательных действий, условие эффективного воздействия на школьника.

**9.4. Использованные информационные ресурсы**


1. Бим–Бад Б.М. Очерки по истории и теории педагогики. – М., 2003.
2. Джуринский А.Н. История педагогики. - М., 2004.
3. История образования и педагогической мысли за рубежом и в России / Под ред. З.И.Васильевой. – М., 2001.
4. История педагогики и образования / Под ред. А.И.Пискунова. - М., 2001.
5. Латышина Д.И. История педагогики. - М., 2003.
6. Титов В.А. История педагогики. Конспект лекций. - М., 2003.
7. Торосян В.Г. История образования и педагогической мысли. – М., 2003.